ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ һӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЫ

ТАТАР ТЕЛЕ һӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ БУЕНЧА УКУЧЫЛАРНЫ МУНИЦИПАЛЬ, РЕСПУБЛИКА һӘМ ХАЛЫКАРА ОЛИМПИАДАГА ӘЗЕРЛӘҮ

МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ БУЕНЧА УКУЧЫЛАРНЫ МУНИЦИПАЛЬ, РЕСПУБЛИКА ҺӘМ ХАЛЫКАРА ОЛИМПИАДАГА ӘЗЕРЛӘҮ

МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР

Казан
2024

ББК 74.268
Т23

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 25 августында 730 номерлы карары белән расланган “Татар халкының милли тәңгәллеген саклап калу” Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә басыла.

Төзүче: Гыйләҗева Л.Г., ТРМҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты.

Татар теле һәм татар әдәбияты буенча укучыларны муниципаль, республика һәм халыкара олимпиадага әзерләү: методик тәкъдимнәр / төз. Л.Г.Гыйләҗева. — Казан: ТРМҮИ, 2024. — 117 б.

© ТРМҮИ, 2024

Татар теле һәм әдәбияты буенча укучыларны олимпиадага әзерләү буенча методик тәкъдимнәр Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 нче елның 22 нче июнендә 566 нчы номерлы әмере белән расланган «Укучылар олимпиадасын үткәрү тәртибен раслау турында» («Об утверждении Порядка проведения олимпиад школьников»), Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Укучылар өчен бөтенроссия һәм республика олимпиадаларының мәктәп этабын уздыру турындагы» боерыгы, (Приказ МОиН РТ от 16.09.2024 № под-1585/24 «О проведении школьного этапа всероссийской и республиканской олимпиад школьников в 2024/25 учебном году»; «Укучылар өчен бөтенроссия һәм республика олимпиадаларының муниципаль этабын уздыру турындагы» боерыгы (Приказ МОиН РТ от 30.10.2024 № под-1809/24 «О проведении муниципального этапа всероссийской и республиканской олимпиад школьников в 2024/25 учебном году») нигезендә эшләнде.

Галимнәр сәләтсез балалар юк, һәркемнең нәрсәгә дә булса сәләте, омтылышы була диләр, безнең — укытучыларның бурычы — баланы сәләтен ачыклау, ихтыяҗын төрле яктан канәгатьләндерү, сәләтен үстерү. «Күп белдерүгә караганда, әз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләү юлларын табарга өйрәтү — мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнеи зурысы», — дигән әдәбият галиме Г.Ибраһимов. Укытучы алдына куелган мөһим бурычларның берсе укучыларның мөстәкыйль рәвештә ижади фикер йөртергә, нәтиҗә ясарга өйрәтү, укучыларның эзләнү, тикшеренү һәм ижади фикерләү эшчәнлеген активлаштыру, сәләтләрен ачу. Татар теле һәм әдәбиятыннан мәктәп, муниципаль, республика һәм халыкара тур олимпиадаларның максаты укучыларның татар теле һәм әдәбияты белән кызыксынуларын уяту, арттыру, укытучыларда укучыларының белем дәрәҗәсе өчен җаваплылык хисен үстерү, укучыларда бер-берсе белән ярышу, көч сынашу мохитен тудыру, гадел көндәшлелек тудыру, укучыларның интеллектуаль потенциалын күтәрү юнәлешендә актив эш алып бару. Бүгенге көндә укучыларның олимпиадаларда катнашу нәтиҗәләре мәктәптә, шәһәрдә, республикада белем бирү дәрәҗәсен ачыклый торган бер критерий булып тора, укытучының эшчәнлек дәрәҗәсен бәяләргә ярдәм итә. Укучыны олимпиадага әзерләү нигезендә системалылык, эзлеклелек ятарга тиеш: мондый төр ярышларга укучыны башлангыч сыйныфлардан ук әзерләү мөһим. Өченче сыйныфта мәктәп күләмендә еллык олимпиадалар уздырып карарга мөмкин. Призлы урыннарга лаек булган укучылар параллель сыйныфта белем алган җиңүче балалар белән үзара көч

сынашалар. Жюри һәр катнашучының эшен тикшерә, анализ ясый һәм төрле номинацияләр буенча җиңүчеләрне билгели. Олимпиадада катнашкан укучы үз җиңүләрен, төрле бәйгеләрдә катнашкан мәгълүматларны бер папкага туплап барса, алга таба кулайрак була. Татар теленнән мәктәп, муниципаль һәм республика күләм олимпиада 4–11 сыйныфлар арасында уздырыла. Мәктәптә уза торган олимпиадада укучы үз теләге белән катнашырга тиеш. Аның татар теле дәресләрендә алган билгеләре исәпкә алынмый. Мәктәп олимпиадасында җиңгән һәм призлы урыннарга лаек булган укучылар олимпиаданың башка этапларында катнашу өчен туплана торган командага сайлап алу турында катнашалар. Һәр ел саен муниципаль дәрәҗәдә үткәрелә торган олимпиадага бер команда туплана. Әлеге команда белән эшләү, аларны олипиадага әзерләү өчен, аерым бер мәктәп укытучысы яисә югары уку йортында эшли торган галим чакырылырга мөмкин. Әлеге эш системасы олимпиадага уку елы дәвамында эзлекле әзерләнергә һәм көчле команда тупларга ярдәм итә. Команда җитәкчесе, укучыларны бергә җыеп, аларның белем системасын билгеле бер тәртипкә китерергә тиеш. Муниципаль күләмдә үткәрелә торган олимпиада нәтиҗәләре Мәгариф һәм фән министрлыгында бергә туплана, нәтиҗә ясала, һәм иң югары балл туплаган укучылар республика күләмендә уздырыла торган олимпиадага чакырыла. Шул сәбәпле һәр муниципаль оешмадан һәр сыйныфтан берәр җиңүче түгел, ә гомум баллар чыгарылганнан соң җиңүче дип табылган 4–11 сыйныф укучылары чакырыла. Нәтиҗәдә, аерым муниципаль оешмадан ун укучы көч сынашырга, ә икенчесеннән бер укучы да катнашмаска мөмкин. Республика күләмендә уздырыла торган олимпиадада, чыннан да, Татарстан республикасындагы иң көчле балалар үзара көч сынаша. Татар теленнән мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендә үткәрелә торган олимпиаданың максатлары түбәндәгеләр:

- укучыларның татар теле белән кызыксынуларына этәргеч бирү;
- укучыларның татар теле дәресләрендә алган белемнәрен тирәнәйтү;
- татар тел белеме белән кызыксынучы укучыларны табу;
- укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү;
- укучыларга үз сәләтләре һәм белемнәре белән бәйле булган югары уку йортларын табарга ярдәм итү. Муниципаль һәм республика күләмендә уздырыла торган олимпиадада 4-11 сыйныф укучылары катнашырга хокуклы. Һәр сыйныф өчен биремнәр аерым төзелергә тиеш. Укучыларны муниципаль һәм республика олипиадасына әзерләү өчен, аерым уку-укыту программасын төзү мөһим. Шул ук вакытта һәр сыйныф һәм һәр укучы өчен индивидуаль белем бирү юнәлешен булдыру кирәк. Берничә дәресне психологлар үткәргән

очракта, бу укучыларга олимпиада вакытында була торган стресс халәтеннән котылырга ярдәм итәчәк.

1.2. Биремнәрне төзүгә гомум таләпләр.

Биремнәр төгәл, грамоталы, укучыларга аңлаешлы итеп һәм мәктәп программасында үтелә торган терминнардан гына төзелергә тиеш. Аларны телдәге бәхәсле, ике төрле фикер йөртергә урын калдыра торган сораулардан төзү катгый тыела. Биремнәрдә җавап формасы күрсәтелергә мөмкин (астына сызарга, дөрес җавапны күрсәтергә, кушымчаларны билгеләргә һ.б.), ә кайчак аның күләме дә искәртелә (мәсәлән, җавап язу өчен тел берәмлекләренең саны күрсәтелә. Өстәмә сорауларга җавап бирү аерым бәяләнгән очракта, биремдә бу хакта укучыга күренеп торырлык итеп искәртелергә тиеш. Болар барысы да катнашучының белемен гадел бәяләү өчен мөһим. Олимпиаданың күп кенә биремнәре тулы җавап язуны таләп итә, чөнки шул очракта гына укучының язу культурасын, үз фикерен эзлекле һәм аңлаешлы итеп әйтә белүе, грамоталылыгы күренә. Тулы җаваплар теге яки бу тел берәмлегенең эчтәлеген генә ачып бирми, ә, бәлки, аның грамматик, стилистик белемен дә, этимологияне, тарихи-мәдәни тел кыйммәтләрен белүе дә аңлашыла, җавапны бер тәмамланган бөтен итеп оештыра алуы бәяләнә. Мондый төр биремнәр: исбатлагыз, аңлатып бирегез, җавабыгызны дәлилләгез диән формада бирелергә тиеш. Укучы бу очракта, үзенең фикерен дәлилләү өчен, грамматик белемең генә түгел, ә күзәтүләрен дә эшкә җигәргә тиеш.

Бирем төрләре

Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиада биремнәрен шартлы рәвештә ике төргә бүлергә мөмкин: лингвистик тестлар һәм лингвистик мәсьәләләр.

Лингвистик тестлар

Мондый төр биремнәр укучыларның мәктәп программасы кысаларында өйрәнелә торган тел берәмлекләрен анализлау белән бәйле белемнәрен тикшерүне максат итеп куя. Тестлар, гадәттә, һәр тел тармагына биреләләр, мәсәлән, фонетика, лексикология, сүз ясалышы, морфология, синтаксис. Тестлар ачык яисә ябык була ала. Анда һәм теоретик, һәм практик сораулар урын алырга мөмкин. Ләкин тестның сораулары да, тәкъдим ителгән җавап вариантлары да бер үк төрле булырга тиеш. Гадәттә, бер тестка 4 төрле җавап вариантын бирү уңышлы, ләкин 4 нче сыйныф укучылары өчен 3 төрле җавап вариантын бирү дә җитә. Тестларны төзү оештыручылардан төгәллек таләп итә. Әлеге төр биремнәрдә җавапны ике төрле вариант итеп билгели алырлык сораулар булырга тиеш түгел.

Лингвистик мәсьәләләр

Лингвистик мәсьәләләр укучының татар теленнән туплаган белемнәрен; фонетик, лексик, сүз ясалышы, морфологик һәи синтаксик анализ күнекмәләрен; телне сиземләвен; күзәтү, тасвирлау, чагыштыру, системалаштыру, гомумиләштерүгә бәйле тикшеренү алымнарын куллана белүен бәяләүне күздә тотып төзелә. Бу биремдә укучы өчен аерым текст тәкъдим ителергә мөмкин, һәм укучы үзенең мәктәптә уку дәверендә алган теоретик һәм практик күнекмәләрен ачып бирергә тиеш. Шуны да онытмаска кирәк: олимпиада укучының белемен генә тикшереп калмый, ә аның тел белән кызыксынуын да арттыра. Катнашучы әлеге олимпиададан үзенә ниндидер яңалык та алып китә. Шуңа күрә укучы өчен тарихи коментарийлар, әдәби әсәрдән цитаталар яисә фәнни хезмәтләр белән таныштыру да урынлы булыр. Олимпиада биремнәрендә укучыны теоретик сораулар белән ялыктыру урынсыз. Укучының теге яки бу теоретик мәгълүматны тормышта, сөйләмдә ничек куллана белүен ачыклау мөһим. Укучыга билгеле бер фикер яисә тема белән бәйле ижади эш тә тәкъдим ителергә мөмкин. Биремнәргә таләпләр:

- тәкъдим ителгән сораулар оригиналь, башка методик кулланмаларда һәм Интернетта булмаска тиеш;

- олимпиада биремнәрен төзегәндә, әлеге методик киңәшләргә таянырга кирәк;

- сораулар ирекле тәртиптә төзелә, ләкин, гадәттә, аларны җиңелдән авырга таба бару ысулы белән төзү уңышлы;

- сораулар бер генә җавап табуны күздә тотылып төзелергә тиеш. Әгәр берничә җавапны табарга кирәк булса, бу хакта, һичшиксез, искәртелә. Муниципаль һәм региональ методик оешма үз төбәгенең этномәдәнияте, диалекталь үзенчәлекләре, җирле сөйләше һәм әдәбияты белән бәйле 2–3 сорау бирергә хокуклы. Татар теленнән Республика олимпиадасы 3 этаптан гыйбарәт, шуңа күрә биремнәрне эшләгәндә, барлык комиссия биремнәрне бер төрле системада төзесә, эшнең нәтиҗәсе һәм укучының әзерлеге күпкә отышлырак була. Әлеге тәртипкә укучыны башлангыч сыйныфта укыганда ук әзерли башларга кирәк. Олипиада эшләрен бәяләгәндә, укучының мәктәп программасын белүе генә түгел, ә лингвистик эрудициясе, телне сиземләве, тоемлавы, логик фикерли белүе дә исәпкә алынырга тиеш. Орфографик, пунктуацион, стилистик нормаларның сакланышын да аерым бәяләү мөһим. Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиада биремнәрен төзегәндә, хаталарның бердәм системасын исәпкә алу нормалары булдырыла. Балларны кую системасының нигезен төзеп кую да таләп ителә.

Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиада үткәрү өчен төзелгән биремнәрне тасвирлау

Биремнәрне төзегәндә, олимпиадада катнашучыларның түбәндәге белемнәрен чагылдыруларын исәптә тотарга кирәк:

- татар әдәби теленең орфоэпик нормаларына ия булуларын (басым, арткы һәм алгы рәт сузыкларны аеру, татар теленә хас тартыкларны һәм сузыкларны әйтү һ.б.);

- татар теленең алфавитын һәм орфографик кагыйдәләрен белүләре;

- хәзерге татар әдәби теленең семантик төзелешен, лексик берәмлекләрнең килеп чыгышын һәм мәгънәсен аңлаулары;

- татар теленең фразеологик берәмлекләрен сөйләмдә дөрес куллана алулары;

- тел берәмлекләрен сүз төзелеше ягыннан таркату күнекмәләре;

- татар теленең морфологик төзелешен һәм сүзгә морфологик анализ ясый белүләре;

- татар теленең синтаксик төзелешен һәм җөмләгә синтаксик анализ ясый белүләре;

- татар теле тарихыннан хәбәрдарлыгы;

- коммуникатив белем һәм күнекмәләргә ия булулары.

Биремнәрне темаларга бүлү түбәндәгечә тормышка ашырылырга мөмкин:

1) фонетика һәм орфоэпия (хәреф һәм авазларның тәңгәллек үзенчәлекләрен ачыклау, орфоэпик нормаларны куллану, кагыйдәдән искәрмәләрне урынлы файдалану һ.б.);

2) графика һәм орфография (орфографик хаталарны табу; сүзләрнең дөрес язылышын күрсәтү);

3) лексикология һәм фразеология (сүзләрнең лексик мәгънәсен аера белү, фразеологик берәмлекләрнең мәгънәсенә төшенү);

4) лексикография (лексикографик материал белән эшли белү, сүзлекләрнең төзелешен аңлау);

5) грамматика (сүзләрнең грамматик төзелешен тану; сүзгә дөрес морфологик анализ ясау, җөмләдәге синтаксик ролен билгеләү);

6) функциональ стилистика (тел сурәтләү чараларын уңышлы файдалана белү, аларның җөмләдә һәм текстта кулланылыш үзенчәлекләрен тасвирлау);

7) тел тарихы, диалектология (сүзнең килеп чыгышын, мәгънәсен, яңа һәм искергән сүзләрнең кулланылышын аңлау, диалектизмнарның матур әдәбиятта кулланылыш үзенчәлекләрен тоемлау).

Олимпиаданың телдән сөйләм өлешен оештыру һәм бәяләү өчен таләпләр буенча киңәшләр

Рус гомуми белем бирү мәктәпләренең рус телле укучылары өчен үткәрелә торган олимпиада биремнәре ике өлештән тора:

- телдән башкарыла торган өлеше;
- язма рәвештә башкарыла торган өлеше.

Укучының кайсы сыйныфта укуыннан чыгып, олимпиада биремнәрен үтәүнең вакыты билгеләнә. Телдән җавап бирү дә, язма өлешен эшләү дә шул вакыт аралыгында оештырыла, алар параллель алып барыла. Укучыларны, олимпиада башланыр алдыннан, олимпиада эшләрен башкару белән таныштыру мөһим. Эшләр таратылганнан соң, ике укучыга (тыңлау өчен 1 генә комиссия оештырылса) телдән җавап бирергә әзерләнергә тәкъдим ителә (әгәр тыңлау өчен комиссия күбрәк булса, укучылар санын арттырыга мөмкин), алга таба чиратлашып дәвам итәләр.

Олимпиадада катнашучы укучының телдән сөйләмен югары балл белән бәяләү өчен төп таләпләр:

- укучы рәсемгә нигезләнеп, теманы дөрес билгеләгән;
- коммуникатив бурычны дөрес аңлый;
- укучы төзегән текст бербөтен һәм композицион төзек (кереш, төп өлеш, йомгак);
- текст эзлекле;
- мәгънәви бөтенлеккә ия;
- логик хаталар юк;
- сүзлек запасы бай;
- грамматик формаларны урынлы һәм дөрес куллана;
- сөйләмендә сурәтләү чараларын куллана (чагыштырулар, эпитетлар, метафоралар һ.б.);
- сөйләме эмоциональ;
- комиссия биргән сорауларны дөрес аңлап, тулы җаваплар бирә;
- диалогик сөйләмгә күчә.

Укучыларга, 7–9 сыйныфларда рәсемнәр, 10–11 сыйныфларда рәссамнарның (ТР ның танылган рәссамнары) картиналары буенча сөйләү бурычы куела.

7-9 сыйныфлар фотографияләргә нигезләнеп сөйлиләр һәм аларның сөйләменә түбәндәге таләпләр куела. Сөйләм өч өлештән торырга тиеш.

1. Кереш өлеш. Укучы рәсемнең нәрсәне (нинди вакыйганы) чагылдыруын билгели, шуннан чыгып, рәсемгә исем куя. Бу очракта аның сөйләмендә

урынлы кулланылган кереш сүзләр булырга тиеш (минемчә, минем уйлавымча h.б.). Сурәтләнгән вакыйга, күренеш турында мәгълүмат бирә (Язгы көн сурәтләнгән, көн кояшлы. Күк йөзе зәңгәр h.б.)

2. Төп өлеш. Рәсемне өлешләргә бүлеп, детальләрне ассызыклап сөйли: алгы планда ..., сул якта ..., уң якта..., өске якта... . Шул детальләргә үз мөнәсәбәтен чагылдыра.
3. Йомгак. Рәсем нинди тәэсир калдырды? Тормышыгыздагы нинди вакыйгаларны исегезгә төшерде? Рәсемдәге геройлар, вакыйгалар белән алга таба нәрсә булыр дип уйлыйсыз?

Бу моментларны укучыларга олимпиада алдыннан аңлатырга кирәк. Әгәр укучы, сөйләгәндә, әлеге юнәлешкә кереп китә алмаса, сораулар бирергә мөмкин. Укучы сөйләмендә метафоралар, эпитетлар, чагыштырулар булу мөһим.

Рәссамның картинасы буенча сөйләмгә дә шундый ук таләпләр куела. Кереш өлештә, әгәр укучы рәссамны атый алса, берничә җөмлә белән аның иҗатын сурәтли алса, картинадагы вакыйгаларны дөрес атаса, югары балл куела.

Олимпиада татар теленнән сәләтле балаларны сайлап алу, барлау чарасы булганга, тәкъдим ителгән биремнәр телнең төрле берәмлекләре, аларның үзенчәлекләре турында уйландыруны максат итеп куярга тиеш. Укучылар мәктәп программасы кысаларында тупланган белемнәрен татар телен сурәтләгәндә, тирәнтен өйрәнүне таләп итә торган мәгълүматларны табарга, ягъни телне сиземләү алымын куллана белергә тиешләр. Укучылар, күзәтү алымы ярдәмендә тел берәмлекләренә мөстәкыйль анализ ясап, билгеле бер нәтиҗә ясый алуларын күрсәтергә мәҗбүр. Мондый төр биремнәр югары уку йорты дәреслекләреннән алына алмый. Укучы татар әдәби телен һәм үз җирлегендә кулланыла торган диалекталь берәмлекләрнең функциясен, үз тәҗрибәсенә таянып ачыкларга, кулланылыш үзенчәлекләрен тасвирлап бирергә тиеш. Моннан тыш, әлеге төр биремнәрне 4-7 нче сыйныфларга бирмәскә киңәш ителә. Төрле сыйныф укучылары өчен олимпиада биремнәрен төзегәндә, аларның кайсы темаларны үткәнлеген, өйрәнгәнлеген истә тотарга кирәк. Тәкъдим ителгән биремнәрнең эчтәлегенә бәйле материаль-техник яктан тәэмин ителеш исемлеге. Татар теленнән мәктәп һәм муниципаль дәрәҗәдәге олимпиада уздыру өчен, мәктәпнең сыйныф бүлмәләре таләп ителә. Һәр катнашучы сыйныф бүлмәсендә аерым парта артында утырырга тиеш. Республика күләмендә үткәрелә торган олимпиада исә аерым билгеләнгән һәм катнашучыларга алдан ук искәртелеп куелган зур бинада уздырыла. Монда

катнашучылар өчен йокы һәм аш бүлмәләре булу мәҗбүри. Әлеге олимпиада да бер өстәл артында төрле сыйныф укучылары утыртыла, ләкин алар бер үк муниципаль оешмадан булмаулары шарт итеп куела. Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олипиадада җитәрлек дәрәҗәдәге биремнәр саны, аклама һәм каралама өчен кәгазь битләре, авторучкалар, кыстыргычлар һәм степлерлар кирәк. Олимпиадада катнашучыларның рейтингын төзү өчен, MS Excel программасы булган компьютер (ноутбук) куллану киңәш ителә. Материалның тиражын арттыру өчен ксерокс яисә принтер таләп ителә. Олимпиада уздырыла торган бина эчендә барлык кирәкле җиһазлары булган медицина пункты белән дежур табиб булуы шарт. Ул олимпиаданың башлану вакытыннан алып тәмамлануына кадәр бинада булырга мәҗбүр. Муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиаданы уздырганда, нәтиҗәлелекне арттыру максатыннан, укучыларның эшләрен сканлап алу киңәш ителә. Шуның белән бәйле оештыру комитеты кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителергә тиеш.

Татар теленнән Татарстан республикасында уздырыла торган мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиаданың үзенчәлекләрен тасвирлау:

а) олимпиаданы оештыручы комитет һәм жюри;

ә) олимпиаданы уздыру тәртибе һәм формасы;

б) нәтиҗәләр чыгару;

в) өстәмә бәйгеләр һәм бәйгедән тыш чаралар.

Олимпиаданы оештыручы комитет һәм жюри.

4–11 нче сыйныфлар өчен татар теленнән мәктәп күләмендә үткәрелә торган олимпиада ел саен 1 нче ноябрьгә кадәр уздырыла. Олипиада уздыру урыны һәм вакыты белем бирү өлкәсе белән идарә итә торган җирле үзидарә оешмалары тарафынннан билгеләнә. Оештыру комитеты район, шәһәр, мәктәп администрациясе, гуманитар бүлек укытучылары әгъзаларыннан оешырга мөмкин. Жюри әгъзалары татар теле һәм әдәбияты укытучылары һәм әлеге белем бирү оешмалары администрацияләреннән туплана. Мәктәп дәрәҗәсендә уздырыла торган олимпиада шул этапка туры килә торган һәм муниципаль предмет-методик комиссиясе тарафыннан төзелгән, татар теленнән Үзәк предмет-методик комиссиясе тәкъдим иткән методик киңәшләрне исәптә тотып эшләнгән биремнәр буенча уздырыла. Татар теленнән мәктәп күләмендә уздырыла торган олимпиаданың оештыру-техник тәэмин ителеше оештыру комитеты карамагында. Жюри олимпиада биремнәренең эшләнешен бәяли, эшләнгән олимпиада биремнәренә анализ ясый, укучы теләге белән аңа үзе эшләгән эшнең бәяләнешен күрсәтә, видеофиксация кулланып, укучыга

аппеляция уздыра, бүлеп бирелгән квотага һәм нәтиҗәләргә бәйле әлеге этапның җиңүчеләрен билгели. Муниципаль күләмдәге олимпиада ел саен 25 нче декабрьгә кадәр уздырыла. Муниципаль дәрәҗәдәге олимпиаданы уздыруның төгәл вакыты РФ субъектларындагы белем бирү өлкәсе белән идарә итә торган дәүләт оешмалары хакимияте тарафыннан билгеләнә. Муниципаль дәрәҗәдәге олимпиаданы уздыруның төгәл урынын белем бирү өлкәсе белән идарә итә торган җирле үзидарә оешмасы билгели. Әлеге этапның төп максаты — республика күләмендәге олимпиадада катнашыр өчен иң сәләтле һәм көчле балаларны ачыклау. Бу олимпиаданы уздыру өчен оештыру комитеты, предмет-методик комиссия һәм муниципаль дәрәҗәдәге олимпиада жюрие туплана. Оештыру комитетына шәһәрнең, районның, мәктәп администрациясенең метод хезмәткәрләре, гуманитар циклдагы предмет укытучылары керә ала. Предмет методик комиссиягә һәм жюригa мәктәп укытучылары белән беррәттән танылган телче-галимнәр һәм югары уку йортының татар теле кафедрасы методистлары керергә мөмкин. Муниципаль дәрәҗәдә уздырыла торган олимпиада шул этапка туры килә торган һәм региональ предмет-методик комиссиясе тарафыннан төзелгән һәм татар теленнән Үзәк предмет-методик комиссиясе тәкъдим иткән методик киңәшләрне исәптә тотып эшләнгән биремнәр буенча уздырыла. Жюри олимпиада биремнәренең эшләнешен бәяли, эшләнгән олимпиада биремнәренә анализ ясый, укучы теләге белән аңа үзе эшләгән эшнең бәяләнешен күрсәтә, видеофиксация кулланып, укучыга аппеляция уздыра, бүлеп бирелгән квотага һәм нәтиҗәләргә бәйле әлеге этапның җиңүчеләрен һәм призерларын билгели. Республика күләмендәге олимпиада ел саен январь ахыры — февраль башында уздырыла. Республика күләмендәге олимпиаданы уздыруның төгәл вакыты һәм урыны РФ субъектларындагы белем бирү өлкәсе белән идарә итә торган дәүләт оешмалары хакимияте тарафыннан билгеләнә. Әлеге этапның төп максаты — Татарстан республикасында белем ала торган иң сәләтле һәм көчле балаларны барлау. Бу олимпиаданы уздыру өчен оештыру комитеты, предмет-методик комиссия һәм республика күләмендәге олимпиада жюрие туплана. Оештыру комитетына республиканың метод хезмәткәрләре, предмет укытучылары керә ала. Предмет-методик комиссиясә һәм жюригa танылган телче-галимнәр һәм югары уку йортының татар теле кафедрасы методистлары җәлеп ителә. Республика дәрәҗәсендә уздырыла торган олимпиада шул этапка туры килә торган һәм республика предмет-методик комиссиясе тарафыннан төзелгән һәм татар теленнән Үзәк предмет-методик комиссиясе тәкъдим иткән методик киңәшләрне исәптә тотып эшләнгән биремнәр буенча уздырыла. Жюри

олимпиада биремнәренең эшләнешен бәяли, эшләнгән олимпиада биремнәренә анализ ясый, укучы теләге белән аңа үзе эшләгән эшнең бәяләнешен күрсәтә, видеофиксация кулланып, укучыга аппеляция уздыра, бүлеп бирелгән квотага һәм нәтиҗәләргә бәйле әлеге этапның җиңүчеләрен һәм призерларын билгели.

Олимпиаданы уздыру тәртибе һәм формасы

4-11 нче сыйныф укучылары өчен татар теленнән мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендә үткәрелә торган олимпиада төгәл сорауларга яисә билгеле бер лингвистик биремнәргә җавап бирү формасында язмача бер турда уздырыла. Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиаданы үткәрү өчен, берничә сыйныф бүлмәсен бүлеп бирү киңәш ителә. Һәр укучы аерым бер партада утырырга тиеш (республика күләмендәге олимпиадада төрле сыйныф һәм төрле муниципаль оешмалардан килгән укучыларга бер партада артында 1-2 укучы утырырга рөхсәт ителергә мөмкин), ул эш биремнәре һәм канцелярия әсбаплары (кәгазь, ручка) белән тәэмин ителә. Олимпиаданы җирле вакыт белән сәгать 9.00 башлау киңәш ителә. Мәктәп һәм муниципаль дәрәҗәдә үткәрелә торган олимпиада биремнәрен башкарыр өчен киңәш ителә торган вакыт: 4-6 сыйныфлар өчен — 60 минут, 7-8 сыйныфлар өчен 120 минут, 9-11 сыйныфлар өчен — 180 минут. Республика күләмендә уздырыла торган олимпиада биремнәрен башкарыр өчен барлык сыйныфларга да 240 минут вакыт бирелә. Олимпиада башланыр алдыннан, оештыручылар катнашучылар өчен инструктаж, ягъни күрсәтмәләр уздыралар: биремнәрне үтәр өчен күпме вакыт бирелгәнлеге искәртелә, чыгарылган баллар белән риза булмаган очракта аппеляциягә бирү тәртибе белән таныштырыла, олипиадада үз-үзеңне ничек тотарга кирәклеге аңлатыла, шулай ук интеллектуаль ярыш нәтиҗәләре белән кайчан һәм кайда танышып булачагы хәбәр ителә.

Олимпиада вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре:

- биремнәрне үтәү вакытында, катнашучыларның бер-берсе белән аралашырга, бүлмә буйлап йөрергә хокуклары юк. Катнашучы бары тик, дежур укытучы яки вәкил итеп билгеләнгән зат озаткан очракта гына, аудиториядән чыга ала. Бу очракта дежур укытучы эшнең тышкы ягына чыгу вакытын язып куярга тиеш;

- катнашучының аудиториядән олимпиада белән бәйле материалларны (бирем бланкларын, җавап кәгазен, караламаны) алып чыгарга хокукы юк;

- катнашучыга аудиториягә кәгазь, белешмә материаллар, электрон чаралар, диктофоннар, плеерлар, электрон китаплар, фотоаппаратлар, смартсәгатьләр һәм башка шундый техник җиһазлар алып керү катгый тыела;

- татар теленнән мәктәп һәм муниципаль дәрәҗәдәге олипиаданы уздыру тәртипләрен һәм таләпләрен бозган очракта, катнашучыны оештыручы аудиториядән чыгарып җибәрергә хокуклы. Бу очракта әлеге катнашучыны чыгарып җибәрү хакында акт төзелә;

- аудиториядән чыгарылып җибәрелгән катнашучылар әлеге уку елында татар теленнән уздырыла торган олимпиадларда катнашудан мәхрүм ителә.

Татар теленнән мәктәп һәм муниципаль дәрәҗәдә уздырыла торган олимпиаданы оештыру һәм контрольдә тоту өчен, башка предмет укытучыларын җәлеп итү киңәш ителә. Билгеләнгән вакыт чыгу белән, укучыларның эшләре җыеп алына һәм эшләрне кодлаштыра һәм жюри рәисенә тапшыра торган оештыру комиссиясенә тапшырыла. Жюри башкарылган олимпиада биремнәрен тикшерә һәм бәяли. Муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиада биремнәрен тикшергәндә, объектив бәяләү максатыннан, бер үк эшне тулаем бер үк жюри әгъзасы карау киңәш ителми. Бер сыйныфта укучы катнашучыларның эшләрен төркемләп тикшерү уңай һәм гадел нәтиҗәләр бирә. Оештыру комитеты һәр биремгә куелган балларны куша, һәм тулы бер эшнең гомум баллары чыга. Оештыру комитеты рейтинг төзи, тапшырылган эшләрнең кодларын ача, жюри олимпиаданың җиңүчеләрен һәм призерларын билгели. Олипиаданың тиешле этабын уздырганнан соң, белем бирү оешмалары белән идарә итә торган җирле үзидарә органнарының официаль сайтларына, Интернет челтәренә барлык сыйныфлар өчен тәкъдим ителгән биремнәрне элү киңәш ителә. Төгәл биремнәрне күрү, аларны үзлектән эшләп карау катнашучыларның белемнәрен генә арттырмый, ә укучыларның татар теле белән кызыксынуларын да арттыра. Республика күләмендә уздырылган олимпиадада җиңү яулаган һәм призерлар исемлегенә кергән катнашучыларның эшләре Интернет челтәренә эленергә тиеш. Бу исә, беренчедән, жюри әгъзаларына җаваплылык, тәгәллек 17 таләп итсә, икенчедән, катнашучыларга үз эшләрен гадел бәяләүләре хакында дәлил булып хезмәт итә.

Нәтиҗәләр чыгару

Эшләрне тикшереп бетергәннән соң, аларга анализ һәм укучыны нәтиҗәләр белән таныштыру эшләре үткәрелә, шулай ук катнашучыларның апелляциягә биргән эшләре карала. Олимпиадага әзерлек дәрәҗәсен арттыру максатыннан, катнашучыларны нәтиҗәләр белән генә таныштырып калмыйча, алар ясаган хаталарга да күзәтү ясау мөһим. Биремнәрне анализлауның төп максаты — олимпиадада катнашучыларны һәр биремнең җаваплары белән таныштыру гына түгел, шулай ук укучылар ясый торган типик хаталарны

аңлату, бәяләү критерийларын күрсәтү. Олимпиадада катнашучылар, биремнәрне анализлау вакытында, үзләренең эшләрен объектив бәяләү белән бәйле тулы мәгълүматларны алырга тиеш. Нәтиҗәдә, апелляциягә бирелә торган эшләрнең саны күпкә кимиячәк. Олимпиадада катнашучылардан башка дистанцион формада тапшырылган эшләргә анализ ясау киңәш ителми. Жюри олимпиаданы оештыру комиссиясе белән берлектә катнашучыларның апелляцияләрен карый һәм эшләре белән таныштыруны тормышка ашыра. Апелляция уздыруның түбәндәге тәртибә киңәш ителә:

- апелляция олимпиадада катнашучы үзенең олимпиада эшенең нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта уздырыла;

- апелляция тыныч һәм дустанә мохиттә уздырыла;

- олимпиадада катнашучының апелляциясе катгый рәвештә башкарылган олимпиада биремнәренең нәтиҗәләрен игълан иткән көндә уздырыла;

- апелляция уздыруны сорап, олимпиадада катнашучы язмача гариза яза;

- апелляцияне тикшергән вакытта, гариза язган катнашучы үзе генә була, аның үзе белән шәхесен раслый торган документы булырга тиеш;

- апелляция карары нигезендә түбәндәге карарның берсе кабул ителә: апелляцияне кире кагу һәм куелган балларны үз көчендә калдыру, апелляцияне канәгатьләндерү һәм балларга үзгәрешләр кертү;

- олимпиада биремнәрен бәяләү методикасы һәм критерийлары апелляция предметы була алмый һәм кабат тикшерелергә тиеш түгел;

- апелляция буенча карар күпчелек тавыш белән хәл ителә. Тавышлар тәңгәл килгән очракта, жюри рәисе хәл итә торган тавышка ия;

- апелляция карары соңгы булып санала һәм кабат тикшерелми;

- апелляцияне уздыру турында беркетмә тутырыла, жюри һәм оештыру комитеты әгъзалары аңа имзаларын куялар;

- беркетмәгә һәм хисап документларына үзгәрешләр кертү өчен, апелляцияне уздыру турындагы беркетмә жюри рәисенә тапшырыла;

- апелляция уздыру белән бәйле документлар булып түбәндәгеләр исәпләнә: олимпиадада катнашучыларның апелляция үткәрүләрен сорап язган гаризасы; апелляцияне теркәгән журнал (кәгазь бите); апелляцияләрнең беркетмәләре.

Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиадага түбәндәгечә нәтиҗәләр ясала: иң югары балл туплаган катнашучылар җиңүче булып санала. Ләкин аларга биремнәр өчен куелган гомум баллның яртысыннан артыгын җыю шарт булып тора. Призлы урыннарга ия булган катнашучыларның саны квотадан чыгып билгеләнә. Әлеге санны шул этаптагы

олимпиада оештыручылары билгели. Бер үк балл туплаган катнашучылар саны квота санынан артып киткән очракта, әлеге катнашучыларның язмышын жюри әгъзалары хәл итә. Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендә үткәрелә торган олимпиаданың җиңүчеләре һәм призерлары оештыручылар тарафыннан раслана. Мәктәп һәм муниципаль күләмдә үткәрелә торган олимпиада җиңүчеләре һәм призерлары дипломнар белән бүләкләнә, алар олимпиадның алдагы этабында катнашу хокукына ия булалар. Республика күләмендә үткәрелә торган олимпиада җиңүчеләре һәм призерлары дипломнар белән бүләкләнә. Алар акчалата премиягә тәкъдим ителә.

Өстәмә бәйгеләр һәм бәйгедән тыш чаралар

Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендә үткәрелә торган олимпиада кысаларында укучының татар теленнән төрле күнекмәләрен үстерә торган өстәмә бәйгеләр уздырылырга мөмкин. Әлеге төр ярышларда җиңү укучыга олимпиаданың алдагы этапларында катнашырга хокук бирми, олимпиада эшен бәяләүдә дә исәпкә алынмый, ләкин татар телен тагын да ныгытып өйрәнүгә этәргеч булып хезмәт итә ала. Мондый төр чараларга түбәндәгеләрне кертергә мөмкин: ораторлар бәйгесе, татар теле белгечләре бәйгесе, шагыйрьләр турниры, рефератлар, проектлар яклау, алдан билгеләнгән тема буенча сочинение яисә эссе бәйгесе, рус телендәге текстны татар теленә иң яхшы тәрҗемә итүчеләр бәйгесе һ.б. Язма эш белән бәйле бәйгеләрне бәяләгәндә, түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алырга кирәк: фикерне дәлилли белү, логик эзлеклелек, композицион төзеклек, сәнгатьлелек, грамоталылык, чыгыш ясау формасы һәм сыйфаты. Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендә үткәрелә торган олимпиада кысаларында бәйгедән тыш чаралар да уздырылырга мөмкин: экскурсияләр, китап күргәзмәсе, стенгазеталар белән таныштыру, лингвистик уеннар, сөйләм культурасы белән бәйле дискуссияләр оештыру һ.б.

Һәр бала үзенчә талантлы. Аның сәләтен, мөмкинлекләрен ачу, үстерү һәм тормышта кулланырга өйрәтү — бүгенге мәктәпнең төп бурычларыннан берсе. Сәләтле балалар белән эшләүдә күптөрле алымнар кулланырга мөмкин. Тырышып, үз вакытыңны кызганмыйча эшләсәң генә, укучыларыбыз зур нәтиҗәләргә ирешер.

Укучыларны фән олимпиадаларына әзерләү түбәндәге этаплардан тора:

1. Аерым фәннәр буенча сәләте һәм кызыксынуы булган укучыларны ачыклау. Аларга сәләтенә, кызыксынуына карап, дөрес юнәлешне (фәнне) сайлату. Бу эшне, әлбәттә, түбән сыйныфлардан ук башларга кирәк.
2. Укучыларны олимпиада хәрәкәтенә кертү. Укучыларны мәҗбүри рәвештә олимпиадада катнаштырып булмый. Аларны күбрәк кызыксындыру өчен, укытучының үз фәнен камил белүе, остаз гына түгел, укучы өчен абруйлы киңәшче булуы, өстәмә вакытын кызганмавы мөһим.
3. Олимпиадага әзерлек.

Фән олимпиадаларында катнашу укучыларга аерым фәннәр буенча белемнәрен тирәнәйтергә мөмкинлек бирә. Укытучы һәрбер сыйныфта үз фәне буенча кызыксыну һәм башкалардан яхшырак нәтиҗәләр күрсәткән 3-5 баладан торган төркем булдыра. Әлеге төркем белән дәресләрдән тыш өстәмә шөгыльләнү кирәк була.

Төп таләпләр:

- укучыларны әзерләү уку елы башыннан ук башланырга тиеш;
- теория бирүгә түгел, укучыларның ижади мөмкинлекләрен үстерүгә күбрәк игътибар итәргә кирәк;
- һәрбер балага индивидуаль якын килү;
- диагностика үткәрү;
- баланы логик фикерләргә, эзләнү эшчәнлегенә, белемнәрне стандарт булмаган ситуацияләрдә кулланырга өйрәтү.

Олимпиада — бер тапкыр гына үткәрелә торган чара түгел, еллар дәвамында планлаштырылган һәм системалылык таләп ителгән тынгысыз хезмәт. Укучыларны фән олимпиадаларына әзерләү эзлекле план буенча башкарылырга тиеш:

- норматив-хокукый документларны өйрәнү;
- аерым предмет буенча укучыларның мөмкинлекләрен ачыклау максатыннан анкета үткәрү;
- укучыларны олимпиадага әзерләү буенча программа төзү;
- факультатив, сайлап алу курслары оештыру;
- фән атналыгы кысаларында мәктәп олимпиадалары, бәйгеләр, брейн-ринглар һ.б. оештыру;
- дистанцион олимпиадаларда катнашу;
- муниципаль һәм республика олимпиадаларында катнашу;
- педагогик кадрлар белән эш: тәҗрибә уртаклашу максатыннан семинар, түгәрәк өстәлләр һ.б. үткәрү;

- ата-аналар белән эш: «Сәләтле балаларның психологик үзенчәлекләре» кебек темаларга лекцияләр, әңгәмәләр үткәрү;
- мониторинг алып бару.

Фән олимпиадаларында катнашу укучыларга:

- мәктәп, район, хәтта республика данын якларга мөмкинлек бирә, патриотик хисләр тудыра;
- түбән сыйныфлардан ук фән белән кызыксыну уята;
- олимпиада биремнәренең кайбер өлешләре («Кенгуру», КИТ, «Русский медвежонок», «Зирәк тиен») тест формасында бирелеп, укучыларны тест белән эшләргә өйрәтә, БДИга әзерләү өчен ярдәм итә;
- һәрбер катнашучы, сертификат, диплом белән бүләкләнеп, портфолиосын тулыландыра.

Сәләтле балалар белән эшләүдә күптөрле алымнар кулланырга мөмкин. Тырышып, үз вакытыңны кызганмыйча эшләсәң генә, укучыларыбыз зур нәтиҗәләргә ирешер.

ФДББС мәктәптә белем бирү процессына, шул исәптән дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруга да яңа таләпләр куя. Федераль дәүләт стандартлары шартларында белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программасы дәрестә укыту эшчәнлеге һәм дәрестән тыш эшчәнлек аша дәүләт санитар-эпидимиологик кагыйдәләрне һәм нормативларны үтәп тормышка ашырыла (СанПиН 2.4.2.2821-10, 2015 елның 24 ноябрь редакциясендә).

Төп гомуми белем бирүнең ФДББС шартларында дәрестән тыш эшчәнлек түбәндәге норматив документлар һәм материалларга нигезләнеп оештырыла:

- Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының “Гомуми белем бирү федераль дәүләт белем бирү стандартларын керткәндә дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру турында” хаты,12 май 2011 ел, № 03-296;
- СанПиН 2.4.2.2821-10 “Гомуми белем бирү оешмаларында укыту шартларына һәм укытуны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр”;
- СанПиН 2.4.4.1251-03 “Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр”;
- Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының “Гомуми белем бирү оешмаларында тәрбия бирү компонентын үстерү Программасының юнәлеше турында” хаты, 13 май 2013 ел, № ИР-352/09;
- Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының “Гомуми белем бирү оешмаларында тәрбия бирү компонентын үстерү Программасын тормышка ашыруда чаралар исемлеген формалаштыру буенча тәкъдимнәр турында” хаты, 12 июль2013 ел, № 09-879;

- Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының “Дәрестән тыш эшчәнлек һәм өстәмә гомуми белем бирү программасын тормышка ашыру турында” хаты, 14 декабрь 2015 ел, № 09-3564.

Дәрестән тыш эшчәнлек — дәрестә уку эшчәнлегеннән кала укучыларны тәрбияләү максатына юнәлдерелгән барлык эш төрләре.

Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыруга ФДББС түбәндәге таләпләрне куя:

- дәрестән тыш эшчәнлек мәктәптә төп белем бирү программасының аерылгысыз өлеше;

- мәктәпнең төп белем бирү программасы составына кертелә;

- ФДББС таләпләрен тулысынча тормышка ашыруга ярдәм итә;

- программаның әлеге өлешенә караган эчтәлекне тутыру белем бирү учреждениесенең үз компетенциясендә;

- төп белем бирү стандартларын тормышка ашыру юлында белем бирү процессын оештыру формаларын сайлауны, дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлекне чиратлаштыруны белем бирү оешмасы үзе билгели;

- дәрестән тыш эшләр өчен сәгатьләр билгеләү укучылар теләгеннән (мөмкинлегеннән) чыгып эшләнелә.

Мәктәптә дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруның төп максаты — укучыларның кызыксынуларын, сәләтләрен һәм ихтыяҗларын канәгатьләндерелек шартлар тудыру һәм аларның буш вакытларын дөрес оештыру, шуның нигезендә тәрбияләү һәм социальләштерү максатына ирешү.

Олимпиада — теге яки бу предмет буенча класстан тыш массакүләм чаралар арасында иң киң кулланылыштагы төр. Ул укучыларны яңа заман шартларында һәм, иң мөһиме, конкуренция шартларында яшәргә өйрәтергә булыша. Бүгенге көндә укучыларның олимпиадаларда катнашу нәтиҗәләре мәктәптә, шәһәрдә, республикада белем бирү дәрәҗәсен ачыклый торган бер критерий булып тора, укытучының эшчәнлек дәрәҗәсен бәяләргә ярдәм итә.

Татар теле һәм әдәбияты буенча укучыларны олимпиадага әзерләү буенча киңәшләр Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 нче елның 18 нче ноябрендә 1252 нче номерлы (2015 нче елның 17 нче мартында кертелгән үзгәрешләр белән (249 нчы әмер) әмере белән расланган “Порядок проведения Всероссийской олимпиады школьников” (“Укучылар өчен Бөтенроссия олимпиадасын үткәрү тәртибе”), Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының “Укучылар өчен бөтенроссия һәм республика олимпиадаларының мәктәп этабын уздыру турындагы” боерыгы, (Приказ МОиН РТ от 02.09.2015 № под-9237/15 “О проведении школьного

этапа всероссийской и республиканской олимпиад школьников в 2015/2016 учебном году"; Приказ МОиН РТ от 09.10.2015 № под-9402/15 "О проведении муниципального этапа всероссийской и республиканской олимпиад школьников в 2015/2016 учебном году") нигезендә эшләнде.

Укучыны олимпиадага әзерләү нигезендә системалылык, эзлеклелек ятарга тиеш: мондый төр ярышларга укучыны башлангыч сыйныфлардан ук әзерләү мөһим. Өченче сыйныфта мәктәп күләмендә еллык олимпиадалар уздырып карарга мөмкин. Призлы урыннарга лаек булган укучылар параллель сыйныфта белем алган җиңүче балалар белән үзара көч сынашалар. Жюри һәр катнашучының эшен тикшерә, анализ ясый һәм төрле номинацияләр буенча җиңүчеләрне билгели, мәсәлән, "Татар теленең иң яхшы белгече", "Иң яхшы филолог" һ.б. Олимпиадада катнашкан укучы үз җиңүләрен, төрле бәйгеләрдә катнашкан мәгълүматларны бер папкага туплап барса, алга таба кулайрак була.

Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар теленнән республика олимпиадасы 3 этапта уздырыла: мәктәп, муниципаль һәм республика турлары.

Алга таба җыентыкта рус телендә гомуми белем бирү мәктәпләрендә татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүче укучыларны олимпиадага әзерләү өчен татар теленнән мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиадаларны биремнәр тәкъдим ителә. Биремнәр, нигездә, коммуникатив характерда булып, беренче өлешендә телдән сөйләм тикшерелә. Икенче өлеше язма рәвештә башкарыла һәм олимпиадада катнашучыларга төрле дәрәҗәдәге интерактив биремнәр тәкъдим ителә.

4 НЧЕ СЫЙНЫФ

1. Напишите правильные сравнения.

Куян кебек _____

Төлке кебек _____

Фил кебек _____

Гепард кебек _____

Жираф кебек __ _____

Бүре кебек _____

Слова для выбора: тиз, усал, озын, хәйләкәр, куркак, зур.

2. Запишите синонимы к выделенным словам.

Урамнан **матур** кыз үтеп бара. _____

Мин **бәләкәй** көчек күрдем. _____

Без абыем белән бик **тату.** _____

3. Продолжите предложения.

1) Мин кышны бик яратам, чөнки _____

2) Безнең бакчада _____

4. Запишите подходящие по смыслу слова.

ак _____ салкын _____ куркак _____

куе _____ кыска _____ биек _____

тырыш _____ тәрбияле _____

5. Составьте предложения и запишите.

1) син барасыңмы, бәйрәмгә, бүген?

_____

2) мәктәп, безнең, янында, бар, кибет.

_____

3) Алия, белән, китапханәдә, очрашты, дусты.

_____

6. Прочитайте текст и определите (подчеркните правильный ответ), какие из приведённых ниже утверждений соответствуют содержанию текста, какие не соответствуют.

Яңа чана

Раиләләрнең ишегалдында балалар бик күп. Алар бер-берсен бик яраталар, бергә төрле уеннар уйныйлар. Быел кыш зур тау ясадылар. Балалар анда көн саен шуарга киләләр. Һәр баланың чанасы бар, Раиләнең генә юк. Ул урамга чыккач, дуслары йөгереп киләләр дә аңа үз чаналарын бирәләр, чөнки Раиләнең дә шуасы килә.

Беркөнне Раиләнең әтисе кибеттән яңа матур чана алып кайтты. Раилә бик шатланды. Әтисе аңа чанасын саклап шуарга кушты. Раилә чанасын алып ишегалдына чыкты. Балалар: «Раиләнең дә чанасы бар!» — дип шатландылар. Үз чанасы булгач, Раиләгә бик күңелле иде, хәзер ул да көне буе чана шуа ала. Бераздан аның янына күрше малае Илдар килде.

– Раилә, чанаңны бирәп тор әле, минем дә шуасым килә, — диде. Кыз аңа:

– Кит, кит! Бирмим, я ватарсың, — диде дә үзе шуа башлады, ә Илдар читкә китте. Балалар, бу сүзләрне ишеткәч:

– Ул чанасын кызгана, саран, — дип кычкырдылар. Раиләгә бик оят булды. Ул Илдар янына килде, аңа чанасын бирергә теләде. Тик малайның аңа карыйсы да, яңа чанада шуасы да килмәде. Ә Раиләгә бик күңелсез булды. Ул хәзер нигәдер яңа чанага шатлана алмый иде. *(Р. Ишморатовадан)*

Текст батырлык турында.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

Раилә — юмарт кыз.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

Текстта кышкы уеннар турында сүз бара.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

Балалар Раиләгә үз чаналарын биреп тордылар.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

Саран кешеләрне яратмыйлар!

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

7. Какая пословица подходит к сюжету текста?

☐ Батыр бер үләр, куркак мең үләр.

☐ Саран, тапса, яшереп ашый.

☐ Күп укыган, күп белгән.

8. Озаглавьте рисунок. Запишите слова, отвечающие на вопросы *кем? нәрсә?*

II вариант

1. Образуйте сложные слова, соединив два слова в одно.

АШ, ТАШ, БОДАЙ, КУЛ, ТӨН, КОШ, БАКА, ЯУЛЫК, ЯК, КАРА, АК, ХАНӘ

2. Напишите вопросы, ответами на которые являются следующие предложения.

1) — _____

— Мин аның “Нечкәбил”, “Куян кызы” әкиятләрен бик яратам.

2) — _____

— Без өйдә өчпочмак, бәлеш, чәк-чәк пешерәбез.

3) — _____

— Аны бит әнием пешерде, шуңа күрә бик тәмле!

4) — _____

— Юк, күз яшьләре шатлыктан да агалар бит алар...

3. Расставьте предложения в нужном порядке, чтобы получился связной текст (укажите последовательность в цифрах).

№	Предложения
	Үзе кечкенә булса да, тавышы бик еракларга ишетелгән, ди.
	Шулай беркөнне бу бака су астыннан өскә күтәрелгән һәм тирә-якны яңгыратып бакылдарга керешкән.
	Үрдәк баканың бакылдавын мактарга тотынган.
	Үрдәкнең борынына менеп атланган.
	Түгәрәк күл буенда, камышлыклар төбендә яшәгән, ди, бер бакылдык бака.
	Бака бик шатланган, тагын да күбрәк бакылдаган.
	Шулвакыт камышлар арасында йөзеп йөргән үрдәк, баканың тавышын ишетеп, аның янына ашыккан.
	Ул көн-төн мактанган: «Бакка-как-как, мине эзләп тап! Миннән оста җырчы, биюче юк. Исемем — Бакылдык, үзем бер батам, бер калкам»,— ди икән.
	«Кил әле, борыным өстенә мен әле. Колакларым катырак, җырыңны бик ишетәсем килә»,— дигән үрдәк. Бака бик шатланган.
	Җырларга дип авызын ачуы булган — үрдәк баканы капкан да йоткан.

4. Являются ли данные высказывания верными? Поставьте знак «+» или «–» в соответствующей ячейке в бланке ответов.

№	Җөмләләр	«+» яки «–»
1	Габдулла Тукай, Абдулла Алиш, Максим Горький — татар язучылары.	
2	Сандугачлар һәм карлыгачлар көзен җылы якларга очып китәләр.	
3	Җидене бишкә тапкырлагач, утыз җиде була.	
4	“**Сәгать**” сүзендә 6 хәреф, 6 аваз	
5	“**Чана**” сүзе ачык иҗекләрдән генә тора.	

5. Определите корень слова.

Сазлык — _____

Суыткыч– _____

Авылдаш — _____

Көзге — _____

6. Напишите татарские народные пословицы о Родине.

7. Прочитайте текст и вставьте пропущенные окончания.

Куян баласы

Алия дәү әнисе белән йөрергә ярата. Алар болын____ да, басу___ да гел бергә баралар. Бүген басу___. Алия куян баласы күрде. Куян баласы ни өчендер качма___. Алия тиз генә аны колакларын___ тотып алды. Куян баласы Алия___ кулларыннан сикереп төшәргә тырышты. Ниһаять, ул арды, тынычланды. Куян баласы йөри алмый, аның аяк___ авырта икән. «Дәваларбыз», — диде әбисе. Алар куян бала___ өй___ алып кайттылар. Алия аны бүлмә___ җибәрде, ә ишек___ япты.

Берничә көн___ куян баласы сикерә, йөгерә, керт-керт итеп кәбестә яфраклары ашый башлады. Әй шатланды Алия!

Ә беркөн___ ул ялгыш ишек___ ачык калдырды. Йөгереп кайтты, бүлмәдән куян баласын эзли башлады — таба алмады. Кыз елап җибәрде.

– Елама, кызым,– диде әбисе.– Инде аның аяклары төзәлде. Куян баласы хәзер элеккечә йөгерә ала, ул әнисе янына урманга китте. Сиңа рәхмәт әйтте. Хайван___ ирек яраталар бит алар.

Йомшак куян баласы әни___ сагынган. Алия моны аңлый иде. Ул алар___ очрашуы турында уйлады. *(З. Гомәровадан)*

8. Выберите наиболее подходящую для текста «Куян баласы» пословицу.

□ Сыерчык диңгез артына китсә дә үз туган оясына кайта.

□ Үз анасын зурлаган, кеше анасын хурламас.

□ Сүзнең тозы мәкаль.

□ Батырлыкта матурлык.

9. Составьте и запишите рассказ по его началу.

Марат балык тотарга бик ярата. Менә беркөнне иртән ул инешкә балык тотарга килде. Бервакыт …

II вариант

I часть

Назовите предметы на рисунке.



Составьте диалог на одну из предложенных тем (работа в парах)

Диалог маленькой девочки с матерью о волке.

Разговор мамы со своими дочерьми о зоопарке.

Диалог маленькой девочки со львом.

Диалог льва и зебры.

II часть

1. Напишите, что объединяет эти предметы.

Образец: автобус, йөк машинасы, троллейбус — транспорт.

1) песи, эт, ат, сыер — ... ;

2) Казан, Мәскәү, Лондон, Түбән Кама — ... ;

3) суган, кишер, бәрәңге, кыяр — ... ;

4) алма, чия, груша, виноград — ... .

2. Составьте словосочетания.

кызу	утыра
авыр	йоклый
тыныч	бара
туры	аңлый

3. Найдите прилагательное в превосходной степени.

1) белемле

2) бик белемле

3) белемлерәк

4) белемсез

4. Как называют человека, который ... ?

Образец: Очучы самолет йөртә.

1) ... поезд йөртә.

2) ... балалар укыта.

3) ... йортлар төзи.

4) ... кешеләрне дәвалый.

5. Найдите продолжение предложения.

Мин юл аркылы чыктым, чөнки ... .

1) анда машиналар күп.

2) анда кешеләр йөри.

3) светофорда ут янды.

4) светофорда яшел ут янды.

6. Верните слово(послелог) *саен* в предложение.

1) Абыем әтием ... тырыш.

2) Яздан ... яңгыр юк.

3) Көн ... дәү әниемә шалтыратам.

4) Дусларым ... музейга бардык.

7. Найдите лишнее слово.

1) тамаша

2) зал

3) сәяхәт

4) сәхнә

8. В какой последовательности нужно расставить предложения, чтобы получился текст?

А. Ул ап-ак, колаклары гына кара.

Ә. Без аның белән бик дус, ул мине көн саен мәктәпкә озата.

Б. Мин аны бик яратам, чөнки ул акыллы, җитез.

В. Минем этем бар.

1) А, Б, В, Ә.

2) Ә, Б, В. А.

3) Б, А, В, Ә.

4) В, А, Б, Ә.

9. Переведите.

Сегодня какая погода? Сегодня ясная, холодная погода. Книга где? На столе. Автобус куда едет? В Москву. Ты что делаешь? Дедушка что делал?

10. Напишите рассказ из 6-8 предложений о зимних играх.

5 НЧЕ СЫЙНЫФ

I вариант

1. Соедините вопрос из левой колонки с соответствующим ответом из правой, ответ пиши цифрами, *напр.: 1 — 4*

1) Китап күпме тора?	1) Апамныкы.
2) Автобус кайчан китә?	2) Йөз илле сум.
3) Сиңа нәрсә эшләргә кирәк?	3)15 минуттан.
4) Бу кемнең урыны?	4) Дәрес хәзерләргә.

2. Напишите 4 предложения о том, что ты хочешь сделать в выходные.

3. Выберите корни от которых можно образовать новое слова аффиксами – даш//-дәш, -таш//-тәш и образуй. Составьте предложения.

1) район

2) салкын

3) озын

4)сыйныф

4. Верните слово (послелог) *шикелле* в предложения

1) Быел көз яз ... .

2) Дәрестән ... өйгә кайттым.

3) Апам әнием ... матур.

4) Атна ... бакчага барабыз.

5.Составьте предложения из данных слов.

1) Мин/ авыл/ сабантуй/ кайт.

2) Без/ гаилә/ биш/кеше.

3) Мәктәп/Чыршы/ бәйрәм/ кызыклы/ бул.

4) Без/ кыш / уен/ бик/ ярат.

6. В каком предложении глагол стоит в прошедшем времени?

1) Марат дусларын туган көненә чакыра.

2) Марат дусларын туган көненә чакырмый.

3) Марат дусларын туган көненә чакырамы?

4) Марат дусларын туган көненә чакырды?

7. Найдите правильный перевод предложения:

Балалар монда көн саен кошларны ашатырга киләләр.

1) Дети там весь день птиц кормят.

2) Дети там каждый день кормили птиц.

3) Дети сюда каждый день приходят кормить птиц.

4) Дети сюда каждый день ходили кормить птиц..

8. Найдите слово, отвечающее на вопрос *кая*?

1) кунакта;

2) кешегә;

3) агачта;

4) мәктәпкә.

9. Переведите текст.

1) Татарстанның башкаласы — Казан. 2) Казан — тарихи шәһәр. 3) Анда күп милләт кешеләре дус яши. 4) Казанга төрле илләрдән туристлар килә. 5) Казан Кремле — бик борынгы архитектура һәйкәле.

10. Напишите середину текста.

Җәйге каникул өч ай була. ..... .

..... .

Беренче сентябрьдә мәктәптә укулар башлана.

II вариант

1. Продолжите сравнения.

Бүре кебек _____

Куян кебек _____

Төлке кебек _____

Эт кебек _____

Ишәк кебек _____

Фил кебек _____

Жираф кебек _____

Сүзләр: хәйләкәр, куркак, кире, усал, тугры, озын, зур.

2. Прочитайте текст и вставьте пропущенные окончания.

Куркак юлдаш

(татар халык әкияте)

Ике иптәш юл___ чыкканнар, ди. Болар зур урман аркылы үткәннәр. Урман___ кергәч, болар____ каршысына кинәт кенә бер Аю килеп чыккан. Моны күргәч, болар___ берсе, бик куркып, агач баш___ менеп качкан. Икенчесе, үлгән булып, тиз генә сузылып яткан.

Аю бу юл___ ятк___ кешенең, баш___ , аякларын иснәгән дә һәм үз юлы___ киткән, ди.

Аю киткәннән соң, теге кеше, агач башын___ төшеп, иптәше___ сораган:

– Аю син___ колагы___ нәрсә әйтте? — дигән. Бу кеше әйткән:

– Аю миңа, моннан соң шушындый куркак кеше белән юлга чык___, дип әйтте, — дигән.

---

3. Выберите наиболее подходящую для текста «Куркак юлдаш» пословицу.

□ Куркак кеше үз күләгәсеннән дә курка.

□ Куркакны юлдаш итмә.

□ Юл бер адымнан башлана.

□ Юл сорашып табыла.

---

4. Напишите цифрами.

Унтугыз — _____

Сиксән биш — _____

Ике йөз алтмыш җиде — _____

Өч мең биш йөз егерме биш — _____

5. Заполните таблицу.

Салих Сәйдәшев, Муса Җәлил, Габдулла Тукай, Фәрит Яруллин, Илһам Шакиров, Сара Садыйкова, Абдулла Алиш, Бакый Урманче, Әлфия Афзалова, Харис Якупов, Роберт Миңнуллин, Шәүкәт Галиев

Шагыйрьләр, язучылар	Композиторлар	Җырчылар	Рәссамнар, сынчылар

6. Определите корень слова.

Тозсыз — _____

Акыллы — _____

Биюче — _____

Тотка — _____

Язгы — _____

7. Докажите, что эти слова являются омонимами (приведите примеры).

Кара, атлас, көзге

8. Напишите татарские народные пословицы о дружбе.

9.Составьте и запишите рассказ по его началу. *(10 предложений)*

Көзнең матур бер көне. Данис әтисе белән урманга гөмбә җыярга килделәр. Гөмбә эзләп йөргәндә кинәт …

6 НЧЫ СЫЙНЫФ

I вариант

1. Прочитайте текст, выберите наиболее подходящий для него заголовок и подчеркните его.

A. Канатлы кунак

B. Каргалар килде

C. Безнең йорт

Безнең йорт шәһәр читендәрәк. Ишегалдында биек агачлар үсә. Агач башында ел саен каргалар оялый.

Бервакыт агачтан карга баласы егылып төшкән иде. Кыяфәтен караганда, бер явызның кулы уйнаганга охшый. Югыйсә аягы да, канаты да имгәнмәс иде. Сыңар канатын җиргә бәргәләп, карга баласы юкә төбендә ята. Тирәсендә дүрт-биш малай. Нишләтергә дә белмиләр. Ул арада якында гына «карр, карр» дигән

тавыш ишетелде. Карасалар, юан ботакка карга килеп кунган. Муенын түбәнгә — карга баласына таба сузган. Күрәсең, әниседер. Малайларга ямансу булып китте. Аларның карга баласын бу килеш калдырасылары килми иде.

(Г.Шәрәфидән)

2. Продолжите рассказ и напишите небольшое сочинение (5 предложений).

3. Расставьте реплики в нужном порядке (укажите последовательность в цифрах), чтобы получился диалог.

№	**Предложения**
	Мин кичә сиңа шалтыраткан идем. Әниең сине грипп белән авырый диде. Әгәр теләсәң, мин сине табибка илтә алам.
	Рәхмәт, син — чын дус!
	Сәлам, Алсу! Синең хәлләрең ничек?
	Ярый.
	Берни дә түгел. Алайса, әйдә, киттек.
	Хәзер бераз яхшырак. Соравыңа рәхмәт.
	Бик әйбәт булыр иде. Бик зур рәхмәт сиңа, Марат.
	Һәрвакыт мөрәҗәгать ит.

4. Допишите пропущенные слова в следующих пословицах.

№	**Предложения**
1.	Дусны табу җиңел, саклавы _____ *(ничек?)*.
2.	Уйнап сөйләсәң дә, _____ *(ничек?)* сөйлә.
3.	Һөнәр ашарга сорамый, үзе _____ *(нишли?)*.
4.	Башланган _____(*нәрсә?*) — беткән эш.
5.	Бер галим _____*(күпме?)* наданны җиңәр.

5. Переведите на татарский язык и запишите.

1. Я горжусь успехами своего друга.
2. Эти люди желают тебе добра.
3. Мне нужны некоторые сведения об истории этого театра.
4. В жизни каждого человека бывают счастливые события.
5. Ты уже поговорил с родителями о поездке в Санкт-Петербург?
6. Если хотите, я вам принесу эту статью.
7. Какая самая популярная передача среди молодёжи?
8. Она взяла лист бумаги и начала рисовать.

6. Допишите окончания слов в предложениях.

№	**Предложения**
1.	9 декабрь — Хәсән Туфан____ туган көн____.
2.	Урал_____ заводта эшли, Уфа____ укый, Урта Азия һәм Кавказ буйлап җәяүләп сәяхәт итә, гомер_____ 16 ел_____ сөргендә уздыра.

3.	Татар әдәбият____ дәреслек_____ аның шигырь_____ җиңел генә эләкмәгән.
4.	Аларның халык_____ барып ирешү юл_____ Моабит дәфтәр_____ тарих_____ охшаш.
5.	1940 ел_____ 18 ноябрь_____ Хәсән Туфан_____ кулга алалар.
6.	Ул башта үлем_____, аннан гомерлек сөрген_____ хөкем ителә.

7. Переведите на русский язык и запишите.

1) Иртәгә, 9 декабрьда, Татарстан территориясендә төнлә һәм көндез урыны белән томан төшәчәк.

2) Үзегезнең әти-әниегезгә тыныч йокы теләгез.

3) Һәркем үз тамырларын белергә тиеш.

4) Габдулла Тукайның «Туган тел» шигырен искә төшерегез.

5) Кайбер карлыгачлар Көнчыгыш һәм Көньяк Африкага очып китәләр.

8. Прочитайте текст и вставьте нужны слова

Имбир — _____ яшел тропик үсемлек. Дәвалау _____имбирнең чи тамыры _____киптереп вак итеп төелгән тамырының порошогы кулланыла. Имбирне борынгы заманнардан _____ үстерәләр. Хәзер Кытай, Корея, Малазия, Индия аны _____ күләмдә җитештерә.

Имбир — ачы _____ хуш исле тәмләткеч, шул ук вакытта _____ нәтиҗәле дәвалау чарасы да. Үсемлекнең вакланган чи тамырын су парында тотып куу ысулы _____ эфир мае ясала. Ул ислемай, косметик әйберләр эшләп чыгаруда _____ кулланыла.

Имбир Якын Көнчыгыш кухнясында бик популяр, _____иттән, яшелчәләрдән, оннан хәзерләнгән ризыкларга һәм, шулай ук, төрле эчемлекләргә кушалар.

Имбир составындагы бик күп биологик актив матдәләр организмны тукландыралар, _____ашаган ризыкны эшкәртүне һәм үзләштерүне яхшырталар, имбирдә ашказаны, эчәкләрнең, ашказаны асты бизенең эшчәнлеген стимуллаштыра _____матдәләр бар. Шул сәбәпле, имбир тамыры ашкайнату әгъзалары авыруы _____нәтиҗәле дәвалау чарасы булып тора.

бик
бирле
ярдәмендә киң
аны
яисә
күп
чөнки
өчен
вакытында
торган мәңге
һәм

9. Установите соответствие между словом и его лексическим значением.

А. Сөйкемле **Ә.** Әхлак **Б.** Тыйнак **В.** Мәрхәмәт	**1.** Кешеләрнең җәмгыятькә һәм бүтән кешеләргә карата мөнәсәбәтләре. **2.** Яхшылык, игелек итү. **3.** Күңелгә ошый торган. **4.** Үзен мактарга, күрсәтергә тырышмаучан, әдәпле. **5.** Яхшы тәрбия алган.

А	Ә	Б	В

II вариант

1. В каком слове не пишется[ө]?

1) т...ньяк;
2) й...рәк;
3) с..ңел;
4) с...лге.

2. Соберите слова, соединив части столбиков. Напишите перевод.

1) ак	1) як
2) кул	2) юлы
3) берь	3) бур
4) көн	4) яулык

3. Напишите, что объединяет эти предметы, названия.

Образец: чәйнек, кашык, тәлинкә — савытлар.

1) бүре, аю, төлке — ...;
2) 1, 20, 100 — ...;
3) дүшәмбе, чәршәмбе, җомга — ... ;
4) табиб, эшче, укытучы — ... .

4. Соедините слова в высказывании.

Образец: чәй, күзлек, гәҗит — Бабай чәй эчте, күзлеген алды һәм газета укыды.

1) мәктәп, дус, өй эшләре;
2) укытучы, укучы, диктант;
3) әни, табиб, дару;
4) урам, тукталыш, трамвай.

5. К явлению природы допишите возможное действие, процесс. *Образец: томан төшә*

1) җил ...
2) яңгыр ...
3) боз ...
4) кар ...

6. В каком предложении глагол стоит в неопределенном (неконкретном) прошедшем времени?

1) Көн саен иртән без кибеткә сөткә барабыз.
2) Апам театрга билетлар алган.
3) Ярышлар ял көне сәгать унда башланырга тиеш.
4) Сабантуйда уйнаган уеннар безгә бик ошады.

7. Раскройте скобки, ставьте в нужном падеже.

(Дустым) бик акыллы эте бар.

(Җылы як) кошлар кайта.

Мин (бакча) чәчәкләр утырттым.

(Мин) чаңгы шуарга ярамый.

8. Напишите 5 правил на каждый день: что нужно делать?

9. Переведите стихотворние в свободной форме.

Я люблю, когда при встрече
Мы знакомым и родным:
“С добрым утром”, “Добрый вечер”,
“Доброй ночи” — говорим.
Это теплое, с любовью
Пожелание здоровья,
Пожелание добра.

(А.Яшин)

10. Напишите другу (подруге) приглашение на день рождение (4-6 предложений).

7 СЫЙНЫФ

I. Устная часть

1. **Напишите рассказ по картине.** (6-8 предложений).



II часть

1. Допишите характеризующие месяц фразы.

Образец: Октябрь ае — көз башлана.

Февраль ае — ... .

Декабрь ае — ... .

Сентябрь ае — ... .

Ноябрь ае — ... .

Май ае — ... .

2. Составьте предложения.

1. тешләреңне, көнгә, мәртәбә, чистарт ике. 2. тараргa, яхшылап, чәчеңне, онытма. 3. чиста, тиеш, киемең, булырга, аяк киемең. 4.онытма, ешрак, сабынлап, юарга, кулларыңны. 5. өстәл, туры, артында, утыр.

3. Дайте другу советы, запишите: заниматься спортом; поливать цветы; дружить с одноклассниками; читать книги; вовремя готовить уроки.

4. Переведите на татарский язык и запишите: мне хочется петь; к сожалению, не читал(а); придя в школу узнал; не хочется писать

5. Найдите подходящие ответы на вопросы.

Образец: — Сез ничек яшисез? — Рәхмәт, әйбәт.

1) — Гафу итегез, сез кайда тугансыз?
2) — Сезнең иртәгә планнарыгыз нинди?
3) — Бу кем эше булырга мөмкин?
4) — Сез нәрсә белән шөгыльләнәсез?
5) — Гафу итегез, мин кем белән сөйләшәм.

1) — Кинога барырга телим.
2) — Мин Ренатның апасы булам.
3) — Себердә туганмын.
4) — Минемчә, Саша эшедер.
5) — Мин институтта укытам.

6. Напишите на татарском языке.

1. Скажите преподавателю, что в школу не пришел из-за болезни 2. Скажи папе, что в ваш класс пришли 2 новых ученика. 3.Скажи другу о том, что учитель объяснил правило, написав на доске. 4. Пригласи своих гостей за стол. 5. Посоветуй брату аккуратно писать в тетраде.

7. Напишите антонимы: намуслы, ялкау, быел, яхшы, озын.

8. Образуйте отрицательные формы глаголов: сөйләшә беләм, сөйлисе килә, килгәч сөйли, аңларга тиеш, барып кайт. Составьте предложения.

9. Напишите эквиваленты следующих поговорок на татарском языке.

Гостя по одёжке встречают, по разуму провожают.

Гостям дважды радуются: встречая и провожая.

10. Напишите правила дорожного движения (3-5 правил).

8 НЧЕ СЫЙНЫФ

I вариант

1. Устная часть

Озаглавьте и опишите рисунок и расскажите.



II. Письменная часть

1. Переведите текст на татарский язык и запишите в строке после каждого предложения.

№	Предложения
1.	Коля заболел. Сейчас он лежит в больнице.
2.	Никток нему в гости не приходил. Могли заразиться.
3.	Лежит Коля, глядит в окно. А с третьего этажа можно увидеть только небо.
4.	Вдруг Коля увидел в окне красный шар.
5.	Шар поднимается к окну и двигается вверх и вниз.
6	Коля внимательно посмотрел. На шарике нарисовано смешное лицо.
7.	Стало Коле хорошо. Это пришли его друзья. Они помнят о Коле.

2. Сезнең авыру иптәшегезнең хәлен белгәнегез бармы? Шул турыда языгыз.

3. Подберите и допишите пропущенные слова в пословицах.

№	Предложения	Слова
1	Дөньяда иң кечкенә бәхет — байлык, иң зур бәхет — _____.	байлык
2	_____ — сәламәтлек билгесе.	мал
3	Сау кешегә көн дә _____.	бәйрәм
4	_____ бер айлык, саулык –гомерлек.	саулык
5	Баш сау булса, башка _____ табылыр.	карават
6	Авыруга алтын _____ та ярдәм итми.	бүрек
7	Баш сау булмаса, _____ күзгә күренми.	матурлык

4. Составьте предложения с словосочетаниями.

Башка кию, баш бармак, баш хәреф, баш ию, баш күккә тию.

5. Расставьте ударения в словах.

Тракторчы, открыткалар, уйнагыз, уйнасыннар, утыр, утырсын, сикермә, бирми, башкала, ничә? мондый, ягъни, иң матур, ямь-яшел, без дә.

6. Прочитайте текст. Ответьте на вопросы и запишите в строке после каждого предложения.

Сохранить здоровье не просто, а потерять можно сразу. Сберечь его поможет спорт! Физические упражнения укрепляют мускулатуру, сердце, позволяют оставаться стройными, избавляют нас от многих болезней.

Великий философ говорил о пользе занятий спортом: «Гимнастика удлиняет молодость человека».

Здоровье — это красота! Об этом люди знали еще в Древнем Китае и Индии, в Древней Греции. Здоровый человек всегда хорошо выглядит.

А.С.Пушкин был крепкого телосложения, мускулистый, гибкий, благодаря ежедневной гимнастике. Л.Н.Толстой прожил долгую жизнь благодаря физическим упражнениям. Он увлекался ездой на велосипеде, на лошади. В 82 года он за день совершал верхом дальние прогулки.

№	Предложения
1.	Сәламәтлекне сакларга нәрсә ярдәм итә?
2.	Физик күнегүләрнең нинди файдасы бар?
3.	Бөек философ спортның файдасы турында нәрсә әйткән?
4.	“Сәламәтлек — матурлык” дигән фикер белән килешәсезме?
5.	А.С. Пушкин һәм Л.Н.Толстой ни өчен сәламәт булганнар?

9 СЫЙНЫФ

I вариант

1. Напишите рассказ *по теме “Казань (Пермь, Оренбург и т. д.) музыкальная” — “Музыкаль Казан”* (8-10 предложений)



II часть

1. Прочитайте рассказ.

Рахманның теләге — сәяхәтче булу. Сәяхәт турында китаплар укыды ул, илебез картасын биш бармагы кебек белә. Рахман үз илебездә генә сәяхәт итәчәк. Безнең илебез бөтенесенә дә бик бай. Рахман, сәяхәтләрдә йөреп,моңарчы билгеле булмаган байлыкларны кешелеккә бүләк итәр.

Туктагыз әле, нәрсә соң ул байлык? Беркөнне ул әтисеннән:

- Байлык нәрсә була ул, әти? — дип сорады.
- Кешегә кирәкле барлык нәрсә — байлык, улым. Менә бу өстәл дә, синең китапларың да — байлык. Ә төп байлык ул — икмәк. Әмма кешенең әле бернәрсә белән дә алмаштырмас (алыштырып булмас) байлыгы була. Беләсең киләме шуны?
- Беләсем килә! ***Нәрсә соң ул алыштырып булмас байлык?***
- ... .

1.1.**Напишите ответы на вопросы.**

1) Рахман илебез картасын яхшы беләме? Автор шул турыда нинди сүзләр белән язган? Табып, тәрҗемә ит.

2) Рахман кайсы илләргә сәяхәт итәргә тели?

3) Аның ни өчен сәяхәт итәсе килә?

4) Әтисе Рахманга байлык турында нәрсәләр әйтә?

1.2.**Напишите продолжение текста.**

Синеңчә, нәрсә ул алыштырмас байлык? Шул турыда фикерләреңне белдереп, хикәяне дәвам ит.

2. Допишите окончания слов в предложениях.

№	Предложения
1.	Илдар Зарипов, Суриков институт... тәмамлап кайт..., рәссам бул... эшли
2.	Казан... ел саен апрель азагы... шигырь бәйрәм… үткәрелә.
3.	Телефон ерак аралар... тиз үт... мөмкинлек бирә.
4.	Хәзерге вакыт... татар теле... чыга торган газета һәм журналлар шактый күп.
5.	Кытайлылар кәгазь эшләү... зур сер итеп сакла... .

3. Переведите выделенные слова на татарский язык и составьте с ними предложения.

Сотни людей, много детей, по пять книг, без пяти минут четыре.

4. Верните пропущенные слова в предложения.

1) Һәр кеше ... әкиятләр тыңларга ... . 2) Һәр ... үзенең әкиятләре бар. 3) Бөтен әкиятләрдә дә халыклар үзләренең ... чагылдырганнар. 4) Әкиятләр безне ... алып кайта, ... дөньясында йөртә. 5) Шуңа күрә ... балалар әкият геройларына ... тырышалар

Сүзләр:

ярата, мажаралар, күп кенә, кечкенәдән, халыкның, охшарга, хыялларын, балачакка

5. Переведите на татарский язык.

1.У каждого народа, у каждой страны есть своя главная река.2. Судьба России связана с Волгой, самой большой рекой в Европе. 3. Река была когда-то торговой дорогой между Севером и Югом, Западом и Востоком 4. Сегодня по Волге везут хлеб, автомобили, соль, рыбу, овощи, фрукты. 5. У великой реки живут несколько миллионов людей: русские, татары, удмурты, калмыки и многие другие народы.

(В.Песков)

6. От корня *сүз* с помощью аффиксов образуйте слова (не менее 4**).**

сүз +... = ... ,

7. Допишите пословицы.

№	Слова
1.	Калган эшкә ... .
2.	Эшләмәгән ... .
3.	Иң татлы тел — ... .

8. Что должен сказать Наиль в следующих ситуациях?

1. Мәрьям әби ике сумка күтәреп кибеттән кайтып килә, аңа Наил очырый. Ул Мәрьям әбигә

– ... , — диде.

2. Наил ашханәгә керде, анда иптәшләре төшке аш ашыйлар, ул аларга

— ..., — диде.

3. Наил ялгыш иптәшенең китабын төшереп җибәрде, ул аңа

— ... , — диде.

4. Наилнең сыйныфташының туган көне, ул аңа шалтыратты һәм

— ... , — диде.

5. Наилнең дусты авырып китте, ул аның хәлен белергә килде. Киткәндә ул дустына

— ... , — диде.

9. Напишите на татарском языке 5 правил поведения в театре.

II вариант

I. Устная часть

Озаглавьте рисунок. Охарактеризуйте представителя каждой профессии расскажите.



II. Письменная часть

1. Переведите текст на татарский язык и запишите в строке после каждого предложения.

№	Предложения
1.	Дәүләтнең бюджеты булган кебек, һәр гаиләнең дә бюджеты була.
2.	Ул акчаны дөрес тотарга ярдәм итә.
3.	Сезгә, булачак гаилә башлыкларына һәм хуҗабикәләргә, гаилә бюджетын төзергә өйрәнергә кирәк.

4.	Ул керемнәр һәм чыгымнардан тора.
5.	Керемгә хезмәт хакы, пенсия, пособие, эшмәкәрлек табышы керә.
6	Чыгымнарга салымнар, газ, ут, страхование өчен түләүләр, азык-төлек, кием-салым, мәгариф, мәдәнияткә тотылган чыгымнар керә.

2. **Запишите пропущенные реплики в диалогах.**

№	**Реплики**
1.	– ...?
	– Иделнең сул як ярына урнашкан.
2.	– ...?
	– 1 миллионнан артык кеше яши.
3.	– ...?
	– Шәһәр җиде районга бүленгән.
4.	– ... .
	– Казанның иң истәлекле урыны– Кремль.
5.	– Казан Кремеле эчендә нәрсәләр бар?
	– ... .
6.	– Кремль каршында нинди һәйкәл бар?
	– ... .
7.	– Казанда иң яраткан урының нинди?
	– ... .

3. Распределите следующие слова по группам

Сатучы, шофер, икътисадчы, трамвай йөртүче, агроном, тракторчы, укытучы, биюче, тәрбияче, зоотехник, фәнни хезмәткәр, рәссам, архитектор, троллейбус йөртүче, игенче, елгачы, скульптор (сынчы), сыер савучы, машинист, диңгезче.

1) Сәүдә һәм икътисадка бәйле һөнәрләр: …

2) Транспортка бәйле һөнәрләр: …

3) Авыл хуҗалыгына бәйле һөнәрләр: …

4) Мәгърифәткә бәйле һөнәрләр: …

5) Сәнгатькә бәйле һөнәрләр: …

4. Составьте предложения с словосочетаниями.

Һөнәр сайлау, җаваплы вазифа, максатка ирешү, киңәш бирү, эшкә урнашу.

5. Определите правильное написание собственных имени напишите в таблице.

№	Собственные имена	Правильное написание собственных имен
1.	(Т, т)атарстан (Р, р)еспубликасы	
2.	(К, к) азан (Д, д)әүләт (У, у)ниверситеты	
3.	(Җ, ж) иңү (К, к)өне	
4.	(Х, х)алыкара (Х, х)атын-кызлар (К, к)өне	
5.	(М, м)инистрлар(С, с)оветы (Р,р)әисе	
6.	(Д, д)әүләт (Д, д)умасы	
7.	(Р, р) оссия(Ф, ф)едерациясе (П, п)резиденты	
8.	(С, с) аратов (Ө, ө)лкәсе	
9.	(И, и)дел (Е, е)лгасы	
10.	(Г, г)алиаскәр (К, к)амал (И, и)семендәге (Т, т)атар(Д, д)әүләт (А, а)кадемия (Т, т)еатры	

6. Напишите рассказ о самом любимом месте в родном городе.

10 НЧЫ СЫЙНЫФ

I вариант

I. Устная часть

1. Озаглавьте картину. Составьте рассказ и расскажите (12-15 предложений).



II. Письменная часть

2. Прочитайте текст.

2.1. Разделите на смысловые части и озаглавьте каждую часть.

Бүген алар урманга барырга уйладылар. Күбесенең туган көннәре җәй башында. Гөлнараларның сыйныфы унбиш яшьләре тулганны билгеләп үтәргә булды. Соңгы уку елында матур **хатирәләр** калсын әле.

Алар урманга килеп җиткәндә, кояш шактый күтәрелгән иде инде. Агачлар тагын да яшәреп киткәндәй тоелды. Чәчәкләр дә көндәгегә караганда матуррак!

Тирә-якка соклана-соклана сукмактан кереп барганда, Гөлнара кычкырып җибәрде: «Ә без бит әле урманнан рөхсәт сорамаган!» Бу сүзләрдән кайсы көлде, ә кайберләре тезелешеп басып: «Урман бабай, керергә мөмкинме? Мөмкин булса, бер кошыңны сайратчы», — диде. **Шулчак**, чыннан да, бер кошчык бик моңлы итеп сайрап җибәрде.

Сыйныфташлары уйнаганда да, бәрәңге пешергәндә дә, ул эшчән кырмыскаларны карап, урман докторы тукранның тавышын тыңлап йөрде. Табигать барысын да аңлый, ә дус егетләре, кызлары ни өчен аңламыйлар соң аны?

Сәеррәк шул ул: башкалар кочак-кочак чәчәк җыйганда да Гөлнара берничәне генә өзә; иптәшләре агач ботагын сындырганда да үзенең кулларында авырту сизгәндәй була.

«Аерылып йөрү килешмәс», — дип, Гөлнара дуслары янына килде. Сөйләшеп, көлешеп утыргач, кәефе дә күтәрелеп китте. Кайтыр вакыт җитте. Алар җыена башладылар. Гөлнара консерв банкаларын, кәгазь кисәкләрен җыярга тотынды. Бер-ике иптәше дә аңа килеп кушылды. Урманны пычратып калдырырга ярамас! Кайбер сыйныфташлары: «Җыегыз, җый!» — дип көлештеләр. Әмма ул бер сүз дә дәшмәде, йөрәге әрнеп уйлады гына: «Юк, аңламыйлар мине. Әнә **тукран** да агачларны кортлардан коткара, кырмыскалар да урманы чистарта. Ә без?»

(Ф.Бәдретдиновадан)

2.2. Подберите и напишите синонимы выделенных слов.

2.3. Найдите и выпишите из текста слова, выражающие просьбу.

3. Напишите 12-15 предложений, как ответ на вопрос из текста “Ә без?”

4. Переведите на русский язык и запишите.

1) Бөек Ватан сугышында кешеләр генә түгел этләр дә катнашкан. 2) Этләр яхшы элемтәче булганнар. 3) Мәсәлән, Джек кушаматлы эт 3 меңгә

якын хәбәр тапшырган. 4) Рекордны Ленинград фронтында “рядовой” Дик куйган. 5) Этләр 303 шәһәрне минадан чистартканнар. 6) Меңләгән яралы солдатларны сугыш кырыннан алып чыкканнар

5. Допишите пропущенное слова в следующих пословицах.

1. _____ *(кем?)* өйрәнер, ахмак өйрәтер.
2._____ *(нинди?)* сүз таш кисә.
3. Эзләмичә _____ *(нәрсә?)* дә табылмасярый.
4. Һәр эш _____ *(нәрсәсе?)* белән,ботка пешә мае белән.
5. _____ *(кемне?)* сыйласаң, этенә сөяк сал.

6. Переведите на татарский язык и запишите.

1) Некоторые виды растений и животных занесены в Красную книгу.

2) По богатству природы и красоте пейзажей Татарстан может соревноватся со многими государствами Европы.

3) Природа — это цветы в вазе, пение соловья, солнечные пляжи и теплый дождь, хорошее настроение.

4) Любите природу, берегите её, и она будет вам благодарна.

5) Сохранение природы — это сохранение жизни на Земле.

6) Она играет огромную роль в воспитании человека и в сохранении его здоровья.

7. Допишите пропущенные части диалога.

— ... ?

— Мин яңа күлмәгемне кидем, чөнки бүген минем туган көнем. Аны миңа әнием текте.

— ... ?

— Ул — фотограф.

— ... ?

— Юк, минем аның фотоларын күргәзмәдә генә күргәнем бар.

— ... ?

— Әйе, нәкъ менә шундый күлмәк теләгән идем. Тагын компьютер.

— … ?

— Әтием бүләк итте. Ул — чын язучы.

— ... ?

— Чын язучылар яхшы китаплар яза, ә чын булмаганнар җыен чүп-чар.

— ... ?

— Мин феялар турында укырга яратам.

— ... ?

— Әйе. Әле тагын Кар кызы буласым килә.

8. Прочитайте стихотворение, найдите и выпишите глаголы в отрицательной форме, переведите.

“Не бери”, “не говори”.
“Не дерись”, “не обзывайся”,
“Не перечь”, “не отвлекайся”,
“Не царапай”, не кори”...
Это кто такой ученый,
Умный, строгий и прямой
Ребятишек увлеченно
Учит словно заводной:
“Ты не бегай”, “ты не прыгай”,
“Ты не лазай”, “ты сиди”,
Да “не трогай”, да “не двигай”,
Да “волчок не заводи”...
Это мальчик наш Василий,
Двух малюток старший брат.
Мама с папой поручили,
Уходя ему ребят.
Из-за строгости братишки
Малыши сидят. Как мышки.
Строгость в меру хороша,
Меру знай, моя душа.

(Татьяна Дашкевич)

9. Прочитайте предложения, верните слова, образовав нужную форму, в текст.

Бездә _____ кошларны суыклар куркытмый, ә менә _____ — аларның иң явыз дошманы. Менә шуңа күрә дә без кошлар турында даими кайгыртырга, _____ ясап эләргә тиеш булабыз. Җимлекне бакчага элеп куйганда, кошлар агачларда булган _____ бөҗәкләрне дә чүплиләр. Җимлекләрне _____ эшләргә мөмкин.	кышлау ач җим зарар төрле

10. Напишите комментирий соревнования Вашего любимого вида спорта для телезрителей.

II вариант

I. Устная часть

Составьте и напишите рассказ о спортивных площадках твоего города (района, села) и о занятиях.



II часть

1. Напишите ответы на вопросы.

1) Интернеттан нәрсәләр турында мәгълүмат табарга мөмкин?
2) Спорт ярышларында җиңү өчен нинди сыйфатларга ия булырга кирәк?
3) Татар халкының күренекле шәхесләреннән кемнәрне беләсең?
4) Якын дустыңда нинди сыйфатлар ошый?
5) Татарстанның климаты нинди?

2. Расскройте скобки, поставьте слова в нужные формы.

1) Муса Җәлил биш (ел) якын (гомер) Казанда уздырган.
2) (Дус) авырлык килсә, (ул) ярдәм итәргә тырыш.
3) (Чәчәкләр) иртәнге (сәгать) өзеп алу мөһим, чөнки алар (яхшы) саклана.
4) Шимбә (көн) алар Боз (сарай) бармакчы булалар.

3. Посмотрите внимательно рисунок и распределите: кто каким предметом что должен делать. Напишите.



4. Найдите и напишите синонимы прилагательных.

Атаклы, ... ;

чибәр, ...;

тату, ... ;

әйбәт, ... ;

таза, ...

5. Образуйте с помощью аффиксов новые слова.

Юл + ... = ...,

6. Составьте предложения.

1) Тәмамлагач, табиб, мин, булырга, мәктәпне, телим.
2) Борынгы, асылташлар, ышанганнар, көченә, кешеләр.
3) Укучылар, өчен, кыш көне, җимлек, куйдылар, кошлар, ясап.
4) Көнне, була, сәгатьтә, кичә, залында, сишәмбе, актлар, унсигез, әдәби.

7. Напишите продолжение предложения.

1) Авыр булса, син ... .
2) Дустым белән очрашканчы, мин ... .
3) Дәресләр бетсә дә ... .
4) Кышкы каникуллар башлану белән, ...
5) Сабан туенда иң зур бүләкне ... .

8. Напишите эквивалент выражений в татарском языке.

Приятного чаепития!

Конечно, я верю.

Вы в конкретном случае не правы.

Я Вам бесконечно благодарна!

Примите искренние пожелания.

9. Найдите продолжение пословицы.

Ахмак дустың булганчы, ...

1) үзең акыллы бул
2) акыллы дошманың булсын
3) дуслар кирәк түгел

10. Прочитайте.

Кулыма икмәк алганда, еш кына сугыш еллары исемә төшә.

Мин 1945 нче елның август башларында күргән бер күренешне оныта алмыйм. Без, бер группа солдат һәм сержантлар, туган илгә кайтып бара идек. Һәркайда җимереклек. Авылларның исемнәре топографик картада гына калган.

Шулай кайта торгач, безнең эшелон кечкенә генә станциягә килеп туктады. Төшәргә команда булмаганга күрә, без ачык ишектән генә тирә-якны күзәтәбез. Шулвакыт безнең вагон янына 7-8 яшьләрдәге бик ябык малай килеп басты. Без бер сүз әйтмичә генә малайны күзәтәбез. Аның көчсез тавыш белән “Абыйлар, ипиегез юкмы, ипи бирегезче”, — дип соравыннан без югалып калдык.

Малай без биргән икмәкне ничек алуын мин беркайчан да оныта алмадым. Табынга утырган саен, икмәк сораган малай искә төшә. Менә бит ул каһәр суккан сугыш!...

10.1. Напишите ответы на вопросы.

1) Ни өчен авылларның исемнәре топографик картада гына калган?

2) Вакыйга сугышның кайсы өлешен сурәтли?

3) Малайга солдатларның мөнәсәбәте нинди?

4) Аның тавышы ни өчен көчсез?

5) Солдат, сугыштан кайткач, малайны онытамы?


10.2. Напишите небольшой рассказ.

Ни өчен автор сугышны каһәр суккан, ди. Рус телендәге эквивалентын бир. Сугышка мөнәсәбәтеңне белдереп, 4-6 җөмләдән торган хикәя яз.

11 НЧЫ СЫЙНЫФ

I. Устная часть

1. Напишите рассказ о татарском театре, о спектаклях.



II часть

1. Прочитайте.

Тукай дөньяда 27 яшькә кадәр генә яшәде, ләкин ул кыска гомерен дә зур итеп, мәгънәле итеп үткәрде. Иҗтимагый һәм сәяси тормышта ул катнашмаган бер генә өлкә дә булмагандыр.

Барыннан да бигрәк ул яза. Әйтерсең лә, гомеренең кыска, вакытының аз икәнен тоеп, уйлаганын әйтеп бетерергә ашыга. Татар әдәбиятының алтын фондына кергән “Шүрәле”, “Су анасы”, “Кисекбаш” әле бүген дә композиторлар, рәссамнар, драматурглар иҗатына, опера һәм балет артистларына илһам биреп тора.

Безнең әдәбиятта Тукай иҗаты биек бер тау булып күтәрелеп тора. Чөнки Тукай — үз халкының рухи байлыгы чагылышы ул. Тукайның тормышы — күз яшьләре белән, фикер һәм җыр белән тулы тормыш. Тукай яши, яшәячәк.

(Г.Ахунов)

1. Напишите ответы на вопросы.

1) Тукай кайда туган, кайларда яшәгән? Шул турыда нәрсәләр беләсең?

2) Ни өчен шагыйрьнең гомере кыска булган?

3) Тукайның тормышы нинди сүзләр аша бирелә?

4) Ул нинди жанрларда иҗат иткән?

5) Тукай татар операсы һәм балеты тарихында нинди роль уйный?

2. Напишите небольшой рассказ, продолжив последнее предложение текста: Тукай яши, яшәячәк.

3. Прочитайте и решите логические задачи. Напишите ответы.

1) Мәрьям белән Тәлгатьнең этләре Сарбай һәм Акбай исемле. Тәлгатьнең эте Сарбай исемле булса, Мәрьямнең эте ни исемле?

2) Вәкил мәсьәләләрне Камилдән тизрәк, ә Камил Фоаттан тизрәк чишә. Мәсьәләне кем иң акрын чишә.

3) Өч малайның исемнәре: Камил, Вәкил, Самат. Бер малай — сәяхәт, икенчесе — сугыш, өченчесе — спорт турында китап укый. Камил спорт турында укымаган, ә Вәкил сугыш һәм спорт турында укымаган. Кем нәрсә турында укыган?

4. Из слов составьте предложения.

1) Инсаф, спорт, мәктәпнең, беркөнне, залында, тапты, телефоны, кесә. 2) халкының, сабантуй, иң, татар, бәйрәме, яраткан. 3) һәйкәл, Кремле, Казан, тарихи. 4) музее, авылында, ачылган, 1979 нчы, Тукай, Кырлай, елда. 5) урманчы, кирәк, өчен, яратырга, булыр, чын, табигатьне.

5. Переведите на татарский язык и запишите.

1. Елабуга — старинный городок в Татарстане 2. Здесь родились: кавалерист-девица Н.А.Дурова, художник И.И.Шишкин, известный ученый психиатр В.М. Бехтеров, маршал Советского Союза Л.А. Говоров и другие известные люди. 3. Эта земля хранит память об отрядах Емельяна Пугачева, о писателях А.Н.Радищеве и В.Г.Короленко, о командире гражданской войны В.И. Чуйкове. 4. В Великую Отечественную войну Елабуга послала на фронт тысячи бойцов. 5. Елабуга включена в число исторических городов.

6. Образуйте новые слова из корня *күз* с помощью аффиксов.

Күз +... =,

7. Выберите и вместо многоточия ставьте фразеологизм.

Әни пешергән бәлеш ... булган.

1) сүзсез калырлык
2) йөз чөерерлек
3) баш әйләнерлек
4) телне йотарлык

8. Найдите грамматический правильное продолжение предложения.

Яңгыр ява, ...

1) ләкин без бернәрсә белмибез.
2) шунда кичә башланды.
3) шул вакытта кыш та җитте.
4) шулай да без юлга чыктык.

9. Вместо многоточия вставьте подходящее падежное окончание.

1) эш... дәвам итәргә
2) эш... ярдәм итәргә
3) эш... игътибар итәргә
4) эш... кайтып китәргә

10. В какой последовательности нужно расставить предложения, чтобы получился текст?

А) Ашый торган ризыкта витаминнар булуы бик мөһим.

Ә) Һәркем сәламәт булу өчен тырышырга тиеш.

Б) Шуңа күрә кешеләр ит тә, сөт ашамлыклары да, яшелчәләр дә, җиләк-җимеш тә ашарга тиеш.

В) Сәламәт булырга теләсәң, иң беренче чиратта яхшы тукланырга кирәк.

1) Ә, В, Б, А
2) В, Ә, Б, А
3) Ә, В, А, Б
4) В, Ә, А, Б

11. Вы решили продать телефон и решили разместить объявление в газете. Составьте текст объявления.

II вариант

I. Устная часть

Выберите рисунок. Составьте рассказ, назовите.



II. Письменная часть

1. Прочитайте. Напишите продолжение текста.

Һәрбер җитди эш киемнән башлана. Матур, зәвыклы сайланган кием әңгәмәштә уңай тәэсир калдыра. Әгәр син эшлекле кеше булырга теләсәң, түбәндәге кагыйдәләрне истә калдыру мөһим. ...

2. Допишите окончания слов в предложениях.

№	Предложения
1.	Март татар халык календаре... иң күркәм айлар... берсе санала.
2.	Чөнки ул бездә озак заманнар яңа ел... бер... ае булып йөргән.
3.	Кояш календар... буенча көн белән төн... тигезлеге вакыт... 21 март исәпләнә.
4.	Казан татарлары унсигез... йөз ... азагы... да әле Яңа ел... яз... көн-төн тигезлеге көнне бәйрәм ит... .
5.	Яңа ел... беренче көн ... өйдән- өй... йөреп бүләк җый... .

3. Верните слова в предложения.

1. Без ... торабыз. 2. ... болын бар. 3. Бу болында тузганак ... бик күп булганга, аны “алтын болын” дип йөртәләр. 4. Мин түзмәдем, болынга ... тузганак чәчәген табып алдым. 5. Чәчәк үзенең ... йомган.

Слова: таҗ яфракларын, бардым да, тәрәзә каршында, чәчәкләре, авылда

4. Составьте и запишите диалог, используя текст.

Татарның беренче пианисты, танылган композитор, “Тукай маршы” ның авторы З.Яруллин 1888 нче елда Мамадыш районының Кече Сөн авылында дөньяга килгән. Ул бик иртә ятим калган, аның башта әтисе, аннан соң әнисе вафат булган. Заһидулла төрле гаиләләрдә тәрбияләнә. 12 яшендә Чистай шәһәренә килеп чыга, анда музыка кораллары төзәтү остасына эшкә яллана. Шунда ул гармунда уйнарга өйрәнә. Аннан соң Нижгар шәһәрендә гармунчы булып эшли башлый. Заһидулла Яруллин татар музыкасының киләчәк үсешенә көчле йогынты ясаган шәхес. Ул — мәшһүр Салих Сәйдәшевнең дә беренче остазы, танылган композиторлар Фәрит һәм Мирсәет Яруллиннарның әтиләре.

5. Переведите на татарский язык и запишите.

1. Когда-то ветер, вода и правда были друзьями. 2. И однажды правда и вода спросили у ветра: “Скажи, друг, вот ты очень быстрый и бродишь по всему миру, скажи, когда понадобишься, где тебе найти?” 3. Вы найдете меня между гор”. 4. Тогда ветер и правда спросили у воды, где ее найти в нужный момент. 5. “Вы найдете меня в фонтанах, реках и океанах”, - сказала вода. 6. И в конце вода и ветер спросили у правды: “Где тебя, правда, найти в нужный момент?” 7. А она ответила: “Я должна быть всегда среди людей, ищите среди людей”.

6. Напишите подходящие реплики.

1. Спроси у друга (подруги), какую оценку он(а) получила на экзамене.
2. Сообщите учителю, что Вы забыли тетрадь по математике.
3. Сообщите другу (подруге), если в выходные погода будет хорошая, то вы всей семьей пойдете на каток.
4. Спросите у брата, какие события происходят в мире.
5. Поздравьте маму с Международным Днем Матери.

7. Прочитайте, решайте логические задачи и запишите ответы на татарском языке.

1. Өч малайның исемнәре: Камил, Вәкил, Самат. Бер малай — сәяхәт, икенчесе — сугыш, өченчесе — спорт турында китап укый. Камил спорт турында укымаган, ә Вәкил сугыш һәм спорт турында укымаган. Кем нәрсә турында укыган?

2. 2, 5 һәм 10 август көннәрендә төрле һава торышы күзәтелгән: “салкын һәм яңгырлы”, “җылы һәм яңгырлы”, “җылы һәм коры”. 2,10 августта җылы, ә 5, 10 августта яңгырлы булган. Күрсәтелгән көннәрдә нинди һава торышы күзәтелгән?

3. Табиб Кәримгә 3 таблетка дару биргән һәм 20 минут саен эчәргә кушкан. Таблетканың өченчесен эчкәнче күпме вакыт үткән?

8. Впишите начало предложений.

1. ..., мин анда бара алмыйм. 2. ... , син барырга тиеш идең. 3. ..., мәктәптән соң алар еш паркка бара иделәр. 4. ... , аның сиңа шәһәрне күрсәтәсе килде. 5. ..., малайлар тиз генә чишенеп, суга сикерделәр.

9. Допишите вторую часть пословиц.

№	
1.	Ике уйла, ...
2.	Кем эшләми, ...
3.	Берлек кайда — ... .
4.	Ир егет үзе өчен туа, ...
5.	Кешенең иң зур дәүләте — ... .


10. Прочитайте стихотворение, напишите содержание на татарском языке в прозе.

“Не бери”, “не говори”.
“Не дерись”, “не обзывайся”,
“Не перечь”, “не отвлекайся”,
“Не царапай”, не кори”...
Это кто такой ученый,
Умный, строгий и прямой
Ребятишек увлеченно
Учит словно заводной:
“Ты не бегай”, “ты не прыгай”,
“Ты не лазай”, “ты сиди”,
Да “не трогай”, да “не двигай”,
Да “волчокне заводи”...
Это мальчик наш Василий,
Двух малюток старший брат.
Мама с папой поручили,
Уходя ему ребят.
Из-за строгости братишки
Малыши сидят. Как мышки.
Строгость в меру хороша,
Меру знай, моя душа. (Татьяна Дашкевич)

II вариант

I. Устная часть.

1. Озаглавьте картину. Составьте небольшой рассказ по картине (12-15 предл.).



II. Письменная часть

2. Прочитайте. О героизме и творчестве какого татарского поэта или писателя вы знаете? Напишите об этом.

Татарстан Язучылар союзының вестибюленә мәрмәр такта куелган. Ул тактада Бөек Ватан сугышында үлеп калган утыз язучының фамилиясе язылган. Алар язасы әсәрләрен язып бетермичә, яшәргә өлгермичә үлгәннәр.

Польша җирендәге Згеш дигән кечкенә генә шәһәрдә Гадел Кутуй күмелгән. “Тапшырылмаган хатлар” авторы Фатих Кәрим җиңүгә ике ай кала Кенисберг янында һәлак була. Дахауның крематорий мичләрендә фашистлар Совет Армиясе полковнигы шагыйрь Хәйретдин Мөҗәйне яндырдылар. Бу исемлектә җырлары бөтен планетага таралган легендар Муса Җәлил, аның көрәштәше Абдулла Алиш та бар. ...

3. Переведите на русский язык и запишите.

(1) Вакыт үтә дә китә. (2) Вакыт агышын күреп булмый, диләр. (3) Дөрес түгел. (4) Вакыт үзе узган җирдә зур ташпулатлар, чәчәккә күмелгән бакчалар, яңа электростанцияләр, куе урманнар калдырып китә. (5) Вакыт яңа төзелгән шәһәрләр, яңа язылган әсәрләр, яңа ачылган йолдызлар булып күз алдына баса. (6) Вакыт кешеләрне ашыктыра. *(Фәнис Яруллин)*

4. Переведите на татарский язык и запиши.

1. Это произошло в дни фестиваля молодежи в Казани. 2.Ко мне подошла девушка и на ломаном татарском языке начала произносить отдельные слова. 3. Смысл слов мне был ясен, но что хотела узнать девушка, я никак не мог понять. 4. Я ее не поняла потому, что она заучила отдельные слова, а грамматики не знала. 5**.** А надо было слова между собой связать.

5. Напишите диалог со своим одноклассником на тему: "Нужно ли знать грамматику изучаемого языка?"

6. Найдите лишние слова, выпишите, переведите. С выделенными словами составьте предложение.

1) бозлы, бозык, **бозлана**

2) **очлы**, очла, очкын

3) язгы, **язмача**, язулы

4) чәчле, чәчкеч, **чәчүлек**

7. Найдите слова, спрятанные в следующих словах:

умыртка, юмартлык

8. Прочитайте, напишите ответ.

Роза, Нина, Наза, Әсма бер малай белән танышалар. Үзләренең исемнәрен әйтәләр дә:

- Синең исемең ничек соң? — дип сорыйлар.
- Берегезнең исеменнән беренче хәрефне, икенчегезнең исеменнән икенче хәрефне, өченчегезнең исеменнән өченче хәрефне, дүртенчегезнең исеменнән дүртенче хәрефне алып, бергә тезгәч, минем исемем килеп чыга, — дигән малай.

Малайның исеме ничек булган?

9. **Восстановите стихотворение, допишите пропущенные слова**.

Ап-ак тау ...	Ак шәлен ... ,
Ап-ак кар	Ап-ак кыш ... .
Ап-ак яр ...	Ак мамык ... ,
Ап-ак юл	Ак баулы ... .
Ак тунлы ...	Ак кардай .....,
Ак бүрек	Ак тауга ... .

(Р. Вәлиева)

10. Напишите подходящие реплики.

1) Спроси у учителя о том, когда он(а) объявит результаты самостоятельной работы.

2) Сообщи другу (подруге), если в выходные погода будет хорошая, то вы всей семьей пойдете на каток.

3) Сообщи маме о том, что ты стал(а) победителем международной олимпиады.

4) Предложи сестре сходить вместе на премьеру нового фильма.

11. Придумайте и напишите пропущенную часть текста (5-6 предл.)

Минем исемем Бак. Мин хәзер аспирант. Ун ел элек мин Ханойда бер кыз белән таныштым. Ул вакытта миңа 17 яшь — мин 10 нчы класста укый идем. Ул кыз исә — 8 нче класста. Без китапханәдә таныштык.

.....

.....

Мин дә лекцияләр тәмамлангач, китапханәгә йөгерәм. Аны көтәм. Килсен генә. Ул килгәч, без коридорда озак сөйләшеп утырабыз. Аннан соң урамга чыгабыз, паркта йөрибез, кафега керәбез, мороженое (туңдырма) ашыйбыз. Ул шоколадлы мороженое бик ярата иде.

Татар мәктәпләрендә татар теленнән олимпиадага әзерләнү өчен тестлар
Тестлар

А1. Төрки телләр кайсы туганлык гаиләсенә керә?

1) һинд-европа телләре
2) семит-хәмит телләре
3) кавказ телләре
4) алтай телләре

А2. Берничә кеше катнашындагы сөйләм ничек атала?

1) монолог
2) диалог
3) полилог
4) полиглот

А3. Фонетика ул — тел белеменең ...

1) дөрес әйтелеш кагыйдәләрен өйрәнә торган тармагы
2) дөрес язу кагыйдәләрен өйрәнә торган тармагы
3) телнең аваз төзелешен өйрәнә торган тармагы

А4. Фонетиканың бүлекләре арасында артык очракны табыгыз.

1) орфография
2) орфоэпия
3) графика
4) лексикография

А5. Фонетиканың төп терминнары арасында кайсы артык?

1) аваз
2) хәреф
3) кушымча
4) басым

А6. Җөмләне дәвам итегез:

Фонема дип, телдәге ...

1) сүзләрне һәм морфемаларны төзүче, аларны бер-берсеннән аеру өчен хезмәт итүче иң кечкенә аваз берәмлеге санала

2) сүзләрне һәм җөмләләрне төзүче, аларны язуда чагылдыручы иң кечкенә язу берәмлеге санала

3) сузык һәм тартык авазларны төзүче иң кечкенә фонетик берәмлек санала

А7. Сүзнең тарихи килеп чыгышын телнең нинди бүлеге өйрәнә?

1) морфология

2) фонетика
3) этимология
4) фразеология

*А8. **Э** хәрефе татар телендәге кайсы сүздә сузык авазны белдерә?*

1) маэмай
2) электр
3) эшчән
4) тәэмин

*А9. **Маэмай, тәэсир, тәэмин** сүзләрендәге өченче аваз ничек атала?*

1) сузык аваз
2) тел арты тартыгы
3) тел алды тартыгы
4) һәмзә тартыгы

А10. Тоннан гына тора торган авазлар ...

1) сузык авазлар дип атала
2) сонор авазлар дип атала
3) саңгырау тартыклар дип атала
4) яңгырау тартыклар дип атала

А11. Алгы рәт сузыкларыннан гына булган төркемне күрсәтегез.

1) [а], [у], [ү]
2) [и], [о], [е]
3) [ә], [ө], [ү]
4) [ы], [о], [а]

А12. Иреннәрнең катнашуына яки катнашмавына карап, сузыклар ...

1) өч төркемгә бүленә
2) дүрт төркемгә бүленә
3) ике төркемгә бүленә

А13. Иренләшкән сузык авазны күрсәтегез.

1) [а]
2) [ә]
3) [ү]
4) [е]

А14. Увуляр тартыклардан торган рәтне күрсәтегез.

1) [къ], [гъ], [х], [ң]
2) [с], [з], [д], [т]
3) [г], [л], [р], [ш]
4) [м], [н], [ң]

А15. Саңгырау тартыклар ...

1) тоннан гына тора
2) шаудан гына тора
3) шау өстенлек итеп, тон катнаша
4) тон өстенлек итеп, шау катнаша

А16. Яңгырау тартык авазлы сүзләрдән генә торган рәтне күрсәтегез.

1) баз, җиде, дуга
2) китап, яшеллек, дәүләт, көз
3) яз, елмаю, җитди, боз
4) күзлек, өстәл, тәрәзә, безнеңчә

А17. Яңгырау тартыкларны күрсәтегез.

1) [п], [ф], [к], [къ], [т], [ш], [с], [ч], [ц], [щ], [х], [h]
2) [б], [в], [г], [гъ], [д], [ж], [л], [р], [м], [н], [ң], [й], [w]
3) [б], [п], [в], [ф], [г], [к], [д], [т]

А18. [а] авазы — ...

1) түбән күтәрелешле, иренләшмәгән арткы рәт сузыгы
2) түбән күтәрелешле иренләшмәгән алгы рәт сузыгы

А19. Нечкә сузыклы сүзләр генә кергән рәтне күрсәтегез.

1) әни, кадерле, кадәр, хисап
2) кыйммәт, сурәт, гадәт, каләм
3) җиләк, тимер, тәрәзә, китап
4) сәнәк, чиләк, тәмләткеч, күбәләк

А20. Сүз азагында килгән [п], [к] тартыклары артыннан сузык авазга башланган сүз килсә, [п], [к] авазлары ...

1) яңгыраулаша
2) төшеп кала
3) үзгәрми

А21. Сүзләр кайсы вариантта бары тик сузык авазларының рәте белән генә аерылалар?

1) кул — кил
2) бар — бәр
3) үл — юл
4) тар — тир

А22. Татар телендә [,] (һәмзә) авазы нинди төр сүзләрдә кулланыла?

1) татар сүзләрендә
2) рус алынмаларында
3) гарәп алынмаларында

4) европа алынмаларында

А23. Кайсы сүздә хәреф ике авазны белдерә?

1) элемтә
2) зыян
3) җырлар
4) сорый

*А24. **Яшьтәш** сүзендә —*

1) 6 хәреф, 6 аваз
2) 6 хәреф, 5 аваз
3) 5 хәреф, 6 аваз
4) 6 хәреф, 7 аваз

А25. Хәреф саны аваз саны белән туры килгән сүзләрне күрсәтегез.

1) алъяпкыч, көньяк, берьюлы, нәкъ
2) аласың, киләсең, киләсез, килгәнсез, аныңча
3) юлчы, елмаю, ялганчы, егерме

А26. Кайсы рәттәге сүзләрдә басым беренче иҗеккә төшә?

1) акыллы, сүзчән, матур
2) каралҗым, ачкылтым, җылымса
3) ямь-яшел, кап-кара, сап-сары
4) матуррак, яшелрәк, карарак

А27. Басым соңгы иҗеккә төшмәгән очракны күрсәтегез.

1) мәктәпләрдә
2) балаларча
3) уйнадылар
4) яшеллек

А28. Логик басым җөмләдә ...

1) сүзләр арасындагы бәйләнешне ачыклау хезмәтен үти
2) тыңлаучы нык игътибар итәргә тиешле сүзгә төшә

А29. Хәреф саны аваз саныннан күбрәк булган сүзләрне күрсәтегез.

1) ятьмә, тәэмин, ямь, берьюлы, җәмгыять
2) тәгълимат, пакь, зәгыйфь, мөстәкыйль
3) яхшы, куян, яланаяк, уен, тыюлык

А30. Басымы өченче иҗеккә төшкән сүзләрне күрсәтегез.

1) кемдер, ниндидер, кайчандыр, кемнәндер, ишеттер
2) әллә нинди, әллә ничек, унау, берәүме, уннарча
3) аңлавымча, сөйләгәнсеңдер, әйткәлисеңме, ишеткәч

А31. ***Тартык + сузык + тартык*** *калыбына туры килгән иҗекне күрсәтегез.*

1) ар - ба
2) кар - быз
3) бү - ле- нү
4) йорт

А32. Сузык авазга тәмамланган иҗек ...

1) ачык иҗек була
2) ябык иҗек була

А33. Ачык иҗекләр рәтендә кайсысы артык?

1) ка-, ба-, та-
2) ки-, би-, ти-
3) дә-, да-, бу-
4) тап-, ку-, ми-

А34. Авазларның төрки телләргә генә хас комбинатор үзгәрешен күрсәтегез.

1) аккомодация
2) ассимиляция
3) тартыкларның чиратлашуы
4) сингармонизм

А35. Авазларның позицион үзгәрешләре нәрсәгә бәйле?

1) авазлар сүзнең кайсы урынында килүенә
2) авазларның бер-берсенә тәэсир итешүенә
3) тартыкларның сузыкларга тәэсир итүенә
4) тартыкларның яңгыраулыкта яки саңгыраулыкта ярашуына бәйле

А36. Элизия ул — ...

1) тартыкларның төшеп калуы
2) сүздәге авазларның урыны алышыну
3) ике сүзнең беренчесе сузык авазга тәмамланып, икенчесе сузыкка башланганда барлыкка килә торган аваз үзгәреше
4) алынма сүзләрне кабул иткәндә, андагы авазларны туган телдәге аваз белән алыштыру

А37. Тулы редукция — ...

1) авазның тулысынча кыскаруы
2) аваз өлешчә кыскару

А38. Редукция күренеше ул — ...

1) авазлар чиратлашу
2) сузык авазларның ярашуы
3) сузыкларның кыскаруы яки төшеп калуы

4) тартык авазларның ярашуы

А39. Ирен гармониясенә буйсынган сүзне күрсәтегез.

1) болыт, көзге, төлке

2) кәгазь, нәкъ, дөнья

3) идән, өстәл, күбәләк

4) такта, кара, алма

А40. Сүзләрнең дөрес язылышын фонетиканың кайсы бүлеге өйрәнә?

1) орфография

2) орфоэпия

3) графика

А41.Алынма сүзне табыгыз?

1) кояш

2) абый

3) яшелчә

4) салам

*А42. **Унбер, өянке, сүзсез** сүзләре нинди принципка нигезләнеп языла?*

1) фонетик

2) график

3) морфологик

4) тарихи — традицион

А43. Рун язуын икенче төрле ничек дип атап йөртәләр?

1) төрки язу

2) гарәп язуы

3) Орхон-Енисей язуы

4) уйгыр язуы

А44. Безнең көнгә килеп җиткән истәлекләр арасында кайсысы рун хәрефләре белән язылган?

1) “Хан улы һәм ана юлбарыс турында легенда”

2) Күлтәгингә багышланган өзек

3) “Борынгы Турфан җырлары”

4) Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәре

А45. Татарларда гарәп графикасының кулланылышка кереп китүнең төп сәбәбе?

1) сәүдә

2) ислам дине

3) мәдәният

А46. Татар язуын латин графикасына күчерү ничәнче елларда башлана һәм дәвам итә?

1) 1920-1930
2) 1925-1935
3) 1927-1939
4) 1930-1940

А47. Татар телендә ничә орфографик принцип бар?

1) өч
2) дүрт
3) биш
4) алты

А48. Сүзләрне фонетик принцип буенча язу –

1) сүзне ишетелгәнчә язу
2) морфемаларның бөтенлеген саклап язу
3) сүзләрнең элеккеге язылышын саклап язу
4) сүзне чыганак телдәгечә язу

А49. Алынма сүзләрнең язылышы нинди принципка корылган?

1) график
2) фонетик
3) морфологик
4) тарихи-традицион

А50. Кириллицага нигезләнгән татар орфографиясендә кайсы язылыш принцибы өстенлек итә?

1) фонетик принцип
2) морфологик принцип
3) тарихи-традицион принцип
4) график принцип

А51. Әйтелешне язуда дөрес күрсәтү өчен уйлап табылган язу –

1) орфография
2) орфоэпия
3) транскрипция
4) иероглифлар

*А52. Кайсы сүздә "**h**" хәрефе языла?*

1) ми...ербанлы
2) мә...әббәт
3) ...астаханә
4) ...алык

А53. Лексикология тармагы нәрсәне өйрәнә?

1) телдәге авазлар һәм хәрефләрне
2) сүзләрнең ясалышы һәм төрләнешен
3) сүзтезмә һәм җөмләләрне
4) телдәге сүзләр җыелмасын

А54. Сүзнең төп вазыйфасы –

1) бәйләү
2) аеру
3) тасвирлау
4) атау

А55. Синонимнар –

1) капма-каршы мәгънәле сүзләр
2) бер үк яки якын мәгънәле, мәгънәдәш сүзләр
3) әйтелешләре очраклы туры килгән сүзләр

А56. Кайсы пар синоним була алмый?

1) төлке — хәйләкәр кеше
2) кибәк баш — надан
3) сандугач — матур җырлаучы
4) сарык — тырыш кеше

А57. Түбәндәге синонимнар кайсы төргә карый?

Председатель — рәис, врач — табиб, библиотека — китапханә

1) идеографик синонимнар
2) абсолют синонимнар

А58. **Нефть — кара алтын** — нинди төр синонимнар булып торалар?

1) мәгънәви синонимнар
2) стилистик синонимнар

А59. Антоним парлардан ясалган сүзләрне күрсәтегез.

1) аллы-гөлле
2) чыр-чу
3) хатын-кыз
4) аклы-каралы

А60. Үзара антоним булган сүзләрне күрсәтегез.

1) тәбәнәк — сай
2) авыр — җиңел
3) сылу — зифа
4) закон — канун

А61. Омонимнар ...

1) әйтелеше төрле, әмма мәгънәләре бертөрле булган сүзләр
2) капма-каршы мәгънәле сүзләр
3) язылышы бер үк, ләкин әйтелеше төрле булган сүзләр
4) язылышы һәм әйтелеше бер, ләкин мәгънәләре төрле булган сүзләр

А62. Омонимнарның бер төре булган омофоннарны күрсәтегез.

1) үпкәләр — үпкәләр
2) май — май
3) сабын — сабын
4) бик мул ла — Бикмулла

А63. Яңа сүзләр ничек атала?

1) архаизм
2) диалектизм
3) неологизм
4) омоним

А64. Искергән сүзнең төрен билгеләгез.

Берләп —

1) тарихи сүз
2) архаизм

А65. Сүзләрнең мәгънәләрен аңлата торган сүзлекне күрсәтегез.

1) тәрҗемәле сүзлек
2) аңлатмалы сүзлек
3) кире сүзлек
4) ешлык сүзлеге

А66. Җирле төбәк сүзләре ничек атала?

1) неологизм
2) профессионализм
3) диалектизм
4) искергән сүзләр

А67. Фразеология ул —

1) сүзгә билгеләмә бирә, сүзнең мәгънәсен һәм мәгънә үзгәрешләрен тикшерә торган фән
2) тел гыйлеменең җирле сөйләшләрне өйрәнә торган тармагы
3) тел гыйлеменең тотрыклы сүзтезмәләрне өйрәнә торган тармагы

А68. Фразеологизмнар арасында артык рәтне күрсәтегез.

1) койрык бору
2) койрыгын да күрми калу

3) төлкенең койрыгы

4) койрыгы бозга каткан

А69. Фразеологизмның дөрес аңлатмасын күрсәтегез.

Телгә килү –

1) сөйли башлау

2) ызгышу

3) уртак фикергә килү

4) уйлап кую

А70. Фразеологизмның дөрес тәрҗемәсен күрсәтегез.

Кызыл кар яугач –

1) когда выпадет красный снег

2) когда на горе рак свиснет

А71. Кайсы төр сүзләр арасында мәгънә бәйләнеше булмый?

1) омоним

2) антоним

3) оксюморон

3) синоним

*А72. **Гали, Зөһрә, Наил, Фәридә** исемнәре кайсы телдән кергән?*

1) гарәп теленнән

2) фарсы теленнән

3) рус теленнән

4) француз теленнән

А73. Тарихи сүзләрне ...

1) актив сүзләр дип йөртәләр

2) пассив сүзләр дип йөртәләр

А74. Төшенчәләргә аңлатма бирелә торган сүзлекләр ничек атала?

1) энциклопедик сүзлекләр

2) филологик сүзлекләр

А75. Сүзнең язылышы турында мәгълүмат табып була торган сүзлекләр ничек атала?

1) диалектологик сүзлекләр

2) фразеологик сүзлекләр

3) терминологик сүзлекләр

4) орфографик сүзлекләр

А76. Сүзләрнең мәгънәләрен аңлата торган сүзлекне күрсәтегез.

1) тәрҗемәле сүзлек

2) аңлатмалы сүзлек

3) кире сүзлек
4) ешлык сүзлеге

А77. Сүз ясалышының төп өйрәнү объектын күрсәтегез.

1) сүз (лексема)
2) аваз
3) морфема
4) җөмлә

А78. Сүз ясагыч кушымча ...

1) сүзгә яңа грамматик мәгънә өсти
2) сүзнең формасын үзгәртә
3) сүзне төрләндерә
4) яңа мәгънәле лексик берәмлек тудыра

*А79. Кайсы сүздә **-ка** кушымчасы юк?*

1) тотка
2) ботка (каша)
3) китапка
4) колакка

А80. Борынгы кулъязмаларны туплый; тел ягыннан тикшерә, бастырып чыгара һәм тарихка мәгълүмат бирә торган фән ничек атала?

1) эпиграфика
2) археология
3) археография

*А81. **-чылык/-челек** сүз ясагыч кушымчалы сүзне билгеләгез.*

1) азчылык
2) урманчылык
3) укытучылык

А82. Тамыр сүзне күрсәтегез.

1) икмәк
2) китапчык
3) сабакташ
4) ташчы

А83. Үзара антонимнардан торган парлы сүзләрне күрсәтегез.

1) аллы-гөлле
2) хатын-кыз
3) ишекле-түрле
4) кыз-кыркын

А84. Исем сүз ясагыч кушымчаларны билгеләгез.

1) –лар/-ләр
2) –лык/-лек
3) –лы/-ле
4) –ча/-чә

А85. Бер сүз төркеменең икенче сүз төркеменә күчүе белән яңа сүз ясалу ничек атала?

1) инверсия
2) конверсия
3) морфология
4) аффиксация

А86. Кайсы төркемдәге сүзләр бер генә морфемадан тора?

1) терәк, белем
2) көндәлек, ташкын
3) тавыш, тагарак
4) ярык, язма

А87. Нинди сүз төркеменә караган сүзләр кушымчалау ысулы белән ясала алмый?

1) исем
2) сыйфат
3) рәвеш
4) сан

А88. ***Берән-сәрән*** *сүзе кайсы сүз төркеменә карый?*

1) исем
2) сыйфат
3) рәвеш
4) сан

А89. ***Күлмәклек*** *сүзенең ясалу ысулы ягыннан төрен күрсәтегез.*

1) тамыр сүз
2) ясалма сүз
3) парлы сүз
4) кыскартылма сүз

А90. ***Түбәнчелек*** *сүзенең мәгънәле кисәкләргә дөрес бүленгән очрагын күрсәтегез.*

1) түбән-че-лек
2) түбән-челек
3) түбә-н-че-лек

4) түбәнчелек

А91. Сүз ясагыч кушымчалы сүзне күрсәтегез.

1) аксыл
2) зәңгәрсу
3) яшькелт
4) сусыл

А92. Кайсы рәттә сүзнең тамыры дөрес билгеләнмәгән?

1) хаклык (хак-)
2) тиңләү (тиң-)
3) юлдашлар (юлдаш-)
4) җирле (җир-)

А93. Бәйләгеч кушымчаларны күрсәтегез.

1) -ыр, -ер, -ган, -ты, -те, -ачак, -әчәк
2) -чы, -че, -гы, -ге, -лык, -лек, -ла, -лә
3) -ның, -нең, -га, -гә, -ны, -не, -дан, дән, -да, -дә
4) -ча, -чә, -дай, -дәй, -лай, -ләй

А94. Телдәге стильләрне өйрәнә торган фән ничек атала?

1) морфология
2) синтаксис
3) стилистика
4) фонетика

А95. Түбәндәге текст кайсы стильгә карый?

Искиткеч бәхетле минутлар иде бу: тартылган кыллар, синең ихтыярыңа буйсынып, әнә нинди авазлар чыгара, телеграф чыбыгыдай зеңли. Фәритнең бармаклары, шушы кылларга тоташып үскәндәй, җиңелчә бер рәхәтлек белән тирбәлә, йөзә, моң булып калтырана. Гәүдәсендәге сихри тетрәү туп-туры бармак очларына агып төшә сыман. Мандолинага кушылып Фәрит әллә үзе чыңлыймы? Ул үзен ике аяклы, ике куллы тере көй итеп тоя башлады. Күзеннән, колагыннан, чәчләреннән чың агыла шикелле. Менә нинди була икән ул моң дигәнең! *(Р.Низамиев)*

1) әдәби стиль
2) фәнни стиль
3) рәсми стиль
4) хатлар стиле

А96. Газета-журнал мәкаләләре, тәнкыйть материаллары, өндәмәләр, юлъязмалар, очерк һәм фельетонар языла торган стильне күрсәтегез.

1) матур әдәбият стиле

2) публицистик стиль

3) фәнни стиль

4) рәсми стиль

А97. Синтаксик синоним булып торган җөмләләрне күрсәтегез.

А) Язлар җитү белән, сәфәргә чыгып китәрбез.

Ә) Язлар җитәр, шуннан соң сәфәргә чыгып китәрбез.

Б) Язлар җитәр һәм без сәфәргә чыгып китәрбез.

В) Язлар җитәр. Без сәфәргә чыгып китәрбез.

1) АВ

2) АБ

3) АӘ

4) БВ

А98. Стилистик яктан дөрес булмаган җөмләне табыгыз.

1) Бу күчермә бик күп кешеләр тарафыннан күчерелеп язылган.

2) Моннан гыйбрәт ал, углым: текә башлы булу гакылсызлыктан килә. (Дәрдмәнд)

3) Кеше үз тормышын үзе бизәргә тиеш. (К.Тинчурин)

4) Кешеләрнең дә маңгайларында язулары булса, бер төрлесенең янына да килмәс идең, йөз чакрымнан әйләнеп үтәр идең. (И.Гази)

А99. Кемнең дә булса ике телдә сөйләшә һәм аңлаша алуы нинди күренеш дип атала?

1) билингвизм

2) полилингвизм

А100. Сочинение өчен тәкъдим ителгән темалар арасында иң киң мәгънәлесен сайлап алыгыз.

1) Балык тотканда.

2) Җиләк җыю — минем иң яраткан шөгылем.

3) Учак янында ял итәбез!

4) Мин җәйге каникулны ничек үткәрдем.

10 НЧЫ КЛАСС

2 нче вариант

1. Алдан да, арттан да бер төсле укыла торган 8 сүз уйлап языгыз.

2. *Орфография күзлегеннән караганда әлеге сүзләрне нәрсә берләштерә?*

көнбагыш, унбер, унбиш, әнкәй, басынкы.

3. Сүзләрне транскрипцияда бирегез.

сәгать –

тозсыз –

матуррак –

тәэмин –

яра –

*4. **Әкият, хикәят** сүзләре белән кертеп җөмләләр төзеп языгыз.*

5. Сүзләрнең мәгънәләренә аңлатма бирегез һәм кулланылыш үзенчәлекләрен аңлатыгыз:

интернет –

җөмһүрият –

чабата –

миннек –

ләчтит сату –

6. Архаизмнарның хәзерге телдәге синонимнарын языгыз.

берлән –

сабак –

безләр –

ошбу –

харита –

7. Татар телендә кулланыла торган рус сүзләренең татарча (яки гарәп-фарсы алынмасы) абсолют синонимнарын табып языгыз. Сез кайсы вариантны кулланып сөйләшәсез һәм кайсысы кулланылырга тиеш дип саныйсыз?

художник –

библиотека –

профессия –

суверенитет –

герб –

председатель –

гостиница –

8. ***Йөгерү — чабу — җилдерү*** *синонимнары арасында нинди аермалык бар?*

9. Оксюмороннарга мисаллар уйлап языгыз. Оксюморон белән антонимнар арасында бәйләнеш урнаштырыгыз.

10. ***Ак*** *сүзе кергән фразеологизмнар уйлап языгыз.*

11. Кайсы очракта фразеологизмнарның аңлатмасы дөрес күрсәтелмәгән?

авыз белән кош тоту — игътибарсызлык күрсәтү

кот очу — курку

башы түшәмгә тию — шатлану

йомры баш — түгәрәк башлы кеше

12. Бирелгән сүзләрнең күп мәгънәле булуын дәлилләгез.

Соң, баш, уң, кара, ак.

13. *Текстны укып, искергән сүзләрне (яки фонетик, морфологик күренешләрне) хәзерге татар әдәби теленә әйләндереп языгыз. Искергән сүзләрне һәр очракта да башка сүзләр белән алыштырып буламы?*

Ул быел кечек угылларын да, ялчыларын да уракка йөртмәде. Дисәтинәләп урырга да бирмәде, гомерендә беренче мәртәбә уларак, урак машиналары алдырып, оста руслар яллады да шуның белән аз көн эчендә игенен бетертте.

Ул, гадәттә, бик моктәсид (саклап тотучан) кеше булып, ашлыкны кыш көне әвен белән сугуда әллә ничаклы файда күрә:

– Саламы да яхшы була, сукканда малың күбәгенә, башагына да рәхәтләнә, — ди иде.

Бу ел исә ничектер анны уйламады, һәммә игенен ялан уртасындагы бер зур Калку чирәмгә җыйдырды да, күрше боярдан зур машина китертеп, берничә көн эчендә барлыгын суктырып, ашлыгын өсәккә ташытты, саламын бик зур эскерт итеп, шул җиргә өйдерде дә, мал-фәлән кагылмасын өчен, тирәсен киртәләтеп куйды.

Базар бәһалары яхшы иде. Халыккача бишәр, унар йөк белән берничә мәртәбә калага да озатты. *(Г.Ибраһимов)*

14. Лингвистик терминнарны ике төркемгә аерыгыз:

1) тел гыйлеме терминнары, 2) әдәбият белеме терминнары.

Синоним, фонема, лирик герой, мәсәл, кушма җөмлә, редукция, синтаксис, архаизм, юнәлеш категориясе, чәчмә әсәр, ия, сузык аваз, бәет, ритм, сюжет, иҗек, трагедия, мелодрама, кушымча, пьеса, этимология, фразеологизм.

15. Тәрҗемә итегез. Нинди үзенчәлек күзәтерсез?

Крупный город, крупный картофель, крупный ученый; богатый человек, богатое платье; горячий кофе, горячий человек, горячее желание, горячий день.

16. Бирелгән сүзләрне мәгънәле кисәкләргә таркатыгыз.

аерылмыйк –

уртаклашмыйлар –

шәһәрчекләрне —

17. “Артык” сүзне сызыгыз.

Шәһәрчек, кызчык, янчык, мәйданчык.

Кайгыру, хәсрәтләнү, көенү, сөенү.

18. Түбәндәге очракларны 1) тезмә сүзгә һәм 2) сүзтезмәләргә аерып языгыз.

Кызыл почмак, кызыл тасма, кызыл туй, кызыл төс, кызыл карлыган, кызыл күлмәк, кызыл түш, кызыл канат, Кызыл китап.

19. Калын хәрефләр белән бирелгән исемнәрнең килешен билгеләгез.

1) “Арлы-бирле кызлар йөгерешә, иңнәренә **шинель** ябынып” (М.Хөсәен).

2) “Җан **тынычлык** тели” (М. Юныс).

3) “**Юлларымны** күзләде, **эзләремне** эзләде” (Х.Туфан).

20. *Җөмләне дәвам итеп бетерегез. Шәхесләрнең берсенә тулырак мәгълүмат бирегез.*

Ризаэтдин Фәхретдин –

Муса Җәлил —

Әлфия Афзалова –

Сайлап алыр өчен җөмләнең дәвамы:

1. Мәгърифәтче галим, тарихчы, дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе.

2. Җырчы, Татарстанның халык Россиянең атказанган артисткасы,

Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

3. Татар халкының бөек улы, герой-шагыйрь.

21. *Бирелгән мәкальләрдә күпнокталар урынына тиешле сыйфатны куеп языгыз.*

1) Бик ... булма — кабып йотарлар,

Бик ... булма — төкереп ташларлар.

2) ... кеше сүз әйткәндә,

Әйтер сүзен чамалар.

3) ... караңгы йөздән ... сүз чыкмас.

4) ... сүзгә җавап юк.

5) ... сүзнең кыскасы,

... сүзнең остасы.

Сайлап алыр өчен сыйфатлар: озын, кыска, татлы, ачы, караңгы, тәмле, ахмак, акыллы.

22. *Антоним сыйфатларны кулланып, мәкальләр уйлап языгыз.*

23. *Кирәкле урынга тиешле тыныш билгеләрен куегыз.*

1) “Хромка” дип аталган бу нәрсәкәй заманында ягъни сугышка кадәр төнге урамнарның тынычлыгын алган гармун иде (Р.Низами)

2) Сыңар кул алай тиз-ансат кына тынмады кемгәдер хәбәр итү белән янап рәхмәт тә әйтмичә билетын түш кесәсенә кыстырды (А.Гыйләҗев)

3) Апабыз әйтте эшебез

Әтиләргә сөйләрлек (Р. Фәйзуллин)

24. *Сүзтезмәләрне аерып күрсәтегез.*

Бала ярату; hава саф; Әминә, Сәкинә һәм Зифа; мап-матур; ант итәм; юри тавышлану; сөйләр сүзләр; юлдагы тузан; я мин, я ул; тозсыз аш; китапка; җир җиләге; Мәскәү — башкала; төп башына утырту; Казан дигән кала.

25. *Түбәндәге җөмләләрдә стилистик хаталарны табыгыз.*

1) Ул зур глобаль проблемаларны хәл итү белән мәшгуль иде.

2) Бу күчермә бик күп кешеләр тарафыннан күчерелеп языла.

3) Яңа танышым белән танышуга мин бик шат идем.

Тестлар

А1. Барысы да татар теле белән кардәш булган телләр төркемен күрсәтегез.

1) әзербайҗан теле, төрек теле, башкорт теле, каракалпак теле

2) казах теле, төрекмән теле, алман теле, кырым татарлары теле

3) башкорт теле, гарәп теле, ногай теле, комык теле

А2. Тел белеме терминнары арасында кайсы артык?

1) синтаксис

2) романтизм

3) сингармонизм

4) лексика

А3. Идел буенда гарәп язуы кайчан кулланылышка керә?

1) V–XIII гасырларда төрки халыклар тарафыннан кулланыла.

2) XIX–XX гасырларда кулланыла.

3) X гасырда (ислам динен кабул иткәннән соң) актив кулланыла башлый.

4) Казан ханлыгы чорында кулланыла башлый.

А4. “Кечкенәдән зурга таба” урнаштырылган тел белеме терминнары рәтендәге ялгышны табыгыз. Кайсыларының урынын алыштырырга кирәк?

А) аваз

Ә) сүз

Б) иҗек

В) сүзтезмә

1) А һәм Ә

2) А һәм Б

3) Ә һәм Б

4) Б һәм В

А5. Лексикологиянең терминнары арасында кайсы артык?

1) сүз

2) неологизм

3) синоним

4) басым

А6. Җөмләне дәвам итегез:

Оксюмороннар дип ...

1) капма-каршы мәгънәле сүзләргә әйтәләр

2) үзара каршылыклы бәйләнешкә кереп, бер сүзтезмәгә әверелгән антоним сүзләргә әйтәләр

3) әйтелешләре һәм язылышлары ягыннан очраклы рәвештә туры килгән аваздаш сүзләргә әйтәләр

А7. Лексикологиянең сулык исемнәрен өйрәнә торган бүлеген күрсәтегез.

1) космонимика

2) зоонимика

3) фитонимика

4) гидронимика

*А8. **Э** хәрефе татар телендәге кайсы сүздә сузык авазны белдерә?*

1) тәэсир

2) энергия

3) элеккеге

4) мөэмин

А9.[у] сузыгына дөрес билгеләмәне күрсәтегез.

1) нечкә, иренләшкән озын сузык аваз

2) калын, иренләшмәгән кыска сузыклар

3) югары күтәрелешле, иренләшкән арткы рәт сузыгы

4) нечкә, иренләшкән кыска сузык аваз

А10. Шаудан гына тора торган авазларны күрсәтегез.

1) сузык авазлар

2) сонор авазлар

3) саңгырау тартыклар

4) яңгырау тартыклар

А11. Арткы рәт сузыкларыннан гына торган төркемне күрсәтегез.

1) [а], [у], [ү]
2) [и], [о], [е]
3) [ә], [ө], [ү]
4) [ы], [о], [а]

А12. Телнең горизонталь хәрәкәтенә карап, сузыклар...

1) өч төркемгә бүленә
2) дүрт төркемгә бүленә
3) ике төркемгә бүленә

А13. Иренләшмәгән сузык авазны күрсәтегез.

1) [о]
2) [ө]
3) [ү]
4) [е]

А14. Сонор тартыклардан торган рәтне күрсәтегез.

1) [къ], [гъ], [х], [ң]
2) [с], [з], [д], [т]
3) [г], [л], [р], [ш]
4) [м], [н], [ң]

А15. Яңгырау тартыклар ...

1) тоннан гына тора
2) шаудан гына тора
3) шау өстенлек итеп, тон катнаша
4) тон өстенлек итеп, шау катнаша

А16. Саңгырау тартыклы сүзләрдән генә торган рәтне күрсәтегез.

1) дөнья, җир, галим, яңгыр
2) китап, күк, сөт
3) яз, елмаю, җитди, боз
4) күзлек, өстәл, тәрәзә, безнеңчә

А17. Саңгырау тартыклардан гына торган рәтне күрсәтегез.

1) [п], [ф], [к], [къ], [т], [ш], [с], [ч], [ц], [щ], [х], [h]
2) [б], [в], [г], [гъ], [д], [ж], [л], [р], [м], [н], [ң], [й], [w]
3) [б], [п], [в], [ф], [г], [к], [д], [т]

А18. [ә] авазы — ...

1) түбән күтәрелешле, иренләшмәгән арткы рәт сузыгы
2) түбән күтәрелешле, иренләшмәгән алгы рәт сузыгы

А19. Калын сузыклы сүзләр кергән рәтне күрсәтегез.

1) әни, кадерле, кадәр, хисап

2) чыршы, карбыз, халык, байлык

3) җиләк, тимер, тәрәзә, китап

4) сәнәк, чиләк, тәмләткеч, көнбагыш

А20. Сүз азагында килгән [п], [к] тартыклары артыннан тартык авазга башланган кушымча килсә, [п], [к] авазлары ...

1) яңгыраулаша

2) төшеп кала

3) үзгәрми

А21. Сүзләр кайсы вариантта бары тик сузык авазларының рәте белән генә аерылалар?

1) бел — бул

2) кал — кил

3) ук — юк

4) кул — күл

А22 Кайсы сүздә җ хәрефе язылса да, [ч] авазы әйтелә?

1) җәмгыять

3) иҗтимагый

2) җитмеш

4) җимеш

А23. Кайсы сүздә хәреф ике авазны белдерә?

1) элгеч

2) йолдыз

3) ялкын

4) карый

А24. ***Кулъяулык*** *сүзендә —*

1) 9 хәреф, 9 аваз

2) 9 хәреф, 8 аваз

3) 9 хәреф, 10 аваз

4) 8 хәреф, 9 аваз

А25. Хәреф саны аваз саны белән туры килгән сүзләр рәтен күрсәтегез.

1) без, басым, кызыл

2) китап, тырышлык, яз

3) егет, яшел, ямаулык

А26. Басымы икенче иҗеккә генә төшкән сүзләрдән торган рәтне күрсәтегез.

1) кайталар, эшләмә, барадыр, татарча

2) кермә, килгән, яшел, быел

3) сүзлек, белгеч, түтәл, кемдер

4) бүген, көндез, кышын, якты

А27. Басым соңгы иҗеккә төшмәгән очракны күрсәтегез.

1) яшеллек

2) ямь-яшел

3) яшелләндерү

4) яшькелт

А28. Түбәндәге иҗек калыпларына туры килгән җөмләне күрсәтегез.

ТС+ТСТ ТСТ+ТСТ ТСТ+ТС+ТС ТС ТСТ+ТС

1) Туган якның төннәре дә якты! (Р.Зәйдулла)

2) Кешеләргә булган ачуны табигатьтән алмыйлар. (Ф.Яруллин)

3) Иң ярлы кеше — туган җирсез кеше. (Г.Гыйльманов)

4) Җир астыннан чыккан су гына саф. (К.Кәримов)

А29. Хәреф саны аваз санынннан күбрәк булган сүзләрне күрсәтегез.

1) мәгънә, сәгать, Сәгъди

2) мәсәл, мәсьәлә, яңалык

3) елан, юлбарыс, яңарыш

А30. Татар теленең үз сүзләре ничә төрле иҗек калыбы белән ясалалар?

1) 4

2) 5

3) 6

4) 8

*А31. **Сузык + тартык + тартык** калыбына туры килгән иҗекне күрсәтегез.*

1) арт - та

2) карт — лык

3) уй –нау

4) а-на-лар

А32. Тартык авазга тәмамланган иҗек ...

1) ачык иҗек була

2) ябык иҗек була

А33. Ачык иҗекләр рәтендә кайсысы артык?

1) ка-, ба-, та-

2) ти-, бит-, ри-

3) а–на, а–та, ба–ла

А34. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрдә нинди аваз үзгәреше күзәтелә?

*Җыеп **кына әйткәндә**, Габдулла агайның җөйләре күзгә күренеп сүтелеп бара иде. (Ф.Хөсни)*

1) протеза
2) эпентеза
3) элизия
4) редукция

А35. Авазларның позицион үзгәрешләре нәрсәгә бәйле?

1) авазлар сүзнең кайсы урынында килүенә
2) авазларның бер-берсенә тәэсир итешүенә

*А36. **Идәнгә, кысынкы** сүзләрендә нинди аваз үзгәрешләре күзәтелә.*

1) яңгыраулыкта–саңгыраулыкта охшашлану
2) борын ассимиляциясе
3) ирен ассимиляциясе
4) тел арты һәм кече тел ассимиляциясе

А37. Өлешчә редукция ул –

1) аваз кыскару
2) аваз бөтенләй төшеп калу
3) аваз өстәлү
4) аваз өлешчә кыскару

А38. Сеңелем, урыны сүзләрендә кайсы аваз үзгәрешләре күзәтелә?

1) өлешчә редукция
2) тулы редукция

*А39. **Солы, көзлек, көлке** сүзләре сингармонизмның кайсы төренә карый?*

1) рәт гармониясе
2) ирен гармониясе

А40. Сүзләрнең дөрес әйтелешен фонетиканың кайсы бүлеге өйрәнә?

1) орфография
2) орфоэпия
3) графика

А41. Алынма сүзне табыгыз?

1) җир
2) җиләк-җимеш
3) келәй
4) туганкай

*А42. **Такта, идән, кара** сүзләре нинди принципка нигезләнеп языла?*

1) фонетик
2) график

3) морфологик

4) тарихи — традицион

А43. Татар халкыныц язу тарихы түбәндәге этаплардан торган.

1) рун язуы → гарәп язуы → латин язуы → кирилл язуы

2) гарәп язуы → латин язуы → рун язуы → кирилл язуы

3) рун язуы → латин язуы → рун язуы → кирилл язуы

А44. Безнең көнгә килеп җиткән истәлекләр арасында кайсысы рун хәрефләре белән язылган?

1) “Хан улы һәм ана юлбарыс турында легенда”

2) “Борынгы Турфан җырлары”

3) Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәре

4) Билгә каганга багышланган өзек

А45. Кирилл язуына нигезләнгән алфавит кайчан гамәлгә кергән?

1) 1927 нче елда кабул ителә

2) 1929 нчы елда кабул ителә

3) 1939 нчы елда кабул ителә

А46. Кайсы төр басым булмый?

1) сүз басымы

2) логик басым

3) фраза басымы

4) текст басымы

*А47. **Бүлмә, идән, үрнәк, биш** сүзләре нинди орфографик принцип нигезендә языла?*

1) фонетик принцип

2) морфологик принцип

3) тарихи-традицион принцип

4) график принцип

А48. Сүзләрне тарихи-традицион принцип нигезендә язу –

1) сүзне ишетелгәнчә язу

2) морфемаларның бөтенлеген саклап язу

3) сүзләрнең элеккеге язылышын саклап язу

4) сүзне чыганак телдәгечә язу

А49. График принципка нигезләнеп язылган сүзләрне күрсәтегез?

1) Телевизор, физика, математика, помидор

2) өстәл, келәй, эшләпә, эскерт

3) келәм, бер, ике, җиләк

4) унбиш, унбер, көнбагыш, әнкәй

А50. ъ билгесе кайсы очракта аеру вазифасын башкара?

1) ашъяулык
2) ягъни
3) кулъяулык
4) нәкъ

*А51. **Тозсыз** сүзенең дөрес транскрипциясен күрсәтегез.*

1) [тозсыз]
2) [тоссыс]
3) [тоссос]
4) тоссоз]

*А52. Кайсы сүздә "**h**" хәрефе языла?*

1) ...ата
2) мә...абәт
3) ...олык
4) ...аклык

А53. Лексика термины нинди мәгънә белдерә?

1) сүзлек составын өйрәнә торган фән
2) телнең сүзлек составы

А54. Билгеләмәдә кайсы термин турында әйтелә?

Бер сүздәге билге-атаманың охшашлык нигезендә икенче сүзгә күчеше

1) метонимия дип атала
2) метафора дип атала
3) синекдоха дип атала
4) функция буенче күчеш дип атала

А55. Антонимнар –

1) капма-каршы мәгънәле сүзләр
2) бер үк яки якын мәгънәле, мәгънәдәш сүзләр
3) әйтелешләре очраклы туры килгән сүзләр

А56. Фонетик архаизмнарны күрсәтегез.

1) аптека — даруханә
2) баргачтын — баргач
3) берләп — беләп
4) җәдвәл — таблица

*А57. **Семья — гаилә, республика — җөмһүрият** сүзләре нинди төр синонимнар булып торалар?*

1) идеографик синонимнар
2) абсолют синонимнар

А58. ***Телевизор — зәңгәр экран*** *сүзләре ниндитөр синонимнар булып торалар?*

1) мәгънәви синонимнар
2) стилистик синонимнар

А59. Синоним парлардан ясалган сүзләрне күрсәтегез.

1) аллы-гөлле
2) ишекле-түрле
3) кыз-кыркын
4) аклы-каралы

А60. Үзара антоним булган сүзләрне күрсәтегез.

1) ак — алсу
2) матур — чибәр
3) җылы — салкын
4) герб — тугра

А61. Шаку, бәргәләү, сугып кертү, кадаклау, җилпенү (канат белән), читкә этәрү, кыерсыту, якын итмәү мәгънәләрен аңлаткан ***кагу*** *сүзе кайсы күренешкә туры килә?*

1) омонимнар
2) синонимнар
3) күпмәгънәле сүзләр
4) антонимнар

А62. Омонимнарның бер төре булган омографларны күрсәтегез.

1) Айсылу — ай, сылу
2) атлас — атлас
3) тозлар — тозлар
4) чаба — чаба

А63. Җирле төбәк сүзләре ничек атала?

1) архаизм
2) диалектизм
3) неологизм
4) омоним

А64. Искергән сүзнең төрен билгеләгез.

Угыл –

1) тарихи сүз
2) архаизм

А65. Сүзләрнең кулланылыш ешлыгын күрсәтә торган сүзлекне күрсәтегез.

1) тәрҗемәле сүзлек
2) аңлатмалы сүзлек

3) кире сүзлек

4) ешлык сүзлеге

А66. Билгеле бер һөнәр ияләре куллана торган сүзләр ничек атала?

1) неологизм

2) профессионализм

3) диалектизм

4) искергән сүзләр

А67. Тел гыйлеменең тотрыклы сүзтезмәләрне өйрәнә торган тармагы ...

1) фразеология дип атала

2) синонимия дип атала

3) лексикография дип атала

4) этимология дип атала

А68. Фразеологизмнар арасында артык рәтне күрсәтегез.

1) кара кайгыга бату

2) йөзенә кара ягу

3 күзенә ак-кара күренмәү

4 кара төс

А69. Фразеологизмның дөрес аңлатмасын күрсәтегез.

Борчак пешмәү –

1) пешерә белмәү

2) килешә алмау

3) сүрән утта кайнау

А70. Үзара синоним булган фразеологик әйтелмәләрне күрсәтегез.

1) кәкре каенга терәтү — агач атка атландыру

2) түбәсе күккә тию — авазы салыну

3) ерак китү — көймәсе комга терәлү

4) агым уңаена йөзү — агымга каршы йөзү

А71. Бер-берсе белән ныклы мәгънәви бәйләнештә торган сүзләрне күрсәтегез.

1) омоним

2) күпмәгънәле сүзләр

*А72. **Венера, Лилия, Роберт, Рим** исемнәре кайсы телдән кергән?*

1) гарәп теленнән

2) фарсы теленнән

3) рус теленнән яки рус теле аша европа телләреннән

4) татар теленең үз сүзләре

А73. Искергән сүзләрне ...

1) актив сүзләр дип йөртәләр

2) пассив сүзләр дип йөртәләр

А74. Теге яки бу фәнгә караган фәнни хезмәтләрнең исемлеген туплаган сүзлекләр ...

1) библиографик сүзлекләр дип атала
2) фразеологик сүзлекләр дип атала
3) диалектологик дип атала
4) этимологик дип атала

А75. Сүзнең дөрес әйтелеше турында мәгълүмат табып була торган сүзлекләр ничек атала?

1) диалектологик сүзлекләр
2) фразеологик сүзлекләр
3) орфоэпик сүзлекләр
4) орфографик сүзлекләр

А76. Диалектологик сүзлекләрдә ...

1) фразеологик әйтелмәләрнең мәгънәләре аңлатыла
2) җирле сөйләшкә караган сүзләрнең мәгънәләре аңлатыла
3) терминнарга аңлатма бирелә

А77. Сүз ясалышының төп терминнары арасында артык очракны күрсәтегез.

1) тамыр
2) басым
3) нигез
4) кушымча

*А78. Я*ңа мәгънәле лексик берәмлек тудыра торган кушымчалар ...

1) сүз ясагыч кушымчалар дип атала
2) бәйләгечләр дип атала

*А79. Кайсы сүздә **-ләр** кушымчасы юк?*

1) әниләр
2) күренешләр
3) сүзләр
4) сөйләр

А80. Кайсы төркемдә сүз ясагыч та, мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларның да ике төре бар?

1) авылдашларым, җырладык
2) шәһәрчекнең, сөйләштек
3) кагыйдәне, русча

*А81. **-дык/-дек** сүз ясагыч кушымчалы сүзне билгеләгез.*

1) утырдык

2) урындык
3) карадык
4) җырладык

А82. Тамыр сүзне күрсәтегез.

1) шәһәрчек
2) кызчык
3) бөркәнчек
4) сыерчык

А83. Үзара антонимнардан торган парлы сүзләрне күрсәтегез.

1) чыр-чу
2) тавыш–гауга
3) ата-ана
4) бала-чага

А84. Сыйфат сүз ясагыч кушымчаларны билгеләгез.

1) –гы/-ге, -кы/-ке
2) -га/-гә, -ка/-кә
3) -чылык/-челек
4) -ча/-чә

А85 Аваз төшеп калу яисә өстәлү, сүзнең басымы үзгәрүе белән яңа сүз ясалу ничек атала?

1) фонетик ысул
2) морфологик ысул (кушымчалау ысулы)
3) синтаксик ысул
4) конверсия

А86. Кайсы төркемдәге сүзләр ике морфемадан тора?

1) байлык, ташбака
2) китап, дәфтәр
3) җайланма, беркетмә
4) җырчы, шәһәрчектән

А87. Кушымчалау ысулы белән ясалган сүзне күрсәтегез.

1) карт-коры
2) карт
3) картлык
4) картны

*А88. **Җиде-сигез** кеше басып тора җөмләсендәге калын хәрефләр белән бирелгән сүз кайсы сүз төркеменә карый?*

1) исем

2) сыйфат

3) рәвеш

4) сан

А89. ***Ачлы-туклы*** *сүзенең ясалу ысулы ягыннан төрен күрсәтегез.*

1) тамыр сүз

2) ясалма сүз

3) парлы сүз

4) кыскартылма сүз

А90. ***Азчылык*** *сүзенең мәгънәле кисәкләргә дөрес бүленгән очрагын күрсәтегез.*

1) азчылык

2) аз-чы-лык

3) аз-чылык

4) азчы-лык

А91. Сүз ясагыч кушымчаны күрсәтегез.

1) –дан/-дән

2) –даш/-дәш

3) –да/-дә

А92. Кайсы рәттә сүзнең тамыры дөрес билгеләнмәгән?

1) җайсыз (җай-)

2) җырлау (җырла-)

3) яшелләндерү (яшел-)

4) язгы (яз-)

А93. Модальлек белдерүче кушымчаларны күрсәтегез.

1) -ны, -не, -ның, -нең, -га, -гә, -дан, дән, -да, дә

2) -чы, -че, -гы, -ге, -лык, -лек, -ла, -лә

3) -нчы, -нче, -ау, -әү, -шар, -шәр,

4) -ча, -чә, -дай, -дәй, -лай, -ләй

А94. Татар теленең функциональ стильләрен күрсәтегез.

1) матур әдәбият стиле, драматургия стиле, поэзия стиле

2) матур әдәбият стиле, көндәлек матбугат стиле, эш кәгазьләре стиле, фәнни стиль, эпистоляр стиль

3) борынгы стиль һәм хәзерге заман стиле

А95. Түбәндәге текст кайсы стильгә карый?

Соры һәм куе соры урман туфраклары Кама алды, Төньяк Идел алды, Көнчыгыш Кама аръягы районнарында һәм Кама аръягының көнбатышында таралган.

Физик-химик үзенчәлекләре һәм уңдырышлылыгы ягыннан соры урман туфрагы кара туфрактан түбәнрәк, ләкин көлсу һәм кәсле-көлсу туфраклардан өстенрәк тора. Аларның черемәле катламы, кара туфрак белән чагыштырганда, юкарак, гумуска ярлырак (гумус 3,5 — 4,5%). Һава һәм су йөреше дә начаррак, чөнки өске катламның структурасы һәм механик составы сыйфат ягыннан түбәнрәк. (Ә.Тайсин)

1) әдәби стиль
2) фәнни стиль
3) рәсми стиль
4) хатлар стиле

А96. Беркетмә, гариза, ышаныч язулары языла торган стильне күрсәтегез.

1) матур әдәбият стиле
2) публицистик стиль
3) фәнни стиль
4) рәсми стиль

А97. Синтаксик синоним булып торган җөмләләрне күрсәтегез.

А) Кышлар җитәр һәм без чаңгы шуарга чыгарбыз.
Ә) Кышлар җитәр. Без чаңгы шуарга чыгарбыз.
Б) Кышлар җитү белән, без чаңгы шуарга чыгарбыз.
В) Кышлар җитәр, шуннан соң без чаңгы шуарга чыгарбыз.

1) АВ
2) АБ
3) АӘ
4) БВ

А98. Стилистик яктан дөрес булмаган җөмләне табыгыз.

1) Ул үзенең шәхси фикерен әйтергә кирәк тапмады.
2) Һәр яңалык үзе белән каршылыклар да алып килә. (С.Кальметов)
3) Авыл халкы кыланган кешене яратмый ул. (Ф.Бәйрәмова)
4) Иң ярлы кеше — туган җирсез кеше. (Г.Гыйльманов)

А99. Кемнең дә булса берничә сөйләшә һәм аңлаша алуы нинди күренеш дип атала?

1) билингвизм
2) полилингвизм

А100. Сочинение өчен тәкъдим ителгән темалар арасында иң киң мәгънәлесен сайлап алыгыз.

1) Кыңгыраулы мәктәп еллары.
2) Чыгарылыш кичәсе.

3) 1 нче сентябрь — Белем бәйрәме.

4) Минем партадашым.

В

Текст өстендә эш

1 нче текст

Текстны укыгыз. Биремнәрне үтәгез.

(1) Язмыш синең тез астыңа китереп сукса — егылмас өчен якасына ябыш. (2) Утларга салса — үзең аннан да көчле ян, шул вакыт аның кызуын сизмәссең. (3) Суларга ташласа — күбек булып өскә күтәрелмә — асылташ булып төпкә бат, ялтыравыңны күреп, чумып алырлар. (4) Тузан итеп һавага күтәрсә — яңгыр тамчыларына кушылып, җиреңә төш. (5) Карурманнарда адаштырса — кояшка карап юл сайла. (6) Ташлар белән бастырса — чишмәгә әверелеп, иреккә ургы. (7) Җиргә күмсә — орлык шикелле тишелеп чык. (8) **Җилкәнеңне** җилләр екса — йөрәгеңне җилкән итеп күтәр. (9) Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән. (10) Көчле рухлылар гына максатларына ирешә алалар. (11) Түземнәр генә бәхеткә лаек.

(86 сүз)

В1. Текст кайсы әсәрдән алынган? Аның авторы кем?

В2. Текстка исем бирегез.

В3. 6 нчы җөмләдәге фигыльләрне күчереп яз, төркемчәсен билгелә.

В4. 1-2 җөмләләрдән исемнәрне күчереп языгыз.

В5. Тексттан кушма сүзләрне күчереп языгыз.

В6. Калын шрифт белән бирелгән сүзгә морфологик анализ ясагыз.

В7. Астына сызылган сүзнең синтаксик вазыйфасын һәм нәрсә белән белдерелүен билгеләгез.

В8. Интонациясе буенча соңгы җөмләнең төрен күрсәтегез.

В8. Кайсы җөмләләрдә текстның төп мәгънәсе чагылыш тапкан?

С. Текстта нәрсә турында сүз бара? *Түземнәр генә бәхеткә лаек* җөмләсен ачыклап, үз фикерләрегезне языгыз.

2 нче текст

Текстны укыгыз һәм тексттан соң бирелгән биремнәрне үтәгез.

(1) Адәми зат җир йөзенә килеп тә, үзенең кем булуы, тамырларының кая барып тоташуы турында уйланмый икән, андый бәндәдән өметеңне өз, юлдаш

булма, чөнки андый зат иң җаваплы бер мәлдә юлдашын гына түгел, илен дә сатачак, чөнки ул җирлексез, тамырсыз корыган агач. (2) Туган җир, изге туган туфрак ул — шаулап үсеп утырган зур агач, ә яфраклары — без. (3) Ул агачның тирәнгә киткән нык тамырлары — безнең яшәешнең киләчәге. (4) Үткәнебез, тарихыбыз исә — гасырлар буена тупланып килгән китапларыбызда. (5) Теге яки бу халыкның үткәне — аның җиңелү белмәс дәһшәтле коралы да. (6) Гыйбрәтле тарих булмаса, ничек итеп дошманга каршы тормак кирәк. (7) Шуңа күрә дә дошман явы килә-нитә калса, алтын-көмешкә, башка төрле **мал-мөлкәткә** түгел, иң әүвәл бәһа белмәс хәзинәгә — китапка каныга торган булган. (8) Гасырлар буена шулай килгән. (М.Хәсәнов) (119 сүз)

В1. Текстка исем бирегез.

В2. 1 нче җөмләләрдән ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз.

В3. Тексттан гарәп һәм фарсы сүзләрен күчереп языгыз.

В4. Тексттагы *адәми зат, бәндә* сүзләрен сез ничек аңлыйсыз, бу сүзләр *кеше* сүзенә карата нинди мөнәсәбәттә?

В5. 7 нче җөмләдә калын хәрефләр белән бирелгән сүзне сүз ясалышы ягыннан билгеләгез.

В6. 5 нче җөмләдәге тыныш билгеләренең куелышын аңлатыгыз.

В7. 2 нче җөмләнең төзелеше ягыннан төрен билгеләгез.

В8. 2 нче җөмләнең төзелеше ягыннан төрен билгеләгез.

С. *Акыллылар алга бара*

үткәне аша... (Акъегет) гыйбарәсен сез ничек аңлыйсыз? Әлеге юлларның текст белән бәйләнешен аңлатыгыз. Үз фикерегезне берничә җөмлә белән языгыз.

3 нче текст

Текстны укыгыз, биремнәрне үтәгез.

(1) Мең тугыз йөз сиксән өченче елны, Ярослав Гашекның 100 еллык юбилеенда катнашырга дип, Чехословакиягә бардым. (2) Прагада экскурсия вакытында безгә бер агай килеп кушылды. (3) Гомерендә беренче күрүе булса да, без аның өчен якын идек, чөнки без — аның ата-бабасы иленнән, туган җиреннән килгән кешеләр. (5) Сирәк-мирәк, үзе сиздермәскә тырышса да, мин аның күзләре дымлануын да искәрдем. (6) Юкка гына әйтмәгәннәр шул: малын җуйган җиде ел елар, иленнән аерылган — гомере буе.

(7) Дөнья киң. (8) Адәм баласы йөремсәк. (9) Ул кай тарафларга гына барып чыкмый, … ул һәрчак кендек каны тамган җирен — изге туган җирен

сагынып кайта, чөнки аның бәхете — туган илендә, туган җирендә. (Р.Кәрами) (96 сүз)

В1. Текстка исем бирегез.

В2. Текст нинди стильдә язылган?

В3. Икенче абзацтан хәреф саны белән аваз саны туры килмәгән сүзне күрсәтегез.

В4. Тексттан саннарны күчереп языгыз һәм төркемчәсен билгеләгез.

В5. Астына сызылган сүзне сүз ясалышы ягыннан тикшерегез.

В6. 9 нчы җөмләдәге күпнокталар урынына бәйләүче чараларның кайсысын куярсыз?

1) чөнки

2) әмма

3) аеруча

4) ки

В7. 3 нче җөмләнең төзелеше ягыннан төрен билгеләгез.

В8 5 нче җөмләне аналитик иярченле кушма җөмлә итеп үзгәртеп языгыз.

С. *Текст нәрсә турында? Авторның әйтәсе килгән фикере нинди? Язмагызда туган җир турында татар халык мәкальләре кулланып языгыз.*

4 нче текст

Текстны укыгыз, биремнәрне үтәгез.

(1) Беренче тапкыр мәктәпкә килгәч, мөгаллим безне идәнгә җәйгән салам өстенә тезеп утыртты. (2) Һәрберебезгә берәр дәфтәр, карандаш һәм кечкенә такта бирде... (3) Ул безне гаҗәеп бер түземлек белән үзе белгән бар нәрсәгә өйрәтте. (4) Һәр укучыга карандашны ничек тотарга кирәген күрсәтте, аннары, дәртләнеп китеп, таныш булмаган сүзләрне аңлата торган иде.

(5) Шуларны хәзер искә төшерәм дә таң калам — үзе көчкә иҗекләп кенә укыган, кулында бер генә дәреслеге, хәтта гади әлифбасы да булмаган ярым надан ул егет шундый зур эшкә алынырга ничек җөрьәт итте икән? (6) Бабалары һәм җиденче буынга кадәр бабаларының бабалары әлифне таяк дип белмәгән балаларны укыту **уен эш түгел бит**!

(7) Дәйшән безне үзе белгәнчә, кулыннан килгәнчә, күңел сиземе буенча укыткан. (8) Ул үзе дә белмәстән батырлык эшләде. (9) Әйе, ул көннәрдә безгә, авылдан беркая чыкмаган кыргыз балаларына, мәктәптә, дөресрәге,

ярыкларыннан һәрвакыт карлы тау түбәләре күренеп торган балчык өйдә, кинәт яңа, күз күрмәгән, колак ишетмәгән дөнья ачылды.

(Чыңгыз Айтматов) (141 сүз)

В1. Астына сызылган сүзнең транскрипциясен бирегез.

В2. 1–3 җөмләләрдән алынма сүзләрне күчереп языгыз.

В3. 2 нче абзацтан фразеологизмнарны табып языгыз.

В4. Беренче абзацтан кушма сүзне язып алыгыз.

В5. 3 нче һәм 5 нче җөмләләрдәге **ул** алмашлыгының синтаксик вазыйфаларын билгеләгез.

В6. Аныклагычы булган җөмлә санын күрсәтегез.

В7. Аерымланган вакыт хәле булган җөмләнең санын күрсәтегез.

В8. 3 нче җөмләнең төрен билгеләгез.

11 НЧЕ КЛАСС

1 нче вариант

1. *Мирасханә, шифаханә, сырхауханә, даруханә, вәкаләтханә, кунакханә, чәчтарашханә* сүзләренең аңлатмасын языгыз.

2. ***Бәхет*** *сүзе кергән фразеологик тезмәләр языгыз һәм мәгънәләрен аңлатыгыз.*

3. *Түбәндәге фразеологизмнарның мәгънәсенә туры килгән русча эквивалентларын языгыз:*

көлен күккә очыру -

корыны бушка аудару -

иләк белән су ташу -

күзгә төшеп җибәрү -

4. *Татар халык мәкальләреннән рус алынмаларын табыгыз һәм мәгънәләрен аңлатыгыз. Нинди фонетик үзгәрешләр барлыкка килгән?*

1. Ярый безгә, каткан тезгә, чәй булмаса, мәтрүшкә.

2. Күрмәгәнгә алабута тансык.

3. Юл кунагы килә белсен, күчтәнәчен бирә белсен.

5. *Түбәндәге очракларны 1) тезмә сүзгә һәм 2) сүзтезмәләргә аерып языгыз.*

Кара бүрек, кара җиләк, кара карлыгын, кара төс, кара карга, кара күлмәк, кара урман, кара алтын, кара тап, кара савыт.

6. *Түбәндәге даталарны үзләре туры килгән филология өлкәсендәге вакыйгалар белән туры китереп языгыз.*

а) латин графикасына нигезләнгән татарча язу (яңалиф) кертелә;

ә) бөтендөнья татарларының беренче корылтае була;

б) татар теле һәм әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен Габдулла Тукай исемендәге премия бирелә башлый;

в) Габдулла Тукай туа;

Даталар: 1927 нче елның 3 нче июлендә; 1986 нчы елның 26 апрелендә; 1992 нче елда; 1966 нчы елда.

7. *Түбәндә китерелгән исемнәр белән җөмләләр төзеп языгыз. Мәгънә төсмерләренә игътибар итегез.*

Шатлык-шатлыклар; батырлык — батырлыклар.

8. *Сүзтезмәләр ясагыз. Һәр очракта да сүзләрне үзара бәйләнешкә кертеп буламы?*

Сәләтле (бала, эш); әзер (текст, ярдәм); каты (кич, таш); уңган (кыз, аш); тәмле (язма, ашамлык).

9. ***Ул*** *алмашлыгын килешләр белән төрләндерегез.*

10. *Фигыльләрнең юнәлешләрен күрсәтегез.*

сөйләшү –

уйлану –

булышу –

кизәнү –

ятлату –

11. *Төрле сүз төркемнәренә караган сүзләрнең ымлык булып килүенә 5 мисал языгыз һәм аларның мәгънәләрен аңлатыгыз.*

12. *Баш килештәге исемнәрнең нинди җөмлә кисәге булып килә алуын мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз.*

13. ***Бер*** *сүзе нинди мәгънәләрдә һәм функцияләрдә кулланыла? Аңлатыгыз.*

1. Беренче шатлыгым минем, беренче йөрәк ярам. (Ә.Д.)

2. Бер дә юк ул патшаның мылтык, кылыч-алмаслары,
Һәр ягында аллы-гөлле күбәләктән гаскәре. (Г.Тукай)

3. Бер тавык бер үрдәк белән бергә торып,
Бер курада бергә ашап, бергә йөреп,
Бара торгач, бер-берсилә дуслаштылар,
Берсе-берсен туган төсле якын күреп. (М.Гафури)

4. Шулай барганда,
Очрады юлда
Матур бер елга,

Үзе тар гына. (Г.Толымбай)

5. Бер минутта бу Сарбай
Тилгәнне тотып алган,
Чирәмдә тик Тилгәннең
Тузгып, йоннары калган. (Х.Шабанов)

6. Эш күбәйде әбигә;
Йөгереп йөри ул өйдә.
Бер иелә, бер чүгә,
Бер суза кулын чөйгә. (К.Нәҗми)

14. ***Җылы сөяк сындырмый, салкын җанны тындырмый*** *җөмләсендә ияне билгеләгез, сүз төркеме буларак анализлагыз.*

15. *Синтаксик берәмлекләрне "үсә бару" тәртибендә урнаштырыгыз.*

1) гади җөмлә
2) сүзтезмә
3) синтагма
4) синтаксик бөтен
5) текст
6) кушма җөмлә

16. *Җөмләне дәвам итеп бетерегез. Шәхесләрне берсенә тулырак мәгълүмат бирегез.*

Каюм Насыйри –
Бакый Урманче –
Салих Сәйдәшев —
Мөхәммәт Мәһдиев –
Сайлап алу өчен җөмләнең дәвамнары:
татар профессиональ сынлы сәнгатенә нигез салучыларның берсе; татар халкының иң сөекле, иң данлыклы композиторы; Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты; татар мәгърифәтчелек фикеренең иң күренекле вәкилләренең берсе, энциклопедик белемле галим, язучы, акыл иясе — гуманист.

17. *Җөмлә кисәкләренең кайсы сүз төркеме белән белдерелүен күрсәтегез.*

1) Тәнне — су белән, җанны күз яше белән юалар. (Ә.Баян)
2) Кеше җаны һәрвакыт матурлыкка сусап яши. (Ф.Яруллин)
3) Кырык ел көтү көтеп чыбыркы шартлата белмәгән кеше кырык беренче елында өйрәнә алмас. (Ә.Баян)

18. *Җөмләләрне җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерегез. Сүз төркемнәрен билгеләгез.*

1) Уңган кеше кулында туфрак алтынга әйләнә. (Т.Галиуллин)

2) Елмаю ул — күңелдән күңелгә сузылган күпер. (Ф.Яруллин)

3) Кешедәге матурлыктан көчлерәк матурлык юк дөньяда. (Х.Вахит)

19. *Җөмләдәге вакыт хәлләрен вакыт җөмләгә әйләндереп языгыз.*

Җәен яшенле яңгырлар бик еш була.

Майда агачлар яфрак яра.

20. *Жөмләләргә морфологик-синтаксик анализ ясагыз.*

1) Сал да мине ап-ак биләвеңә

Бишек җыры җырла, карурман! (Р.Вәлиев)

2) Сәләтлеләр күтәрә алмаган илне сәләтсезләр күтәрәмгә калдыра. (М.Галиев)

21. *Кирәкле урынга тиешле тыныш билгеләрен куегыз.*

1) Әни өмәче кызларны сыйларга дип каз итеннән үпкә бавырыннан мул итеп аш белән бәлеш пешергән (Г.Бәширов)

2) Бу яшеллекләр бу сулар бу зәңгәр күкләр һәммәме дә кешенең тормышын ямьләү өчен генә яратылгандыр (Ф.Садриев)

22. *Җөмләләрдән хәбәрлекле мөнәсәбәттә торган сүзләрне язып алыгыз.*

1) Дөнья ямен, яшәү хозурлыгын

Аңлар өчен вакыт җитми һич тә. (Ш.Җиһангирова)

2) Кояшлы көз, алтын гомер теләп,

Сары чәчәк ата көнбагыш. (Ә.Баян)

3) Гали затлар үз йөрәгендәге кояшның нурын соң тамчысына кадәр, кызгынмыйча, ижатына салып китә. (М.Галиев)

23. *Сүзтезмәләрдәге бәйләүче чараларны күрсәтегез.*

Кара яулыгы, баланың күзләрендә, утыра торган урын, бакчадагы чәчәкләр, борчак кадәрле миңле, аларны очраштырды, эшләргә куштым, бару-бармау турында сөйләштек, узган атнада, күрүгә таныдым.

24. *Бирелгән җөмләләрдән сүзтезмәләрне аерып чыгарыгыз.*

1) Ак шомыртлар куанышып

Чакырдылар ак туйга. (Ә.Гадел)

2) Исем ул — синең тормыш юлыңнан күтәреп барган үз байрагың. (М.Юныс)

25. *Җөмләләрдә калын хәрефләр белән бирелгән сүзләр арасындагы мөнәсәбәтне билгеләгез.*

1) Баш иярләр һәрвакыт белемлегә. (Утыз Имәни)

2) Матур ялганга бөтенебез ышана. (Ф. Яруллин)

3) Күктә, биектә-биектә, бер-бер артлы йолдызлар кабына башлады. (Ф.Шәфигуллин)

26. *Җөмләләрнең төрен атагыз.*

1) Мин туңам.

2) Туңдыра.

3) Туңдым һәм арыдым.

4) Туңдым — кермәдем.

5) Туңдым — кертмәделәр.

27. *Җөмләнең төзелеше һәм мәгънәсе ягыннан төрен билгеләгез.*

1) Туган телең искә төшә икән,

Хәл ителгән чакта язмышлар. (С.Хәким)

2) Шунысы гажәп: бу дәһшәттән

Без ничек калдык әле? (И.Юзеев)

28. *Җөмләнең схемасын сызыгыз, төзелеше һәм мәгънәсе ягыннан төрен билгеләгез.*

Хуш исләрен гөлләр сипкәндә,

Тәрәзәмне җилләр чирткәндә

Карамадың нигә әйләнеп,

Яннарымнан үтеп киткәндә. (Ә.Ерикәй)

29. *Катлаулы кушма җөмләләрдәге гади җөмләләрнең чиген билгеләгез, иярчен җөмләләрнең мәгънәсе һәм төзелеше ягыннан төрен билгеләгез.*

1) Килсә, мин, сез палатага кереп җиткәнче, аннан сөенеч алам. (В.Нуриев)

2) Син булмасаң белмәс идем

Игелек бар диеп җирдә. (Ш.Җиһангирова)

30. *Түбәндәге сүзтезмәләрне укыгыз. Нинди хата бар?*

Тулы аншлаг, истәлекле сувенир, потенциаль мөмкинлекләр, беренче премьера, иң беренче чиратта.

Тестлар

А1. Телнең беренчел фунциясен күрсәтегез.

1) коммуникатив (аралашу)

2) танып белү

3) эмоцияләрне белдерү

А2. Төрки телләр нинди тармакка карый?

1) төрки-монгол тармагы

2) тунгус-маньчжур тармагы

3) япон-корея тармагы

А3. *Татар теле ....*

1) кыпчак төркеменә керә
2) угыз төркеменә керә
3) болгар төркеменә керә

А4. *Татар теле — ...*

1) тамыр тел
2) полисинтетик тел
3) флектив тел
4) агглютинатив тел

А5. *Телгә кагылышлы гомуми мәсьәләләр ...*

1) гомуми тел белемендә тикшерелә
2) хосусый тел белемендә тикшерелә

А6. Татар теленең ничә диалекты бар?

1) 2
2) 3
3) 4
4) 5

А7. Татар теленең диалектларын күрсәтегез.

1) урта, себер
2) урта, мишәр, себер
3) урта, керәшен, тау ягы
4) себер, мишәр

А8. Татар теленең көнчыгыш диалекты ул — ...

1) мишәр диалекты
2) Казан арты сөйләше
3) Себер татарлары теле
4) урта диалект

А9.Татар телендә ...

1) аффикслар берьюлы берничә мәгънә белдерә
2) аффикслар бер генә мәгънә белдерә

А10. Морфология нәрсәне өйрәнә?

1) җөмлә кисәкләрен
2) авазлар һәм хәрефләрне
3) сүз төркемнәрен
4) телнең диалектларын

А11. Тамырга ялганып, аңардан яңа сүз ясый торган кушымчалар ...

1) төрләндергеч кушымчалар
2) төр кушымчалары
3) сүз ясагыч кушымчалар

А12. Исем — ...

1) ярдәмлек сүз төркеме
2) җөмлә кисәге
3) модаль сүз
4) мөстәкыйль сүз төркеме

А13. ***Куян баласы, әдәбият белеме, бала киеме*** *мисаллары ничәнче төр изафә булалар?*

1) I төр изафә
2) II төр изафә
3) III төр изафә

А14. Предметның кайсы затка караганлыгы нинди кушымчалар ярдәмендә белдерелә?

1) килеш кушымчалары
2) тартым кушымчалары
3) сүз ясагыч кушымчалар
4) кушымчалар белән белдерелми

А15. Кайсы килеш ярдәмендә предметның урыны белдерелә?

1) иялек килеше
2) төшем килеше
3) чыгыш килеш
4) урын-вакыт килеше

А16. Кайсы килештәге исем җөмләдә туры тәмамлык була?

1) баш килештәге исем
2) иялек килешендәге исем
3) юнәлеш килешендәге исем
4) төшем килешендәге исем

А17. Исемнәрдә күплек сан кушымчаларының ничә варианты бар?

1) 2
2) 3
3) 4
4) 5

А18. Төшем килешендәге исемне табыгыз.

1) язын
2) кичен

3) китабын

4) җәен

А19. Кушымчалары ике генә булган килешне күрсәтегез.

1) төшем

2) юнәлеш

3) чыгыш

А20. Предметның билгесен белдерә торган сүз төркемен күрсәтегез.

1) исем

2) фигыль

3) сыйфат

4) рәвеш

А21. Кимлек дәрәҗәсендәге сыйфат …

1) предметтагы билгенең ким булуын белдерә

2) бер предметтагы билгенең икенче бер предметтагы гадәти билгедән кимрәк икәнлеген белдерә

А22. Парлы сыйфатлардан торган рәтне күрсәтегез.

1) күренер-күренмәс, ишекле-түрле, абына-сөртенә

2) зуп-зур, кап-кара, ап-ак

3) бала-чага, савыт-саба, ата-ана

4) аллы-гөлле, аклы-каралы

А23. Саннар, саналмышлары белән килгәндә, …

1) җөмләдә иярчен кисәк (аергыч) хезмәтен үти; тартым белән дә, килеш белән дә төрләнми

2) җөмләдә баш кисәк хезмәтен үти; тартым белән дә, килеш белән дә төрләнә

А24. Калын хәрефләр белән бирелгән санның төркемчәсен билгеләгез.

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм песи,

*Безнең өйдә без **җидәү**... (Г.Тукай)*

1) микъдар саны

2) тәртип саны

3) җыю саны

4) бүлем саны

А25. Мәгънә һәм вазифаларына карап, алмашлыклар ...

1) 5 төркемчәгә бүленә

2) 6 төркемчәгә бүленә

3) 7 төркемчәгә бүленә

А26. Билгеләү алмашлыкларыннан торган рәтне күрсәтегез.

1) мин, син, ул, без, сез, алар
2) һичкем, беркем, һични, бернинди
3) кем, нәрсә, нинди, ничек, кайчан
4) минеке, синеке, аныкы

А27. Грамматик категорияләре иң күп булган сүз төркеме:

1) исем
2) фигыль
3) сыйфат
4) рәвеш

А28. Фигыльнең юклык төре кушымчаларын күрсәтегез.

1) -лы/-ле
2) -дагы/-дәге
3) -ма/-мә
4) -тан/-тән

А29. Сөйләү моментыннан соң башкарыла торган заманны күрсәтегез.

1) хәзерге заман
2) киләчәк заман
3) үткән заман

*А30. **Сөену, шатлану, дулкынлану** фигыльләре нәрсәне белдерә?*

1) хәрәкәтләнүне
2) фикерләүне
3) хис-кичерешне

А31. Зат-сан белән төрләнгән фигыльләр ...

1) затланышлы фигыльләр дип атала
2) затланышсыз фигыльләр дип атала

А32. Боерык фигыль ...

1) боеруны, кушуны белдерә
2) эш, хәл, хәрәкәтнең булуын (яки булмавын) хәбәр итә
3) ниятне, максатны, боеруны, өндәүне, теләкне белдерә һәм -рга/-ргә, -ырга/-ергә кушымчалары ярдәмендә ясала

А33. Шарт фигыльне күрсәтегез.

1) укый, сөйли, белә, яза
2) укы, сөйлә, бел, яз
3) укып, сөйләп, белеп, язып
4) укыса, сөйләсә, белсә, язса

А34. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыль булган мәкальне табыгыз.

1) Ни эшләсәң, шуны ашыйсың.
2) Илгә ни булса, безгә шул булыр.
3) Белеме барның кадере бар.
4) Батыр егет — ил күрке.

А35. Исем фигыльне тап.

1) тыңлаучы
2) булышу
3) эшләргә
4) укый

А36. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыль формасын ясаучы кушымчалар: ...

1) -ыр, -ер, -р
2) -ачак, -әчәк, -ячак, -ячәк
3) барысы да

А37. Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең нигезе ...

1) тартыкка беткән фигыльгә тартыктан башланган кушымча ялгап ясала
2) тартыкка беткән фигыльгә -ачак, -әчәк, сузыкка беткән фигыльгә -ячак, -ячәк кушымчалары ялгап ясала
3) сузыкка беткән фигыльгә сузыктан башланган кушымча ялгап ясала

А38. Хәл фигыльнең өченче төре боерык фигыльгә ...

1) -гач, -гәч, -кач, -кәч кушымчалары ялганып ясала
2) -ып, -еп, -п кушымчалары ялганып ясала
3) -ганчы, -гәнче, -канчы, -кәнче кушымчалары ялганып ясала

А39. Фигыльләр, мәгънәләренә карап, ...

1) гади һәм кушма фигыльләргә бүленә
2) күчемле һәм күчемсез фигыльләргә бүленә

А40. Кайтым юнәлешендәге фигыльләр рәтен күрсәтегез.

1) барган, эшләрләр, киткәннәрде, килмәс
2) юынган, киенгән, каранган
3) укыт, үткәр, күрсәт
4) карашам, күрешәбез, казышканнар

А41. Мөстәкыйль фигыльләр ...

1) аерым торганда, тулы мәгънә белдерә; мөстәкыйль кулланыла
2) аерым торганда, мәгънә белдерми; мөстәкыйль кулланылмый - җөмләдәге башка тулы мәгънәле сүзләргә генә ияреп килә

А42. Көтелмәгән хәлләр кешеләрне якынайтып, хисләрен тазартып җибәрә. (Т.Галиуллин) җөмләсендә **җибәрә** сүзе нинди сүз төркеменә карый?

1) мөстәкыйль сүз төркеме

2) ярдәмче фигыль

3) ярдәмлек сүз төркеме

4) модаль сүз

А43. Вакыт рәвешләреннән торган рәтне күрсәтегез.

1) әкрен, салмак, тиз, җәяү, берьюлы

2) күп, аз, байтак, шактый, сирәк

3) быел, кичә, элек, көзен, башта

4) ерак, югары, түбән, анда, монда, якын

А44. Җыючы теркәгечләрдән торган рәтне күрсәтегез.

1) һәм, да, дә; янә, вә, тагы(н), ни ... ни

2) ләкин, әмма, тик, фәкать, бәлки, ә, бары

3) я, яки, яисә, әллә-әллә, әле-әле

4) әгәр, ки, чөнки, гүя, гүяки, ягъни, бигрәк тә, аеруча

*А45. **Таба (табан), карата, күрә, карамастан, караганда** бәйлекләре кайсы килешне таләп итәләр?*

1) баш килешне

2) юнәлеш килешен

3) чыгыш килешен

4) төрле килешләрне таләп итәләр

*А46. **Кадәр, чаклы, хәтле, тикле** бәйлекләре ...*

1) баш килештәге исемнәрдән соң килгәндә, охшату яки чагыштыру мәгънәсендә кулланыла

2) юнәлеш килешендәге исемнәрдән соң килгәндә, урын яки вакыт чиген белдерә

А47. Калын хәрефләр белән бирелгән сүз кайсы сүз төркеменә карый?

*Үз төсен үзгәртми саклаучы арада берсе **бар**:*

*Көз көне һәм кыш буе саргаймый торган чыршы **бар**. (Г.Тукай)*

1) ымлык

2) аваз ияртеме

3) хәбәрлек сүз

4) бәйлек

*А48. Гаҗәпләнү хисен белдергәндә, **нәрәмәч, әкәмәт, тамаша** кебек сүзләр кайсы сүз төркеменә керә?*

1) исемнәргә

2) ияртемнәргә

2) ымлыкларга

4) сыйфатка

А49. Аваз ияртемнәре артыннан өтер ...

1) куела
2) куелмый

А50. Көчәйткеч кисәкчәләр ярдәмендә сыйфатның кайсы дәрәҗәсе ясала?

1) төп
2) кимлек
3) артыклык
4) чагыштыру

А51. Сорауны белдерә торган кисәкчәләрне күрсәтегез.

1) -чы, -че; -сана, -сәнә
2) -дыр, -дер, -тыр, -тер
3) гына, генә; кына, кенә
4) -мы, -ме; -мыни, -мени

*А52. **Теләсә кем** ясалышы буенча нинди алмашлык?*

1) тамыр алмашлык
2) кушма алмашлык
3) парлы алмашлык
4) тезмә алмашлык

А53. Синтаксисның төп берәмлеген күрсәтегез.

1) сүз
2) аваз һәм хәреф
3) сүз формалары һәм сүзнең мәгънәләре
4) сүзтезмә һәм җөмлә

А54. Җөмлә ...

1) безне чорнап алган чынбарлык турында нәрсә дә булса хәбәр итә, сөйләүченең мөнәсәбәтен белдерә
2) төшенчәләрне атый гына

А55. Хәбәрлекле мөнәсәбәтне белдерә торган чаралар арасында кайсы артык?

1) хәбәрлек кушымчалары
2) зат-сан кушымчалары
3) -ныкы/-неке кушымчалары
4) шарт фигыль кушымчасы

А56. Сүзтезмәне күрсәтегез.

1) Казан — башкала
2) Ләйсән белән Галия
3) сөйләп бетерү
4) матур итеп сөйләү

А57. ***Кызыклы китап, яшел чирәм*** *сүзтезмәләренең төрен күрсәтегез.*

1) сыйфат сүзтезмә

2) исем сүзтезмә

3) алмашлык сүзтезмә

4) рәвеш сүзтезмә

А58. Җөмлә ничек оеша?

1) бер яисә ике сүзнең хәбәрлекле мөнәсәбәткә керүе нигезендә

2) ике мөстәкыйль төшенчәне оештыру, аларны үзара бәйләп кую нигезендә

3) бер сүзнең икенче сүз турында өстәмә аныклык, мәгълүмат бирүе нигезендә

А59. Иягә нинди билге хас түгел?

1) баш килештә генә килә

2) ия составында күплек, тартым кушымчалары була

3) таркалмый торган сүзтезмәләрдән тора

4) ия янында бәйлекләр, бәйлек сүзләр килергә мөмкин

А60. Җөмләнең баш кисәкләреннән генә торган рәтне күрсәтегез.

1) ия, хәбәр

2) аергыч, тәмамлык, хәл

3) ия, хәбәр, эндәш сүз, кереш сүз

4) аергыч, тәмамлык, хәл

А61. Аергычка нинди үзенчәлек хас?

1) исем белән бирелгән кисәкне ачыклый

2) фигыль белән бирелгән кисәкне ачыклый

3) бары тик сыйфат белән генә белдерелеп, барлык сүз төркемнәрен ачыклый

А62. Тәмамлыкка нинди үзенчәлек хас?

1) исем белән бирелгән кисәкне ачыклап килә

2) ия турында нәрсә дә булса хәбәр итә

3) эш-хәрәкәт үтәлүгә бәйле затны, предметны белдерә

4) эш-хәрәкәтнең үтәлү характерын белдерә

А63. Аныклагычка нинди үзенчәлек хас?

1) ияртүче сүздән алда килеп, аңа өстәмә аныклык бирә

2) ияртүче сүз урынында килеп, аңа өстәмә аныклык бирә

3) ияртүче сүздән соң килеп, аңа өстәмә аныклык бирә

А64. Җөмләнең тиңдәш булмаган кисәген билгеләгез.

1) барлык кисәкләр дә

2) баш кисәкләр генә

3) баш һәм иярчен кисәкләр

4) модаль кисәкләр

А65. Хәлләр мәгънәләре ягыннан ничә төрле була?

1) 5

2) 10

3) 8

4) 6

А66. Урын хәле кергән җөмләне күрсәтегез.

1) Әнә матур гына дулкынланып күренә торган уҗым басуы. (Г.Ибраһимов)

2) Беләсезме, ул ай бик карт бит инде. (Ф.Әмирхан)

3) “Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай” дигән сүзләр язылган һәйкәл милләттәшләребезне элеккеге Татар бистәсенә чакырып тора. (Х.Бәдретдинов)

4) Сандугач аз гына тыныч торган да яңадан сайрарга тотынган. (Д.Аппакова)

А67. Максат хәле үзен ияртүче фигыльгә …

1) юнәлеш килеше кушымчасы, инфинитив формасы, өчен бәйлеге, дип, максатыннан, ниятеннән кебек бәйлек сүзләр ярдәмендә иярә

2) хәл фигыль кушымчасы, чагыштыруны белдерүче -дай, -дәй, -ча, -чә кушымчалары; бәйлек яки бәйлек сүзләр ярдәмендә; янәшәлек юлы белән иярә

А68. Фикернең чыганагын белдерә торган кереш сүзләр: ...

1) димәк, шулай итеп, шул рәвешле, бәс

2) башлыча, нигънаять, ичмаса

3) беренчедән, бердән, икенчедән, өченчедән

4) минемчә, синеңчә, аныңча, безнеңчә, сезнеңчә, минем уемча

А69. Калын хәрефләр белән бирелгән сүз кайсы сүз төркеменә карый?

– Әйт миңа син өч матур сүз,

*Уйлап әйт син, **бәбкәем**! (Н.Исәнбәт)*

1) ия

2) аергыч

3) эндәш сүз

4) хәл

А70. Хикәя җөмлә …

1) тыныч, салмак тавыш белән әйтелә һәм, гадәттә, хәбәр белән тәмамлана

2) сөйләүченең ихтыярын — эшкә кушуын, үтенүен, өндәвен, боеруын белдерә

3) сорау интонациясе белән әйтелә, сорау алмашлыклары яки сорау кисәкчәләре ярдәмендә ясала

А71. Чынбарлыктагы күренешләрне раслау яки инкяр итүгә бәйле рәвештә җөмләләр нинди төрләргә бүленәләр?

1) гади — кушма

2) тулы — ким

3) раслау — инкяр

А72. Инкяр җөмләне күрсәтегез.

1) Беркөн мин улым Рөстәм белән әбиләрдә кунакта булдым. (Д.Аппакова)

2) Таңнан башланган кар туктамады, яуды да яуды. (Г.Ибраһимов)

3) Әнә шул тулган айга карагыз әле! (Ф.Әмирхан)

4) Шул көннәрдә безнең ана каз да бөтенләй сәерләнеп китте. (Г.Бәширов)

А73. Әйтү максаты буенча җөмләнең төрен билгеләгез.

Чит илдән мин бик тә укымышлы бер галим чакырттым. (Н.Фәттах)

1) сорау җөмлә

2) боеру җөмлә

3) хикәя җөмлә

4) тойгылы җөмлә

А74. Җөмләнең төрен билгеләгез.

Яхшыны ишетәсең килсә, яман сөйләмә. (Мәкаль)

1) билгеле үтәүчеле җөмлә

2) билгесез үтәүчеле җөмлә

3) гомуми үтәүчеле җөмлә

4) үтәүчесез җөмлә

А75. Сүз җөмләне билгеләгез.

1) Ул-бу булмасын! (Н.Фәттах)

2) Нинди бәла-каза? (Н.Фәттах)

3) Һәрбер сүзнең урыны бар. (Мәкаль)

4) Ал-ло!

А76. Җөмләдә сүз тәртибе сакланмаган очракны билгеләгез.

1) Боз һәм кар эреде. (Г.Тукай)

2) Мин дә әтием шикелле,
Шофер булырга уйлыйм. (З.Туфайлова)
3) Сөекле кошчыклар
Килгәннәр ич очып. (Б.Рәхмәт)
4) Иртәнге кояш
Нурларын чәчә. (З.Туфайлова)

А77. Аерылмыш ...

1) аергычның алдында килә
2) аергычтан соң килә

А78. Җөмләнең төрен билгеләгез:

Ачка тугыз юрган куйганнар, алай да йоклый алмаган. (Мәкаль)

1) гади җөмлә
2) кушма җөмлә
3) катлаулы кушма җөмлә
4) тезмә кушма җөмлә

А79. Иярченле кушма җөмләләр төзелешләренә карап нинди төркемнәргә бүленәләр?

1) теркәгечле һәм теркәгечсез
2) аналитик һәм синтетик

А80. Түбәндәге җөмләдә ничә гади җөмлә бар?

Боз һәм кар эреде,
Сулар йөгерде,
Елап елгалар,
Яшьләр түгелде,
Көннәр озая,
Төннәр кыскара. (Г.Тукай)

1) 3
2) 4
3) 5
4) 6

А81. Яктылык — кояш янында, яхшылык — ана янында. (Мәкаль) җөмләсенең төрен билгеләгез.

1) теркәгечле тезмә кушма җөмлә
2) теркәгечсез кушма җөмлә
3) иярчен җөмлә
4) гади җөмлә

А82. Ия белән хәбәр арасында сызык куелырга тиешле җөмләне билгеләгез.

1) Яхшы кеше (?) эштә беленер. (Мәкаль)

2) Азыклы ат (?) арымас. (Мәкаль)

3) Яхшының кадерен (?) ил белер. (Мәкаль)

4) Ана (?) шәфкать диңгезе. (Мәкаль)

А83. Түбәндәге җөмләдә кайсы җөмлә кисәкләре юк?

Очып барганда Тилгән,

Җирдә чебиләр күргән. (Х.Шабанов)

1) аергыч

2) хәбәр

3) тәмамлык

4) хәл

А84. Кайсы очрак синтетик кушма җөмләгә мисал була?

1) Ул керфекләрен яңадан ачып җибәргәндә, карт куак, яшәреп, матур яшел яфракларга күмелеп утыра икән. (Д.Аппакова)

2) Шунда ата каз башын иеп, үпкәләгән кыяфәттә, күңелсез генә лапаска таба киткән була. (Г.Бәширов)

3) Аңладым ич, аңладым:
Бит юарга сабыннары
Юк икән бит аларның. (Р.Бәшаров)

4) Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява,
Җирләр дымлана, –
Бу кайчак була? (Г.Тукай)

А85. Иярчен җөмлә баш җөмләнең тәмамлыгы урынында килсә, андый җөмлә ...

1) тәмамлыгы булган гади җөмлә дип атала

2) иярчен тәмамлык җөмлә дип атала

А86. Аналитик сәбәп җөмлә баш җөмләгә ...

1) *күрә* бәйлеге, *сәбәпле* яки *аркасында* бәйлек сүзләре, кайбер килеш кушымчалары ярдәмендә бәйләнә

2) мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә бәйләнә

3) *чөнки* теркәгече яки көттерү паузасы ярдәмендә дә бәйләнә ала

4) мөнәсәбәтле сүзләр һәм *чөнки* теркәгече яки көттерү паузасы ярдәмендә дә бәйләнә ала

А87. Җөмләнең мәгънәви төрен билгеләгез.

Теле татлының дусы күп. (Мәкаль)

1) иярчен аергыч җөмлә
2) иярчен тәмамлык җөмлә
3) иярчен максат җөмлә
4) иярчен кире җөмлә

А88. Иярчен ия җөмләне табыгыз:

1) Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә, матур милли көй. (Г.Тукай)
2) Ул биргән яулык та озак еллар түш кесәсеннән төшмәде. (Ш.Маннур)
3) Кем килене булыр, шул борчый, шул уйландыра иде аны (Ә.Еники).
4) Тимерне кызуында сугалар. (Мәкаль)

А89. Иярчен хәбәр җөмләнең ...

1) аналитик төрләре дә, синтетик төрләре дә була
2) аналитик төрләре була алмый, синтетик төрләре генә була
3) синтетик төрләре була алмый, аналитик төрләре генә була

А90. Иярчен тәмамлык җөмләле кушма җөмләләр арасында артык очракны күрсәтегез.

1) Ир какканны ил кагар. (Мәкаль)
2) Без күрәсене кеше күрмәс. (Мәкаль)
3) Буең җитмәгәнгә сузылма. (Мәкаль)
4) Ал тәгәрмәч кайдан, арты да шуннан. (Мәкаль)

А91. Җөмләдә бәйләүче чараны билгеләгез.

Тышта бик җылы булса да,
Тун кигәннәр чебиләр. (М.Фәйзуллина)

1) 2 нче зат боерык фигыльнең берлек формасы
2) *-са да*
3) санау интонациясе
4) көттерү паузасы

А92. Җөмләнең бәйләүче чарасын күрсәтегез:

Алгы сызыкка беренче баруы булмаса да, уйлана калды: немец моннан биш йөз метрда гына. (Х.Камалов)

1) көттерү паузасы
2) ки теркәгече
3) ялгызак мөнәсәбәтле сүзе
4) кушымча

А93. Кушма җөмләне күрсәтегез.

1) Тәгаен әйтүе кыен. (Т.Галиуллин)

2) Бик каты ишек ябылды. Аннары бүлмә эче тып-тын калды. (Г.Ахунов)

3) Кинәт сискәнеп куйды ул, гүя яшен ташы урталай ярып үткәндәй булды. (Р.Мөхәммәдиев)

4) Туры әйтелгән сүз — гаделлекнең аяусыз көндәше. (М.Галиев)

А94. Иярчен кире җөмләне табыгыз.

1) Күлнең барлык бакалары тырыша торгач, Башбармак тәмам савыгып аякка баскан. (Ф.Яруллин)

2) Солтанның шул кадәр жаны бизгән: авылына әйләнеп тә карамый. (Г.Бәширов)

3) Быелгы яз, картлар әйтмешли, бик иртә уянды. (Ш.Камал)

4) Уянмый ул, бөтен кеше тавышлансын. (Г.Тукай)

А95. Синтетик иярчен аергыч җөмләне билгеләгез.

1) Гомер юлының икенче яртысына җиткәч, кешенең фәлсәфәсе үзгәрә. (К.Кәримов)

2) Кайчан кирәк тапсалар, шунда хезмәт итә. (Г.Ибраһимов)

3) Бәхетле шул баладыр, кайсы дәресенә күңел бирсә. (Г.Тукай)

4) Гадәтем: ялгыз кешеләрне кытыклап үтерәм. (Г.Тукай)

*А96. **... эндәшсәң, ... җавап. (Мәкаль)** җөмләсендә күп ноктапар урынына тиешле парлы мөнәсәбәтле сүзләрне куегыз.*

1) кемнән ... шуңардан

2) кем ... шул

3) ничек ... шундый

4) ни ... шуны

А97. Җөмләнең бәйләүче чараларын табыгыз.

Керегез, ә мин киттем. (*И.Гази)*

1) җыючы теркәгеч

2) каршы куючы теркәгеч

3) бүлүче теркәгеч

4) санау интонациясе

А98. Җөмләнең структур төрен билгеләгез:

Иртәләрен инде көтүче Мифтахның кычкырып көтү куганы да ишетелмәс булды, озын чыбыркысы да сызгырып шартламый иде. (М.Галәү)

1) теркәгечле тезмә кушма җөмлә

2) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә

3) синтетик иярченле кушма җөмлә

4) аналитик иярченлн кушма җөмлә

А99. Иярчен җөмләнең мәгънәви төрен билгеләгез:

Бишбармак биергә чыгып басуга, күлнең барлык җан ияләре, җыелешып, аны карарга киләләр һәм такмаклар әйтеп торалар икән. (Ф.Яруллин)

1) иярчен ия җөмлә

2) иярчен хәбәр җөмлә

3) иярчен аергыч җөмлә

4) иярчен вакыт җөмлә

А100. Кереш җөмлә түбәндәге мәгънәне белдерә.

1) баш җөмләне яисә бер кисәкне аныклый

2) җөмләнең яисә аның кайсы да булса бер кисәгенең эчтәлегенә сөйләүченең мөнәсәбәтен белдерә

3) көтелгән эш яки хәлнең баш җөмләдә киресе булучагын белдерә

4) баш җөмләдәге эш яки хәлнең максатын белдерә

А101. Кушма җөмләдәге гади җөмләләр санын билгеләгез.

Син адаштың, ләкин син яхшы идең, синең яхшы иде күңелең, тик белмәдең тормыш баткагыннан ялгыз чыгу мөмкин түгелен. (Һ.Такташ)

1) 3

2) 4

3) 5

4) 6

А102. Тиңдәш кисәкләре яки тиңдәш җөмләләре күп булу аркасында, бик нык җәенкеләнгән гади яки кушма җөмлә ничек атала?

1) өстәлмә

2) текст

3) күзаллаулы баш килеш

4) тезем

А103. Сөйләүче кулланган башка кеше сүзләре ничек атала?

1) туры сөйләм

2) кыек сөйләм

3) уртак сөйләм

4) чит сөйләм

А104. Бер-берсенә кискен каршы кую интонациясе белән бәйләнгән гади җөмләләр арасына нинди тыныш билгесе куела?

1) өтер

2) ике нокта

3) сызык

4) бернинди дә билге куелмый

А105. Җөмләнең иясе дә, хәбәре дә сан белән белдерелсәләр, ике арага нинди тыныш билгесе куела?

1) өтер;

2) сызык;

3) бернинди дә билге куелмый.

А106. Гомумиләштерүче сүз тиңдәш кисәкләрдән алда килсә, аннан соң нинди тыныш билгесе куела?

1) өтер

2) сызык

3) ике нокта

4) җәя

А107. Тиңдәш аергычлар бер-берсеннән өтер белән ...

1) аерылалар

2) аерылмыйлар

А108. Сорау билгесе ...

1) сөйләүченең, тыңлаучыга мөрәҗәгать итеп, нәрсәне дә булса белергә теләвен аңлата торган җөмләләр ахырына куела

2) көчле тойгыны белдергән сүзе булган җөмләләрдән соң куела

3) хикәя җөмлә ахырында куела

ТЕКСТ ӨСТЕНДӘ ЭШ

10 НЧЫ КЛАСС

1 нче текст

Текстны укыгыз. Биремнәрне үтәгез.

(1) Язмыш синең тез астыңа китереп сукса — егылмас 2чен якасына ябыш. (2) Утларга салса — үзең аннан да көчле ян, шул вакыт аның кызуын сизмәссең. (3) Суларга ташласа — күбек булып өскә күтәрелмә — асылташ булып төпкә бат, ялтыравыңны күреп, чумып алырлар. (4) Тузан итеп һавага күтәрсә — яңгыр тамчыларына кушылып, җиргә төш. (5) Карурманнарда адаштырса — кояшка карап юл сайла. (6) Ташлар белән бастырса — чишмәгә әверелеп, иреккә ургы. (7) Җиргә күмсә — орлык шикелле тишелеп чык. (8) **Җилкәңне** җилләр екса — йөрәгеңне җилкән итеп күтәр. (9) Нинди генә

очракта да җиңәргә өйрән. (10) Көчле рухлылар гына максатларына ирешә алалар. (11) Түземнәр генә бәхеткә лаек.

(86 сүз)

В1. Текст кайсы әсәрдән алынган? Аның авторы кем?

В2. Текстка исем бирегез.

В3. 6 нчы җөмләдәге фигыльләрне күчереп яз, төркемчәсен билгелә.

В4. 1-2 җөмләләрдән исемнәрне күчереп языгыз.

В5. Тексттан кушма сүзләрне күчереп языгыз.

В6. Калын шрифт белән бирелгән сүзгә морфологик анализ ясагыз.

В7. Астына сызылган сүзнең синтаксик вазыйфасын һәм нәрсә белән белән белдерелүен билгеләгез.

В8. Интонациясе буенча соңгы җөмләнең төрен күрсәтегез.

В8. Кайсы җөмләләрдә текстның төп мәгънәсе чагылыш тапкан?

С. Текстта нәрсә турында сүз бара? *Түземнәр генә бәхеткә лаек* җөмләсен ачыклап, үз фикерләрегезне языгыз.

2 нче текст

Текстны укыгыз һәм тексттан соң бирелгән биремнәрне үтәгез.

(1) Адәми зат җир йөзенә килеп тә, үзенең кем булуы, тамырларының кая барып тоташуы турында уйланмый икән, андый бәндәдән өметеңне өз, юлдаш булма, чөнки андый зат иң җаваплы бер мәлдә юлдашын гына түгел, илен дә сатачак, чөнки ул җирлексез, тамырсыз корыган агач. (2) Туган җир, изге туган туфрак ул — шаулап үсеп утырган зур агач, ә яфраклары — без. (3) Ул агачның тирәнгә киткән нык тамырлары — безнең яшәешнең киләчәге. (4) Үткәнебез, тарихыбыз исә — гасырлар буена тупланып килгән китапларыбызда. (5) Теге яки бу халыкның үткәне — аның җиңелү белмәс дәһшәтле коралы да. (6) Гыйбрәтле тарих булмаса, ничек итеп дошманга каршы тормак кирәк. (7) Шуңа күрә дә дошман явы килә-нитә калса, алтын-көмешкә, башка төрле **мал-мөлкәткә** түгел, иң әүвәл бәһа белмәс хәзинәгә — китапка каныга торган булган. (8) Гасырлар буена шулай килгән.

(М.Хәсәнов) (119 сүз)

В1. Текстка исем бирегез.

В2. 1 нче җөмләләрдән ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз.

В3. Тексттан гарәп һәм фарсы сүзләрен күчереп языгыз.

В4. Тексттагы *адәми зат, бәндә* сүзләрен сез ничек аңлыйсыз, бу сүзләр *кеше* сүзенә карата нинди мөнәсәбәттә?

В5. 7 нче җөмләдә калын хәрефләр белән бирелгән сүзне сүз ясалышы ягыннан билгеләгез.

В6. 5 нче җөмләдәге тыныш билгеләренең куелышын аңлатыгыз.

В7. 2 нче җөмләнең төзелеше ягыннан төрен билгеләгез.

В8. 2 нче җөмләнең төзелеше ягыннан төрен билгеләгез.

С. *Акыллылар алга бара*

үткәне аша... (Акъегет) гыйбарәсен сез ничек аңлыйсыз? Әлеге юлларның текст белән бәйләнешен аңлатыгыз. Үз фикерегезне берничә җөмлә белән языгыз.

3 нче текст

Текстны укыгыз, биремнәрне үтәгез.

(1) Мең тугыз йөз сиксән өченче елны, Ярослав Гашекның 100 еллык юбилеенда катнашырга дип, Чехословакиягә бардым. (2) Прагада экскурсия вакытында безгә бер агай килеп кушылды. (3) Гомерендә беренче күрүе булса да, без аның өчен якын идек, чөнки без — аның ата-бабасы иленнән, туган җиреннән килгән кешеләр. (5) Сирәк-мирәк, үзе сиздермәскә тырышса да, мин аның күзләре дымлануын да искәрдем. (6) Юкка гына әйтмәгәннәр шул: малын җуйган җиде ел елар, иленнән аерылган — гомере буе.

(7) Дөнья киң. (8) Адәм баласы йөремсәк. (9) Ул кай тарафларга гына барып чыкмый, … ул цәрчак кендек каны тамган җирен — изге туган җирен сагынып кайта, чөнки аның бәхете — туган илендә, туган җирендә.

(Р.Кәрами) (96 сүз)

В1. Текстка исем бирегез.

В2. Текст нинди стильдә язылган?

В3. Икенче абзацтан хәреф саны белән аваз саны туры килмәгән сүзне күрсәтегез.

В4. Тексттан саннарны күчереп языгыз һәм төркемчәсен билгеләгез.

В5. Астына сызылган сүзне сүз ясалышы ягыннан тикшерегез.

В6. 9 нчы җөмләдәге күпнокталар урынына бәйләүче чараларның кайсысын куярсыз?

1) чөнки

2) әмма

3) аеруча

4) ки

В7. 3 нче җөмләнең төзелеше ягыннан төрен билгеләгез.

В8 5 нче җөмләне аналитик иярченле кушма җөмлә итеп үзгәртеп языгыз.

С. ***Текст нәрсә турында? Авторның әйтәсе килгән фикере нинди? Язмагызда туган җир турында татар халык мәкальләре кулланып языгыз.***

4 нче текст

Текстны укыгыз, биремнәрне үтәгез.

(1) Беренче тапкыр мәктәпкә килгәч, мөгаллим безне идәнгә җәйгән салам өстенә тезеп утыртты. (2) Һәрберебезгә берәр дәфтәр, карандаш һәм кечкенә такта бирде... (3) Ул безне гаҗәеп бер түземлек белән үзе белгән бар нәрсәгә өйрәтте. (4) Һәр укучыга карандашны ничек тотарга кирәген күрсәтте, аннары, дәртләнеп китеп, таныш булмаган сүзләрне аңлата торган иде.

(5) Шуларны хәзер искә төшерәм дә таң калам — үзе көчкә иҗекләп кенә укыган, кулында бер генә дәреслеге, хәтта гади әлифбасы да булмаган ярым надан ул егет шундый зур эшкә алынырга ничек җөрьәт итте икән? (6) Бабалары һәм җиденче буынга кадәр бабаларының бабалары әлифне таяк дип белмәгән балаларны укыту **уен эш түгел бит**!

(7) Дәйшән безне үзе белгәнчә, кулыннан килгәнчә, күңел сиземе буенча укыткан. (8) Ул үзе дә белмәстән батырлык эшләде. (9) Әйе, ул көннәрдә безгә, авылдан беркая чыкмаган кыргыз балаларына, мәктәптә, дөресрәге, ярыкларыннан һәрвакыт карлы тау түбәләре күренеп торган балчык өйдә, кинәт яңа, күз күрмәгән, колак ишетмәгән дөнья ачылды.

(Чыңгыз Айтматов) (141 сүз)

В1. Астына сызылган сүзнең транскрипциясен бирегез.

В2. 1-3 җөмләләрдән алынма сүзләрне күчереп языгыз.

В3. 2 нче абзацтан фразеологизмнарны табып языгыз.

В4. Беренче абзацтан кушма сүзне язып алыгыз.

В5. 3 нче һәм 5 нче җөмләләрдәге **ул** алмашлыгының синтаксик вазыйфаларын билгеләгез.

В6. Аныклагычы булган җөмлә санын күрсәтегез.

В7. Аерымланган вакыт хәле булган җөмләнең санын күрсәтегез.

В8. 3 нче җөмләнең төрен билгеләгез.

11 НЧЕ КЛАСС

1 нче текст

В. Текстны укыгыз һәм тексттан соң бирелгән биремнәрне үтәгез.

(1) Кеше белән табигать гел **бергә**. (2) Кеше табигатьтән кыюлыкка, батырлыкка, сабырлыкка өйрәнә. (3) Кеше табигатьне, табигать кешене бизи. (4) Бер-берләрен тулыландыручы бу ике көчне аерып карап булмый. (5) Кеше табигать матурлыкларыннан кыска гына вакытка аерылып торса да ямансулый, сагына башлый.

(6) Теплицадагы үсемлекләргә дә бөтен нәрсәсен бирәләр: ашламасын, дымын, яктылыгын, әмма алар барыбер кыр чәчәкләре кебек нык булып үсә алмый. (7) Йолкып алуга, сабаклары егылып төшә, чөнки алар көннәр буе җилләрдә тирбәлмәгән, кояшның рәхимсез эсселегендә сыналмаган. (8) Кыр чәчәкләре тамырларын теләгән кадәр тирәнгә җибәрә ала, ә теплицадагы чәчәкләрнең тамырлары каты бетонга төртелеп, кая китәргә белмичә, сабак тирәсендә чуала. (9) Тамыры ташка тигән гөлнең очы саргая башлый. *(Ф.Яруллин) (98 сүз)*

В1. Кайсы җөмлә текстның исеме булып килә ала?

1) Теплицадагы үсемлекләр.

2) Кеше — табигать баласы.

3) Кеше табигатьне бизи.

4) Теплицадагы үсемлекләр һәм кыр чәчәкләре.

В2. Тексттан сингармонизм законына буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз.

В3. 6 нчы җөмләдән авазларның йотылу күренешенә мисаллар китерегез.

В4. Рус теле һәм рус теле аша кергән алынмаларны күрсәтегез.

В5. Астына сызылган сүзне морфемаларга таркатып языгыз.

В6. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди сүз төркеме белән белдерелүен һәм синтаксик вазыйфасын билгеләгез.

В7. Составында эшнең башлануын белдерә торган кушма фигыль хәбәре булган җөмләләрнең санын күрсәтегез.

В8. 8 нче җөмләнең төзелеше ягыннан төрен билгеләгез.

С. Теплицадагы үсемлекләр образын кешеләргә күчереп аңлатып карагыз. Бу образ белән автор нәрсә әйтергә теләгән.

2 нче текст

В. Текстны укыгыз һәм тексттан соң бирелгән биремнәрне үтәгез.

(1) Мәгълүм ки, уку-язу өчен хәрефләрне белү кирәк. (2) Билгеле булганча, борынгы мисырлыларның сүзле-иҗекле язу тәртибеннән — көнбатыш самиларның иҗекле системасы, аннан грек алфавиты үсеп чыккан.

(3) Грек алфавиты исә борынгы этрус алфавитына да нигез булып хезмәт иткән, ә соңгысы инде латин алфавиты өчен база ролен үтәгән. (4) Латин алфавитыннан күпчелек Көнбатыш Европа, Африка, Азия, Океания илләренең алфавитлары барлыкка килгән.

(5) Хәзерге рус һәм татар алфавитларының нигезендә кириллица дигән славян алфавиты ята. (6) Бу алфавитның исеме IX гасыр урталарында яшәгән славян мәгърифәтчесе Кирилл (монахлыкка кадәр аның исеме Константин булган) исеме белән бәйле. Кирилл исә үзенең әлеге алфавитын 863 нче елда төзи. (7) Ул 24 хәрефне греклардан алган, ә дистәдән артык славян авазларын бирү өчен өр-яңа хәрефләр уйлап чыгарган.

(8) Фәндә грекларның язуны хәзерге Ливан җирләрендә яшәгән финикиялеләрдән кабул ителгәнлеге расланган. (9) Бу хакта грек риваятьләрендә дә сөйләнә, хәреф исемнәренең һәм формаларының охшашлыклары да әнә шуны күрсәтеп тора. (10) Шул рәвешчә, дөньядагы барлык алфавитлар да теге яки бу дәрәҗәдә әнә шул финикиялеләр алфавитына килеп тоташа. (Д.Г.) (152 сүз)

B1. Текст нинди стильдә язылган?
B2. 1 - 4 җөмләләрдән алынма сүзләрне күчереп языгыз.
B3. Астына сызылган сүзне морфемаларга таркатып языгыз.
B4. Тексттан ялгызлык исемнәрен күчереп языгыз.
B5. Тексттан артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны табып языгыз.
B6. Тексттагы кереш сүзләрне табып языгыз, мәгънәсен аңлатыгыз.
B7. 2 нче җөмләдәге тыныш билгеләренең куелышын аңлатыгыз.
B8. 9 нчы җөмләнең схемасын сызыгыз.

C. 1990 нчы еллар ахырында сүз алып барылган күренеш — кириллицага нигезләнгән татар язуын латин графикасына күчерү турында нәрсә беләсез? Бу очракка карата сезнең фикерегез нинди?

3 нче текст

B. Текстны укыгыз. Биремнәрне үтәгез.

(1) Юллар, юллар... (2) Алып китүчесе дә, кайтарып куючысы да шушы ук юллар. (3) Тармакланып җиргә уелган — буш җиргә түгел, кешеләр күбрәк яши торган җиргә. (4) Юлда йөрү — **яшәүнең** бер формасы. (5) Йөрелмәгән юлның

кадере юк! (6) Бер юлны икенчесе кисә; кечесен олы юл таптап үтә; пычрак юллар көзге артыдай чем-кара асфальтка килеп кушыла; чуерташлы күтәртелгәннәре кинәт өзелеп икмәк басуы читенә алып чыга... (7) Юлны юл алыштыра... (8) Бөтенесе дә мөҗим, бөтенесе дә хәрәкәтле. (9) Максатка илтүчесен олы юл диярләр, хәтта ул сукмак кына булса да, кемдер аны олы юл дип зурлап әйтер, чөнки җәркемнең дә үз максаты үзенә якын. (10) Коры юл, су юлы, чуен юл... (11) Теләсә кайсын сайла. (12) Аягың тартса юлга чык.

(13) Чит җирләргә алып китүче юлларны сөйми Фазыл. (14) Ерак юлга чыгарга риза ул үзе — тик Татарстаныбызда гына булсын. (15) Үзебезнең юлларда сагыш юк, сагыну газаплары интектерми. (16) Туган авылың искә төшсә, сөйгән ярларың чакырса, җәяүләп китәргә, Чулман белән Иделне каек белән кичәргә; Мишә, Ык, Шушма, Үшнә, Сөлчә, Зөя кебек елгаларын колачлап йөзәргә була, ә чит җирләрдә ерак араларны кичүе ай-һай авыр...

(К.Кәримов) (162 сүз)

В1. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзне транскрипциядә бирегез.

В2. 1–5 нче җөмләләр арасында ирен гармониясенә буйсынган сүзне күчереп языгыз.

В3. Чулман гидронимының бүгенге көндә актив кулланылышта булган вариантын языгыз.

В4. 5 нче җөмләнең баш кисәкләрен табыгыз.

В5. 16 нчы җөмләдәге фигыльләрне күчереп языгыз, төркемчәсен күрсәтегез.

В6. 9 нчы җөмләдән исемләшкән сыйфат фигыльне табып языгыз.

В7. 1 нче абзацтан хәбәре хәбәрлек сүз белән белдерелгән җөмләнең санын күрсәтегез.

В8. 6 нчы җөмләнең төзелеше ягыннан төрен билгеләгез.

С. Текст нәрсә турында? *Йөрелмәгән юлның кадере юк!* җөмләсен сез ничек аңлыйсыз?

4 нче текст

В. Текстны укыгыз һәм тексттан соң бирелгән биремнәрне үтәгез.

Әбугалисина

(1) Ул төшкә кадәр балаларга сабак укыта, төштән соң, урамга чыгып, алар белән рәхәтләнеп уйнап йөри. (2) Аның бу **гадәте** кайбер кешеләргә бер дә ошамый. (3) Аңа: ”Син шундый галим, шундый акыл иясе кешесең, никадәр балаларга сабак өйрәтәсең, белем бирәсең, ә үзең надан балалар белән уйнап йөрисең”, — диләр.

(4) Әбүгалисинаның моңа бер дә исе китми. (5) Ул: ”Кешенең һәр яшендә үзенә күрә бер матурлыгы була, сабыйлыкның матурлыгы уен белән”, — дип җавап бирә.

(6) Тагын берничә ел үтеп китә. (7) Әбугалисина зур галим булып җитә. (8) Бохара тирәсендә аңа тиң, аның белән сүз көрәштererлек кеше калмый, ләкин ул үзе моңа гына риза булмый, тагын да тирәнрәк белем алырга тели. (9) Туганы Әбелхарис белән бергәләп, гыйлем эстәп, алар туган илләреннән ераклarга китәргә уйлыйлар, ата-аналарыннан тұбәнчелек белән рөхсәт сорыйлар. (10) Ата белән ана, балаларыннан аерылу бик кыен булса да, аларның яхшы теләкләренә каршы килмәделәр.

(11) — Бездән рөхсәт, теләгән җирләрегезгә барыгыз, дөнья күрегез, белем алыгыз, шул белемнәрегез белән халыкка файдалы кешеләр булыгыз, — диделәр.

(К.Насыйри) *(172 сүз)*

В1. Кайсы мисал текстның төп фикерен ассызыклый һәм аңа эпиграф булып хезмәт итә ала?

1) Мәңге яшәргә теләсәң, и угыл,
Ал гыйлем, чөнки тереклек суы ул. (Габдерәхим Утыз Имәни)

2) Дөньяда иң читене — үз алдында акыллы булып күренү. (Туфан Миңнуллин)

3) Бәхетсезлекнең күбесе наданлыктан башлана. (Гомәр Бәширов)

4) Кырык ел көтү көтеп чыбыркы шартлата белмәгән кеше кырык беренче елында өйрәнә алмас. (Әхсән Баян)

В2. Тексттан үзара синоним булган сүзләрне (исем сүз төркемен) табыгыз.

В3. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзне транскрипциядә бирегез.

В4. Астына сызылган сүзне морфемаларга таркатып языгыз.

B5. 1–4 нче җөмләләрдән алмашлыкларны күчереп языгыз, төркемчәсен билгеләгез.

B6. 2 нче җөмләдән сүзтезмәләрне күчереп языгыз.

B7. 4 нче җөмләнең төзелеше ягыннан төрен билгеләгез.

B8. 8 нче җөмләнең төзелеше ягыннан төрен билгеләгез.

C. *Мин күп белергә телим, чөнки*... Әлеге җөмләне дәвам итеп, үз фикерегезне белдереп кечкенә хикәя төзеп языгыз.